ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

«УТЫЗЫНЧЫ ЕЛЛАРДА...»

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

«УТЫЗЫНЧЫ ЕЛЛАРДА...»

халык тормышының фаҗигале сәхифәләре

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2022

УДК 94(47)"20"–058
ББК 63.3(2)614–361ю1
У 82

Төзүчесе, басмага әзерләүче
һәм мәкаләләр авторы –
археограф, текстолог
Раиф Мәрданов

У 82 «Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2022. – 180 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 29 нчы китап).

Китапта 1930 нчы еллардагы сәяси эзәрлекләү фаҗигаләренә бәйле кульъязмалар – хатирәләр, хатлар, документлар, бәет-мөнәҗәтләр – тупланды һәм аларга бәйле аңлатмалар тәкъдим ителде. Алар репрессия һәм сөрген хәсрәтләрен үз башларыннан кичергән кешеләр (элекке дин әһелләре, бай-сәүдәгәрләр һ.б.) тарафыннан теркәлгән.

Ул чорның тагын бер дәһшәтле күренешенә – мәчет манараларын кисүгә – багышланган бәет вариантлары урын алды.

Текстларның күбесе Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмалардан.

ISBN 978-5-88473-094-6

УДК 94(47)"20"–058
ББК 63.3(2)614–361ю1

© Мәрданов Р.Ф., 2022
© «Милли китап» нәшрияты, 20212

«Дога кылам Сталинга...»

Әйе, нәкъ шундый каршылыклы сүзләр бар бу китаптагы текстларның берсендә. Ул заманда дин тоту (димәк, дога кылулар да) тыелган булуы белән бергә, Сталинның даһилыгына мөкиббән китү дә күздә тотылмаган. Утызынчы елларда – Иосиф Сталин чорында төрмәгә ябылган татар укымышлысының әлеге сүзләре киная белән әйтелгән. Ул үз җәмәгатенә мөрәҗәгать итеп, болай дигән:

Минем өчен сәдака бир
Мин укыган остазыма?!
Йөз мең яшәүләрен теләп,
Дога кыйлам Ысталинга.

«Татар археографиясе» сериясенең шушы китабында катлаулы замандагы репрессияләргә, халык тормышындагы үзгәрешләргә һәм фаҗигаләргә бәйле кулъязма истәлекләр тупланды. Алар турында тәфсилләп язуга керешкәнче, репрессив чараларның гомуми манзарасын искә төшерик.

***

Совет хакимлеге урнашкач илдәге сәяси һәм иҗтимагый тормыш тамырдан үзгәргән. Байлар һәм ярлылар, изүчеләр һәм изелүчеләр дигән сыйнфый көрәш мәсьәләсе чиктән тыш куертылган һәм киң мәйдан алган. Ягъни, бер үк ил-дәүләт эчендәге гражданнардан торган җәмгыятьне яңа хакимият икегә аерып, акка һәм карага бүлгән. Яхшы һәм бай тормышлы, укымышлы, фикерле кешеләрнең күпчелеге совет һәм халык дошманнарына әверелгән. Дошман сыйныф вәкилләренә карата рәхимсез һәм даими репрессияләр үткәрелгән.

Яңа хакимият беренче елларыннан ук үзенә каршы чыгучыларны эзәрлекли башлаган. Репрессияләрнең икенче

дулкыны дин әһелләренә, элекке сәүдәгәрләргә һәм чагыштырмача таза тормышлы кешеләргә юнәлдерелгән. Гомумән, совет власте игълан ителгәннән алып репрессия чаралары тукталып тормаган: 1918–1919 елларда бай һәм мөлкәтле кешеләргә контрибуция һәм зур салымнар түләтү, «хәрби коммунизм» чорында (1919–1920 нче елларда) һәм аннан соңгы унбиш-егерме ел дәвамында авылларда яшәгән кулаклардан икмәк-ашлыкларын алу, динне кысрыклау белән бергә, руханиларны җәберләү, элеккеге сәүдәгәр һәм байларның, мулла-мәзиннәрнең мал-мөлкәтләрен тартып алып, йорт-җирләреннән мәхрүм итү, милләтче, солтангалиевче, троцкийчы, чит ил шпионнарын һәм бүтән төрле – совет властенә дошман элементларны эзләү, хөкүмәткә һәм большевиклар партиясенә карата җайсыз һәм тәнкыйть сүзе әйтүчеләрне эзәрлекләү... Ул чорда хаклы рәвештә хөкемгә тартылучыларга караганда, хаксызга җәберләнүчеләр чамадан тыш күп булган. Совет хөкүмәтенең һәм җитәкчелегенең дистә еллар буе дәвам иткән репрессия ысуллары: хокуклардан һәм мөлкәттән мәхрүм итү, үлем җәзасы, төрмәләр, лагерьлар, сөргеннәр бәласе бөтен гаиләләргә диярлек кагылган. Элекке дин әһелләренең берсе дә җәбер-золымнан котылмагандыр.

Егерменче гасырда СССРдагы репрессияләрнең вәхши алымнары һәм корбаннары турында бик күп язылды һәм сөйләнде. Сталин хакимлек иткән чорда репрессияләнгән кешеләрнең саны турында мәгълүматлар күп һәм алар берберсеннән бик нык аерыла. Һәрхәлдә, алар миллионнар белән исәпләнә. Тарихчылар язган ышанычлы мәгълүматларга караганда, мәсәлән, Виктор Земсков тикшерүенчә, 1921–1953 елларда 4 миллион 60 мең 306 кеше (күпчелеге 58 нче маддә буенча) репрессияләнеп, шулардан 799 мең 455-е атып үтерелгән. Кулак буларак сөрелгәннәрнең тулы саны билгесез, В.Земсков 1929–1933 елларда андыйларның исәбе 4 миллион тирәсе булган дип яза. 1930–1931 еллар эчендә кулак сөргеннәренә 1,8 миллионнан артыграк кеше җибәрелгән. Шулардан 1932 ел башына 1,3 миллион калган (башкалары үлгән, качкан,

кайтарып җибәрелгән)[1]. Кулак итеп сөрелгәннәрдән барлыгы ничәсе үлгәнлеге турында төгәл сан шулай ук юк, һәрхәлдә, алар 700 мең тирәсе булган һәм күпчелеге 1930–1933 елларга туры килгән дип язалар.

Нахак корбаннарны истә тоту һәм алар турында язу дәһшәтле, коточкыч заманнарны күзаллау, белеп тору һәм гыйбрәт алу өчен кирәк. Алар бит кемнәрнеңдер газизләре, күз нурлары булган.

Сыйнфый дошманнарның бер өлеше СССР Җинаять кодексының иң авыр – 58 нче маддәсе буенча хөкем ителгән. Үз эчендә унсигез пункттан торган бу маддә властька каршы нинди дә булса каршылык хәрәкәтен (контрреволюцион хәрәкәтне) үз эченә алган һәм 1961 елга хәтле гамәлдә булган. Репрессияләнгән кешеләрнең шактые әлеге маддәдән тыш, административ ысул белән сөрелгән. Бу очракта, нигездә, совет хөкүмәте үткәргән чараларга каршы, бигрәк тә, колхозлашу чорында сыйнфый дошман – кулак дип җәберләнгән кешеләр күздә тотыла. Аларның бөтен йорт-җирләре һәм мал-мөлкәтләре тартып алынган, барлык хокуклары бетерелгән (ягъни, раскулачивать ителгән). 1929 елдан 1930 ел уртасына хәтле СССР авылларында яшәүчеләрнең алдынгы, тырыш сафына каршы үткәрелгән геноцид сәясәте нәтиҗәсендә 120 меңнән артык гаилә (ягъни, 2 миллион чамасы кеше) кулакларны сыйныф буларак юкка чыгару корбаны булган. Авыл советлары раскулачивать итү буенча үзара ярышлар оештырганнар. Шул рәвешчә, крестьяннар концлагерьларның бушка хезмәт итүче төп көчен тәшкил иткән.

Сәяси репрессия корбаннары Хәтер китабының унтугызынчы томындагы мәгълүматка игътибар итик: «Татарстан Республикасы буенча административ репрессияләргә 50 меңнән

---

[1] Земсков В.Н. Масштабы политических репрессий в СССР (против спекулятивных мифологических построений) // Известия Самарского научного центра РАН. – 2012. – №3. Шуны да искәртергә кирәк, В.Н.Земсков исәпләгән саннарга кайбер категорияләр кермичә калган, мәсәлән, махсус указлар буенча («башак» өчен һ.б.) хөкем ителгән кешеләр.

артык гаилә дучар булган. Ул вакытта гаиләләрнең күп балалы булуын, нигездә 6–10 кешедән торуын искә алсак, репрессия корбаннарының саны 350 мең кешегә җитә»[2]. Хәтер китабының бу томында 1816 гаилә турында кыскача белешмә бирелгән. Милли состав буенча шуларның 73 проценты татарлар, 4,4 проценты руслар булуы күрсәтелгән[3]. Хәтер китапларындагы саннар һәм аларның нисбәтләре, әлбәттә, төрлечә. Мәсәлән, Татарстанда 58 нче маддә буенча хөкем ителгән репрессия корбаннарының өченче томындагы саннар бүтәнчә. Фамилияләр «В» һәм «Га» хәрефләренә башланган әлеге томга барлыгы 3552 фамилиягә бәйле мәгълүмат теркәлгән. Шулардан тоткынлыкта һәлак булганнары 23% тәшкил итә (бу исәптәгеләрнең 10% атып үтерелгән). Гомуми санның 56,5 проценты татарлар (2006 кеше) һәм 30 проценты руслар (1052 кеше).

СССРның 1937–1938 еллардагы сәяси репрессияләрен хәзерге тарихчылар «зур террор» дип атый. Ул чорда сәяси сәбәпләр белән 1 миллион 372 мең 382 кеше кулга алынган, шулардан 681 мең 692 кеше атып үтерелгән.

Репрессиягә дучар булган кешеләр үзләре генә түгел, аларның бөтен гаилә әгъзалары да зур хәсрәт кичергән. Чиксез кырыс кануннар буенча, әтиләре белән берлектә, җәмәгатьләре һәм балалары да эзәрлекләнгән. Совет хакимияте чорында репрессияләнгәннәргә һәм аларның балаларына XX гасыр ахырыннан алып реабилитацияләнү белешмәләре бирелеп килде. Татарстаннан кулак буларак сөргенгә җибәрелгән затларның бер өлеше 1990 нчы елларда исемлекләр буенча күпләп һәм җәбер күргән кешеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча аерым да реабилитацияләнгән. Ләкин хәзергәчә акланмаганнары да аз түгел.

---

[2] Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы. Унтугызынчы том: административ репрессияләр. Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш районнары = Книга памяти жертв политических репрессий. Том 19: административные репрессии. Агрызский, Азнакаевский, Аксубаевский, Актанышский районы. – Казан: «Хәтер китабы» нәшр., 2007. – Б. 4.

[3] Шунда ук. – Б. 6.

***

Бу китаптагы материалларның күпчелеге авылларда яшәгән, совет хакимлеге урнашкач дәүләт тарафыннан талану, җәберләнү, кулак итеп мөлкәтләре тартып алыну һәм читкә сөрелү кебек хәсрәтле хәлләрне кичергән кешеләрнең язмышларын чагылдыра. Шуңа күрә вакыйгаларның үз чоры авылларындагы гомуми торышы белән танышыйк.

Игеннәр уңышы начар булуга карамастан, 1929 елда Татарстандагы крестьяннардан икмәк туплау планы шулкадәр арттырылган ки, авыл халкына үзе җыеп алганнан икеләтә-өчләтә күбрәк микъдарда икмәк тапшыру йөкләнгән. 1929 елның көзеннән Татарстанда крестьяннарны кысу көчәйгән. ВКП(б) Үзәк Комитеты 1929 елның ноябрендә үткәргән Пленумында колхоз төзелеше мәсьәләсе тикшерелеп, социализм ягына кискен борылыш – хуҗалыкларны күмәкләштерү булырга тиеш дип билгеләгән. Шуннан соң ил күләмендә колхозлар оештыруга әһәмият көчәйгән. Бу хәрәкәт кулакларга каршы көрәшне тагын да кискенләштерү белән бергә алып барылган. ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты шул елның 8 декабрендә авыл хуҗалыгын тоташ коллективлаштыру турында карар кабул иткән. Менә шушы карарлар нигезендә колхозларга мәҗбүриләп кертү тизләтелгән. Кайбер урыннарда 1930 елның язгы чәчүенә йөз процент күмәкләштерү максат итеп куелган.

Нәтиҗәдә, 1929 елның 1 декабренә крестьян хуҗалыкларының 18 проценты коллективлаштырылган. 1930 елның гыйнвар аенда гына Татарстанда 500 яңа колхоз төзелгән.

ВКП(б) Үзәк Комитеты 1930 елның гыйнвар ае башында «Коллективлаштыру таләпләре һәм колхоз төзелешенә дәүләт ярдәме чаралары турында» һәм шул ук айның ахырында тагын бер – «Тоташ коллективлаштыру районнарында кулак хуҗалыкларын бетерү чаралары турында» карарлар кабул иткән. Колхоз төзелешенә каршы төп көч – кулак дип белдерелгән. Кулакларның мал-мөлкәтен тартып алырга һәм аларны тоташ күмәкләштерү районнарыннан читкә күчерергә рөхсәт ителгән.

1930 елның гыйнвар аенда бөтен ил һәм республика мат-

бугатында кулакларны сыйныф буларак юкка чыгаруда коры сүздән гамәли эшкә күчәргә өндәгән агитацион мәкаләләр басылган. Шулай итеп, көчләп күмәкләштерү киң колач алган, кулакларны сыйныф буларак бетерү – бу эшнең аерылгысыз бер өлеше булып торган. Партия фәрманын үтәгәндә каршылык күрсәткән өчен кулга алу белән куркыту, зинданга ябу, буйсынмаган крестьяннарны сайлау ирегеннән мәхрүм итү, яла ягу, баерак күршеләренә каршы бүтән авылдашларында дошманлык уяту һәм башка шундый күптөрле чаралар кулланылган. Кулаклар гына түгел, урта хәлле, хәтта ярлы крестьяннар да кулга алынган яки башка төрле репрессияләргә дучар ителгән.

Февраль аенда партия Өлкә Комитеты пленумы язга кадәр хуҗалыкларның 80 процентын, ә көзен тулысынча берләштерергә күрсәтмә биргән. Шушы айның уртасында Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык комиссарлары советы «Татарстанда кулакларны сыйныф буларак бетерү» турында карар кабул иткән. (Ул ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын кабатлаган). Бу документ буенча кулак хуҗалыклары өч төргә бүленгән: беренче төргә эләгүчеләр мал-мөлкәтеннән мәхрүм ителеп, илнең халык аз яши торган районнарына озатылырга тиеш булган, икенче төрен – республиканың башка кантон һәм районнарына, өченчесен – кантоннар һәм волостьлар эчендә бүтән җиргә күчерү каралган.

Халык өчен хәвефле ул чорда милләттәшләребез язмышы өчен ифрат борчылган мәшһүр татар әдибе һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый эмиграциядәге татар матбугатында 1930 елның февралендә «Татарстан тоташтан колхозлаштырыла» исемле мәкаләсендә болай язган: «...Татар-башкорт коммунистлары да башка юл эзләп тормаячаклар, шул Сталин юлыннан барачаклар; алар да Татарстандагы 14% чамасындагы атлы-сыерлы, карыны тук, тырыш татарларның атларын, сыерларын, җирләрен, [авыл хуҗалыгы] машиналарын алып, аларны хәерчеләндерәчәкләр; үзләрен туган илләреннән куып, Себернең тайгаларына, Соловкиның суыкларына җибәрәчәкләр; ачлыктан, суыктан, чирдән үлеп бетүләренә юл

хәзерләячәкләр; шуларны барысын да гүя күмәк хуҗалыкларны корыр өчен, бер ел эчендә эшкә ашыру юлында эшләячәкләр»[4].

Республикадагы кулак хуҗалыклары 1929 елда бары тик 2,6 процент дип исәпләнгән булса, 1930 елның март ае башында кулак дип таркатылган хуҗалыклар 23 процентны тәшкил иткән. Күмәкләштерү темплары буенча Татарстан илдә өченче урынга чыккан. «Тоташ коллективлаштыру» барышында, рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә генә дә, 13,7 мең крестьян хуҗалыгы таркатылган, 45,5 мең кеше «кулак» дип читкә сөрелгән. Йөзләрчә дин әһеле төрмәләргә ябылган. Кискен көрәштә күмәкләштерүне уздыручылар да, кушканны үтәүчеләр дә һәлак булган.

Авыл хуҗалыгын яңача кору белән бәйле киеренкелекне, шул чорда бөтен совет илендә күзәтелгән колхоз төзелеше буенча партия һәм совет хөкүмәтенең сәясәтен бозуларны чикләү йөзеннән И.Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» исемле махсус чыгышы 1930 елның 2 мартында радио аша тапшырылган һәм «Правда» газетасында басылып чыккан. Ул шулай ук зур форматлы, махсус стена газетасы рәвешендә татар телендә дә бастырып таратылган. Шуннан соң крестьяннар авылы-авылы белән колхозлардан чыкканнар һәм яңа оештырылып килгән күмәк хуҗалыклар таркалган яисә таркалу чигенә җиткән. (Колхозлардан крестьяннарның күпләп чыгуына, имеш, кулаклар гаепле дип табылган). Шул ук 1930 елның март ае ахырында кулакларга каршы көрәш көчәю сәбәпле, крестьяннар яңадан колхозларга керә башлаганнар. Вакыйгалар 1931 елның көзендә яңадан куерган.

Әлеге барлык вакыйгалар дингә һәм дин әһелләренә каршы көрәш белән бергә алып барылган. Эшче-крестьяннарның дошман сыйныфы булган дин әһелләрен совет хөкүмәте төрле ысуллар белән җәберләүне үзенең төп сәяси юнәлешенең берсенә әйләндергән. Мулла һәм мәзиннәрне шактый зур күләмдәге салымнар белән җәфалаганнар.

[4] Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т. 10: публицистика / төз. Г.Хөснетдинова. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 112–113.

1927 елның язында республиканың үзәк газетасы «Кызыл Татарстан», «Крәстиян гәзите» һәм бүтән матбугат органнары битләрендә дингә каршы пропаганда киң җәелгән. Руханилар белән көрәшне көчәйтергә өндәгән язмалар еш чыккан. 1928 елның җәендә төрле төбәкләрдәге мулла һәм мәзиннәрнең үз вазифаларыннан баш тартулары турында хәбәрләр һәм игъланнар басыла башлаган. Аларның күбесе мулла яки мәзиннең үз исеменнән («Мин, фәлән районның фәлән авылы мулласы... муллалыгымны ташлыйм» рәвешендә) бирелгән. Өстәвенә, игълан иясе газетада бастырган өчен акча түләргә мәҗбүр ителгән. Дәүләтнең көчле салымнар белән кысуы һәм административ басымы астында эшләнгән бу чара совет властенең дингә каршы көчле пропагандасы булган. Халык имамнарның бу юлга үз теләкләре белән бармавын белсә дә, газетада язмасы чыккан кешеләргә карата мөнәсәбәтен барыбер үзгәрткән. Газеталарда мондый игъланнар елдан-ел күбәя барып, 1929 елның көзеннән 1930 елга хәтле берьюлы иллешәр һәм йөзгә якын мулла-мәзиннәрнең үз рухани вазифаларын туктатуларын белдергән исемлекләр чыгып торган.

Газеталарда 1929 елның башыннан мәчет биналарын мәгариф һәм мәдәни оешмаларга алырга кирәклеге хуплап һәм күпләп языла башлаган, андый үрнәкләр һәм мисаллар макталган. Хөкүмәт карамагына алынган мәчетләрнең манараларын кисү халыкка аеруча авыр тәэсир иткән.

Кулак дип тәгаенләнгән кешеләр (күбесе гаиләләре белән) Архангельскига, Беломорканалга, Коми Республикасына, Уралдагы һәм Себердәге лагерьларга, зур төзелешләргә, шахталарга һ.б. урыннарга сөргенгә җибәрелгәннәр.

Чит җирләргә сөрелгән кулакларның кул көчләре белән бөек илнең индустриясе күтәрелгән, яңа промышленность үзәкләре корылган. Беломорканал, Магнитогорск каласы һәм совет чорының башка мәшһүр гигантлары нәкъ шундыйлардан. Галимнәр язуынча, Магнитогорскига Татарстанның барлык районнарыннан диярлек 60 меңгә якын кеше сөрелгән һәм шуларның күпчелеге татарлар булган. Ә Идел-Урал буйла-

рындагы бүтән республикалар һәм өлкәләрне дә исәпкә алганда, 1931–1932 елларда Магнитогорскига йөз меңгә якын татар сөрелгән. Тарихчы һәм әдибә Фәүзия Бәйрәмова бу хакта болай язды: «1931 елның җәендә Татарстан авылларыннан Магниткага сөрү үзенең иң югары ноктасына җитә, чөнки 1932 елның башында биредә беренче чуен кою миче эшли башларга тиеш була, ә төзелешкә кеше кирәк, кеше кирәк! Һәм һәр ай саен Татарстаннан 10–12 мең колны буш далага китереп аударалар. Аларга яшәр өчен брезент палаткалар бирәләр һәм икенче көнне үк конвой белән эшкә куалар. Иң авыр эшкә – җир казырга, кирпеч салырга, бетон ташырга, домна мичләрен төзергә... Бу кол татарларны эшкә мылтык белән алып баралар, мылтык астында алып кайталар. Яшәү урыны – чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган зона, кулда бер документ юк, хокук юк, тел белү юк. Бу кышны сөрелгән халык чүпрәк шалашларда, җир асты куышларында, баракларда чыга, 10 яшькә кадәр булган балаларның барысы да диярлек ачлыктан һәм өшеп үлеп бетә. Ул кышны салкынлык 40 градуска җитә, ул кышны бөтен Магниткада тиф, кызамык, түләмә, туберкулез чирләре котыра, үлүчеләр саны туучыларга караганда 10 тапкыр артыграк була! Аларның бөтенесен бергә шәһәр янындагы чокырларга ташлыйлар...»[5]. Ф.Бәйрәмова шул елларда Магнитогорскида эшләгән америкалы язучы Джон Скотт китабыннан өзек тә бастырган. Анда, аерым алганда, палатка шәһәрчегендәге кешеләрнең саны 1933 ел ахырына 35 меңгә җиткәнлеге әйтелгән; 1932/33 еллар кышында 10 яшьтән кече балалар бөтенесе үлеп беткәнлеге, беренче көннән үк 12–14 яшьтән өлкәннәр барысы да сак астында төрле эшләргә йөртелгән булуы язылган[6].

Ул дәһшәтле кышта Магнитогорскида 11 мең кеше һәлак булган дигән мәгълүмат бар. Магнит шәһәрендәге халык үлеменә күрә, аны Ленинград блокадасына да тиңлиләр. Андагы бакракларда һәр кешегә 60 квадрат сантиметр мәйдан туры

[5] Бәйрәмова Ф. Мәдхия абыстай хатирәләре // Шәһри Казан. – 2006. – 22 март.
[6] Джон Скотт. За Уралом: американский рабочий в русском городе стали. – Москва, Свердловск, 1991. – 278 с.

килгәнлектән, алмашлап һәм утырып йоклаганнар. Тоткыннар эш вакытында һәм барак-палаткаларында даими рәвештә 2–4 кешелек кораллы сак астында тотылганнар.

Магнитогорскига кулак итеп җибәрелгән чаклар турындагы куркынычлы хатирәләр матбугатта да күп басылды. Шул хәлләрне кичергән бер мулланың кызы сөйләгәннәрдән берничә җөмләсенә генә игътибар итик: «Коры кырга китереп ташланган татарлар тифтан, ачлыктан чебен урынына кырылдылар, урамда, эштә өшеп үлделәр. Баракларның идәне җир, түбәсе ябылып бетмәгән, яңгыр-кар сулары өскә ага... Баракта дүрт сәке, һәр гаиләгә икешәр метр урын, чаршау-пәрдә корырга ярамый, комендант күрсә, аларны өзәләр. Кеше ач, төнлә бәдрәфкә чыкканда янчык белән ипиләрен тотып чыгучылар да була, анда да талыйлар, баракта калдыру да куркыныч. Шунда бәби табалар, шунда үләләр, аларны җыючы юк, өсләреннән бетләр чабышып йөри. Төзелештә эшли алмаган картларны, татар муллаларын бәдрәфтән тизәк түгәргә мәҗбүр итәләр. Ат урынына үзләре җигелеп бу нәҗесне 12 чакрымдагы далага илтеп ташлыйлар иде. Бу хәлләргә түзә алмыйча юләрләнүчеләр дә күп булды, кешене шул хәтле мәсхәрә итәләр иде...»[7]. Бу карчык Магнитогорскидагы дәһшәтләргә чыдамыйча качып китүләре, тотылып кире кайтарылулары, ачлык һәм бүтән газапларны да бик ачынып сөйләгән.

Татарстаннан кулак итеп сөрелгән кешеләрнең дәвамчысы Рафаил Бакировның китабында[8] язылган истәлекләр дә тетрәндергеч.

Дәһшәтле заманның мәхшәрле хәлләре бу китаптагы хатирәләрдә дә тасвирланды. Мәсәлән, Магнитогорскига җибәрелгән Миңнәхмәт Шәймәрдановның күп еллар узгач туган авылына кайтып килергә рөхсәт булып, кайтып килгәннән соң: «Анда да ачтан үлгәннәр, ярый монда җибәргәннәр, монда әйбәт яшәгәнбез», – дигән сүзләре тетрәндергеч. Бу – авылда яшәгән, ирекле дип саналган тормыштагы халыкның

[7] Бәйрәмова Ф. Мәдхия абыстай хатирәләре // Шәһри Казан. – 2006. – 22 март.

[8] Бакиров Р. Живые родники. – Магнитогорск, 1999. – 232 с.

чын хәлен белдерә. Тоткынлык җәзасын үтеп, туган җиренә кайткан кешеләрнең тәмам гаҗизлеккә төшеп, рухи газап кичергәнлекләре Г.Апанаевка бәйле язмада да ачык күренә. Ул Казанга кайткач тамак туйдыру хәсрәтеннән гасабиланып, мондагы тормыштан концлагерьдагы вакытын өстенрәк куйган. Болар, әлбәттә, никадәр парадокслы булсалар да, шул заманның чынбарлыгын ачык күрсәтә. Әтиләре белән 1931 елда Магнитогорскига сөрелгән (ул вакытта 10 яшьлек) шагыйрь Гамил Афзал Актаныш районындагы туган авылы Такталачыкка 1959 елда кайткан һәм туган нигезләре таркалып, берни дә калмаганны күрү тәэсирендә болай дип язган:

Мылтык белән куган идең мине,
Мөлкәтемне талап туган ягым.
Сөргеннәрдә каргамадым сине,
Ватан диеп, сагынып кайттым тагын.

Баемагансың син безне талап,
Кызыл талаучылар үлгән инде.
Менә, йөрим туган җирне карап, –
Туган авыл тәмам бөлгән инде[9].

Колхозларда советка каршы дошман элементларны һәм коткы таратучыларны эзләү, кулакларны ачыклауның тагын бер дулкыны 1932 елның көзеннән 1933 елның язына кадәрге арада күтәрелеп алган.

Ул заманнардагы хәлләрне гомуми генә күзаллагач, ихтыярсыз, Россия империясенең чын-чынлап «халыклар төрмәсе» дип бәяләнүе искә төшә һәм бу гыйбарәнең СССР чорына да туры килгәнлеге аңлашыла.

Эшче көчләрне гадәттән тыш кырыс рәвештә туплап, бушка эшләүче тоткыннар хезмәтен куллану – индустрияләштерү максатлары белән акланган дигән караш безнең ил тарих фәнендә озак еллар дәвам итте. Ләкин Сталин чорында халыкның аерым өлешләрен көчләп күчерү һәм тулаем депортацияләү рәвешендәге террор сәясәтен соңгы заман

---

[9] Гамил Афзал. Гомер кичүләре: шигырьләр. – Казан: «Рухият» нәшр., 2000. – Б. 46.

белгечләре мәгънәсезлек дип бәялиләр. Кулакларны сөргүгә, лагерьлар һәм махсус посёлокларны асрауга тотылган чыгымнар дәүләтнең тоткыннар хезмәте нәтиҗәсендәге керемнәреннән күбрәк булган. 1930 нчы еллардагы индустриаль ыргылыш һич тә аклап булмый торган күп миллионлы корбаннар белән түләнгән. Гомумән, XX гасырда үз иленең халкын бу кадәрле күпләп эзәрлекләгән хакимиятләр дөнья күләмендә берничә генә (икенчесе – Камбоджа-Кампучия).

Утызынчы еллар башында Архангельск якларына сөрелүчеләрнең яртысы һәлак булганын һәм ул чордагы фаҗигаләрнең турыдан-туры корбаннары күп миллионнар белән исәпләнгәнен уйлаганда тәннәр чымырдый. СССР чорындагы тормышны әкияти бәхетле итеп күзаллап, аны сагынучылар совет чынбарлыгының менә шундый кара якларын бөтенләй аңламый, ахрысы.

***

Бу китапта 1930 нчы еллардагы репрессияләргә бәйле кульязмалар туплап бирелгән булса да, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә башка чорлардагы эзәрлекләүләргә бәйле кульязма истәлекләр дә барлыгын искәртергә тиешбез. Мәсәлән, Мөхәммәтгали Шәриповның 1919 елда совет хакимиятенә каршылык күрсәтүдә гаепләнгән муллалар һәм башка кешеләр язмышын чагылдырган хатирә дәфтәре шундыйлардан. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «679т» шифры белән саклана торган әлеге кульязма совет властенең беренче елларында ук кулланылган репрессив чараларның вәхшәт дәрәҗәсен чагылдыра[10].

[10] Бу дәфтәрнең тексты һәм аның турындагы мәкаләләребез басылды: Шәрипов М. Гүрләргә керде безнең башлар: «контрреволюционер» мулла язмалары // Мирас. – 1996. – №№1–2. – Б. 196–205; №3. – Б. 107–109; №4. – Б. 93–99; №5–6. – Б. 221–231; Шәрипов М. Гүрләргә керде безнең башлар: «контрреволюционер» мулла язмалары. Тарихи мирас. – Нефтекамск, 2008. – 78 б.; Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 14–16, 74.

Дәфтәрнең иясе – татар мулласы М.Шәрипов (1876–193?) хөкүмәткә икмәк тапшырмауда гаепләнеп, 1919 елның декабрендә, аннан соң 1920 елның маенда, 1921 елның февраль һәм октябрь айларында кулга алынып эзәрлекләнгән. Соңгысында аның дүрт иптәше атарга, ә тагын өчесе белән үзе бишәр елга Уфа контрреволюцион лагерена ябарга хөкем ителгән. Ул җәза вакытын тутырып авылына кайтканнан соң берничә ел узгач, кулак буларак, ике кияве белән Архангельск ягына сөрелгән һәм шунда һәлак булган. Совет зинданнарында укымышлы муллаларның, хәтта 70–80 яшьләрендәге имамнарның ябылу күренешләре, тоткыннарның төрле авырулардан күпләп үлүләре һ.б. Мөхәммәтгали хәзрәт дәфтәрендә тасвирланган.

Кулъязмаларга бәйле, археография сериясендә басылып чыккан башка китапларыбызда совет чорында репрессияләнгән муллалар һ.б. шәхесләр турында язылган яки телгә алып үтелгән очраклар булган иде. Мәсәлән, Саба районының Югары Шытсу авылында 1918–1928 елларда имамлык иткән һәм шул чорда Мамадыш өязенең мөхтәсибе вазифасын үтәгән Хатыйп Закировның 1931–1934 елларда тоткынлыкта булганлыгы искәртелде[11]. Тумышы белән Иске Мичән авылыннан булган Хатыйп Закиров (1881–1946) колхозга каршы агитациядә гаепләнеп, 1931 елның 6 май көнендә кулга алынган һәм шул ук елның 12 сентябрендә 58 нче маддә буенча 8 елга концлагерьга хөкем ителгән. Калган җәза вакытын үтү өчен 1932 елның 7 сентябрендә Төньяк крайга җибәрелгән. Туган җиренә кайтып, 1946 елда вафат булган. 1990 елның май аенда акланган.

Ижевск шәһәре мәчетләренең һәм имамнарының 1930 нчы еллардагы катлаулы язмышын чагылдырган кулъязма һәм документаль материаллар турында да язган идек[12].

---

[11] Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 24–25. Хатыйп муллага адресланган ике хат тексты искәрмәләр белән бастырылды: Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2018. – Б. 95–97, 99, 143–145.

[12] Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 29.



Мөхәммәтгали Шәрипов кулъязмасы
(Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә
«697т» шифры белән саклана)

1920 нче еллар ахырында – дингә каршы көрәшнең котырган вакытында бер авыл мулласының улын җаваплы итеп билгеләп, халыктан дини (гарәп язулы) китаплар җыю вакыйгасы шулай ук совет чоры дәһшәтләре чылбырыннан[13].

«Татар археографиясе» сериясенең 8 нче басмасындагы Кырым сәяхәтнамәсенә багышланган текстта, аз күләмдә булса да, 1930 нчы еллардагы репрессияләр, кулак итеп сөрүләр, мәчетләрне ябу һәм муллаларны җәберләү кебек рәхимсез күренешләр искә алынган[14].

Сериянең 14 нче чыгарылышында туган төбәге һәм нәселе тарихын өйрәнгән кызыклы шәхес Мөхәммәтгариф мулла Морадый (1883–1937) язмалары дөнья күрде һәм аның турында мәгълүмат бирелде. Ул 1920 нче елларда татар авылындагы кискен үзгәрешләрне дә – комсомол яшьләрнең дингә һәм руханиларга каршы тупас мөнәсәбәтләрен, тәртипсез гамәлләрен (бозык җырлар белән аптырату, тәрәзә-коймалар вату, мәчеткә кереп әшәкелек кылу һ.б.) теркәгән. Ул үз авылының башка муллалары һәм байлары белән бергә 1929 елдан алып көчле эзәрлекләнүгә дучар булган. Беренче мәртәбә 1930 елда хөкемгә тартылган. 1937 елда яңадан кулга алынган һәм атып үтерелгән[15].

Күренекле татар драматургы, репрессия корбаны Кәрим Тинчуринның (1887–1938) сәхнә өчен иҗат иткән, матбугатта басылып чыкмаган өч әсәре археографик сериянең 15 нче һәм 16 нчы китаплары буларак нәшер ителгән иде[16]. Автор әсәрләренең хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары 1937 елда Тинчуриннар фатирындагы тентү вакытында могҗиза белән генә исән калганнар.

---

[13] Шунда ук. – Б. 49–50.

[14] Сәяхәтнамәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2011. – 19–50.

[15] Гали авылы тарихы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2014. – Б. 25–28.

[16] Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2015. – 192 б.; Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2015. – 108 б.

Бөек Ватан сугышы хатлары авторларыннан укытучы Мирза Тархановның (1897–1984) дәһшәтле 1937 елда репрессияләнгән булуы, катлаулы язмышы һәм фронтта штраф батальонында сугышып яралануы һ.б. турында яздык[17].

«Татар археографиясе» сериясенең 26 нчы китабында мәшһүр рәссам һәм сынчы Бакый Урманченың 1929 елда кулга алынып, 5 елга хөкем ителүенә һәм Соловецк монастырендә тоткынлыкта булуына бәйле мәгълүматлар басылды. Шунда ук башка репрессия корбаннарының да исемнәре телгә алынган[18].

Гаҗәеп нәфис шигырьләр иҗат иткән мулла Мөхәммәтхаррас Каратайиның (1861 елда туган) моңарчы билгеле булмаган әсәрләре сериянең 27 нче китабында дөнья күрде. Бу хәзрәт тә 1930 елда кулга алынып, гаиләсе белән Төньяк крайга сөрелгән һәм шуннан кайтмаган. Ә аның шигырьләре безнең көннәргә кадәр Мөхсин мулла Гобәйдуллин (1870–1930) күчермәсендә сакланып калган. Бу имам шулай ук 1929 елда төньякка сөрелеп, 1930 елда лагерьда һәлак булган[19].

Югарыда санап үтелгәннәрдән күренгәнчә, «Татар археографиясе» басмаларында моңа кадәр совет чоры репрессияләренә багышланган махсус китап булмаса да, фаҗигале сәхифәләр турында шактыенда язылган. Гомумән, татар археографиясенең совет елларындагы кайсы гына мәсьәләсенә кагылсаң да, ул заманның кара һәм караңгы якларына юлыгырга туры килә.

Археографик экспедицияләрдә татарлар яшәгән төбәкләрнең һәммәсендә динне мыскыллау һәм муллаларны-байларны җәберләү турында бик күп вакыйгалар ишетә идек. Төп максатыбыз кулъязма истәлекләрне туплау булганга күрә, андый хатирәләрне, кызганычка каршы, теркәү белән шөгыльләнмәдек. Шулай да, кайбер вакыйгаларны язып алдык.

---

[17] Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2020. – Б. 10, 191–196.

[18] Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2020. – 218 б.

[19] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 203–211.

Мәсәлән, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән 1994 елгы фәнни-археографик экспедициясе вакытында Башкортстанның Борай районындагы Силәсау авылында булган идек. Пенсиядәге укытучы, элекке мәктәп директоры Арслангали абый Муллаяров (1924 елда туган) үз гаиләләре кичергән ачы тарихны сөйләде. Аның әтисе Миңнетаһир Мөхәммәтгали улы Муллаяров (1878–1937) Иске Бикмәт авылы мәдрәсәсендә укыган, XX гасыр башында имамлыкка указ алып, үз авылларында мулла булып торган, мәдрәсә тоткан. Биш баласы дөньяга килгән. Совет золымы чорында – 1929 елда хөкемгә тартылып, өч ел төрмәдә булып кайткан. Мөлкәте (шул исәптән, барлык китаплары) конфискацияләнгән. Аннан соң озак тормыйча, 1937 елда яңадан кулга алынган һәм хөкем ителгән[20]. Инде бүтән кайтмаган, һәлак булган. Аның 6–7 кешелек гаиләсе түбәсе эшләнеп бетмәгән, түшәм белән генә ябылган, яңгыр сулары үтә торган өйдә ун ел дәвамында (1940 елга хәтле) бик зур мохтаҗлыкта гомер иткән. Ул елларда бернинди кош-корт һәм мал-туар асрый алмыйча, гаять авырлыкта көн күргәннәр. Миңнетаһир мулланың өлкән улы да 1930 нчы елларда (21 яшендә) репрессияләнгән. Арслангали абый биргән кулъязмалар арасында әтисенең лагерьдан язган хатлары да бар иде. Алар хәзерге вакытта Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана.

Тагын бер аянычлы язмышны монда искә алыйк. Лаеш районындагы данлыклы Хәерби авылының Ситдыйк Гали улы Йосыпов (1872–1933) таза тормышлы кешеләрнең берсе булган. Хуҗалыгында 3 ат, 5 сыер асраган, Мишә елгасы буенда умарталык тоткан. Кулаклыкта гаепләп, сөрүләр башлангач, умарталыклары колхозга алынган, үзләре йортларыннан куып чыгарылып, ул сүтелгән һәм колхозга ферма өе итеп корылган. Әйберләре, киемнәре, хәтта кызлары бирнәгә дип үзләре

---

[20] Электрон чыганак мәгълүматларына караганда, мулла Таһир Муллаяров 1937 елның 5 августында кулга алынган һәм 58 нче маддә буенча 10 елга хөкем ителгән. 1989 елда акланган.

тукыган эскәтерләре, сөлгеләре дә талап алынган. Соңыннан ул киемнәрне талаучылар башлыгының хатыны һәм балалары киеп йөргән[21].

Фаҗиганең иң хәтәр һәм дәһшәтле өлешен Ситдыйк бабайның оныклары Гөлсем һәм Илнура апалар (1937 һәм 1954 елларда туганнар) болай дип сөйләделәр. Авылдан читкә сөрелү бәласеннән котылып кала алмаячакларын фәһемләп, Ситдыйк бабай бик гасабиланган. 1933 елның бер көнендә мәчеткә баргач, авылның иң булдыксыз хәерчесеннән: «Син бит кулак, ник килдең монда? Мәчеткә аяк басарга тиеш түгелсең!» – дигән авыр сүзләр ишетү, шул адәм актыгы башыннан түбәтәен бәреп төшереп, аяк астына салып таптавы болай да рәнҗетелгән, мыскылланган Ситдыйк бабайның күңеленә өстәмә яра салган. Шушы хәлдән соң ук ул, түбәнсетүләргә түзә алмыйча, катгый бер карарга килгән һәм авылның мулласына мөрәҗәгать иткән. «Берәү үз-үзен ни рәвешле юк итсә, мордар булып саналмас?» – дип киңәш сораган. Бик дини, тәкъва кеше буларак, Ситдыйк бабай мордар китүнең (ягъни, үз-үзеңә кул салуның) зур гөнаһ икәнлеген анык белгән. Мулла: «Әгәр аяклары бәйләнгән булса, шул вакытта мордар дип саналмас», – дигән. Моны ишеткәч Ситдыйк Йосыпов өенә кайтып аякларын бәйләгән дә, муеныннан пычак белән суелып, үз-үзен корбан иткән. Икенче көнне мәхкәмәдән боларны кулак итеп сөрмәскә дигән карар килеп ирешкән.

Аны ничек тә җибәртмичә калдыру өчен шул чорда җаваплы урында эшләгән кияве тырышкан – Ситдыйкның өлкән улы Кызыл армиядә кавалериядә булып, бүләкләнгәнлегә сәбәпле, Йосыповларны сөрмәскә дигән карар чыгартуга ирешкән[22]. Әмма... тәкъдир.

---

[21] Галимуллина Г., Насибуллина А. Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр. – Казан: ТР ФАнең Татар. энцикл. һәм төбәкне өйрәнү ин-ты, 2019. – Б. 281. Бу китапта Йосыпов фамилиясе ялгышлык белән Юнысов диелгән.

[22] Хәерби авылы тарихына багышланган китапта утызынчы елларның фаҗигале корбаны Ситдыйк Йосыповның нәсел дәвамчылары турында мәгълүмат та бар: Галимуллина Г., Насибуллина А. Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр... – Б. 280–283.

Халкыбызның язмышында менә боларга охшаш әрнеткеч хәлләр-вакыйгалар да аз булмаган бит.

***

Археографик материаллар арасында 1930 нчы еллардагы фаҗигаләргә турыдан-туры бәйле кульязмалар (хатирәләр, хатлар, документлар, бәет һәм мөнәҗәтләр) аз түгел. «Татар археографиясе» сериясенең бу чыгарылышында нәкъ шундый язма истәлекләрнең текстлары тупланды. Әлеге материаллар 1930 нчы еллардагы хәсрәтләрне үз башларыннан кичергән, Сталин чоры лагерьларын үткән кешеләр, шәфкатьсез чорның шаһитлары тарафыннан кәгазьгә теркәлгән булуы ягыннан әһәмиятле. Китапта урын алган текстларның бер өлеше хатирәләр рәвешендә, ә күпчелеге эчке кичерешләрне хисле һәм моңлы итеп ача торган мөнәҗәт һәм бәет жанрларында язылган. Шулай ук лагерь чорына караган хатлар да бар. Колхозлашу чорындагы кулак дип җәберләүләр, күтәрә алмаслык салымнарга бәйле гаризалар да ул замандагы киеренкелекне тулырак күзалларга ярдәм итә. (Төгәлрәк әйткәндә – гаризаларның караламалары, чөнки төп нөсхәләре адресатларына тапшырылган). Утызынчы елларда булып узган дәһшәтле күренеш – мәчет манараларын кисү фаҗигасенә багышланган бәетләр дә җыентыкка кертелде.

Китаптагы текстлар мөмкин кадәр хронологик эзлеклелекне саклап бирелде. «Манара бәетләре» ахырда урнаштырылды. «Манара бәетләре»нең археографик һәм текстологик җәһәтләрдән әһәмиятләре зур. Чөнки алар үз чорларында халык арасында бары тик язма рәвештә һәм телдән сөйләнеп кенә таралган, XX гасыр ахырына кадәр нинди дә булса китапларда яисә матбугатта басылмаган.

Бирелгән текстлар арасында Мәләкәс шәһәре имамы Гатаулла хәзрәтнең 1936 елда язган хатында мөфти Ризаэтдин Фәхретдин вафатына бәйле мәгълүмат булуы мөһим.

Кульязмаларның кайберләрендә төгәл еллары күрсәтелмәгән. Андый текстлар чама белән даталанды. Берничәсенең

авторлары үзләренең ничә яшьтә икәнлекләрен белдерүгә карап, язылу вакытын якынча билгеләдек. Элек, бигрәк тә репрессиягә дучар булган аерым бер кешенең туган елы төрле чыганакларда төрлечә язылган булуын да истә тотарга кирәк. Тагын шунысы мөһим, татарлар элекке чорда үзләренең яшьләрен мөселманча (һиҗри) ел исәбе буенча санаганнар. Ягъни, хәзергечә григориан ел исәбенә караганда, яшь саны күбрәккә туры килгән. (Мәсәлән, григориан елы белән 66 яшендәге кешенең мөселманча яше 68 була).

Бер текстта язылганча, 1930 ел башыннан «һәр урында гомуми колхозлаштыру дәвам итә, һәр урында мәсҗидләр ябыла, кулаклар белән бергә мулла-мөәзиннәр дә ябыла, мөлкәтләре мөсадәрә кылына иде. Кулакларның гаиләләре көтү-көтү сөргенгә читкә озатыла иде». Гомумән, кешеләрнең гомер иткән өйләреннән куып чыгарылулары – хәтәр заман чынбарлыгы. Язмаларның кайберләрендә үз өйләрен бушату өчен ике сәгать вакыт бирелгәнлеге әйтелгән. Өстәвенә, андыйлар иң фәкыйрь кешеләрнең начар йортларына урнашырга мәҗбүр ителгәннәр. Мәсәлән, «ихатасыз һәм хаҗәт үтәргә һичбер урыны булмаган, мунча кебек тотен тула торган өенә чыгарып, аны минем өйгә керттеләр» дигән юллар шуңа дәлил. Салымналоглар белән тәмам интектерүләр, гаҗизлеккә төшерүләр гаиләләрне турыдан-туры ачлыкка дучар иткән. Йортҗирләреннән һәм мал-мөлкәтләреннән мәхрүм итеп, эшелоннарга төяп, ерак һәм чит-ят җирләргә куу мәхшәре – коточкыч. Бу да «таң атып, көн җәелгәнче», тиз арада башкарылган. Шул ук совет властенә хезмәт иткән, Кызыл Армиядә булып кайткан ир-атларның гаиләләрен дә читкә сөрүләр – җан әрнетерлек фаҗига. Аерым бер волостьтәге авыллардан берьюлы «кулак гаиләләре барлыгы 80 ат йөге кемсә озатылып, безнең авылдан җибәрелгәннәрнең байтагы шәрә диярлек, киемсез», алар арасында 80 яшьлек карт муллалар һәм ахуннар булганлыгы, шулай ук «безнең өскә кияргә бернәрсә югые. Безне шәрә, ялангач җибәргәннәр» дигән хатирәләр трагедиянең киңлеген һәм газаплауның шәфкатьсезлек дәрәҗәсен күрсәтә. Халыкны

шул рәвешле җәфалаган җирле хакимият вәкилләренең үзләре дә берничә елдан җәзага тартылулары – системаның бөтенләй рәхимсезлеген һәм кансызлыгын дәлилли. Кулак итеп сөрүләр вакытында качып китүчеләр, хәтта ерак Архангельск ягына сөрелгәч тә, аннан качып кайтып, яңадан җибәрелгән һәм җәза вакытыннан соң авылына кайтып үлүчеләр турында шул хәлләрнең шаһитлары язган истәлекләр бик гыйбрәтле.

Текстларда теркәлгән һәр вакыйгага карата өстәмә аңлатмалар язарга мөмкин. Аллаһы Тәгалә биргән сәләтләре һәм шәхси тырышлыклары нәтиҗәсендә олуг гыйлем ияләре, югары дәрәҗәдәге тәрбия-әхлак үрнәкләре булып җитешкән зыялы затларның башка сыймаслык түбәнлекләргә төшерелеп мыскылланулары таң калырлык. Халык арасында зур абруйга ирешкән Коръән-хафизларның һәм мөхтәсибләрнең лагерьлардагы салкын һәм бетле баракларда асралуга дучар ителүләре һ.б. шундый вәхшилекләрне күңел бик авыр кабул итә. Данлыклы муллаларның совет золымына төшерелгәч чарасыз калып, «кулдан килгән бер төрле дә һөнәр юк (ул вакытта чабата да ясый белмидер идем)» дигән сүзләре, каравылчы һәм урам себерүче булып эшләүләре, үзләре имамлык иткән туган авылларына сөргеннән кайткач баз (землянка) казып, шунда гаилә белән җан асраулары, хәерче урынына теләнеп йөрү көненә калулары, аларның иректә калган хәләл җефетләре – «мулла хатыннары аркаларына пиштәр киеп, урыс авылларында чабата сатып» тамак туйдырулары да тетрәндергеч.

Сталин чоры җәберләүләрен күргән кешеләрнең гомуми нәтиҗә-фикерләре дә игътибарга лаек. Мәсәлән, Фәттахетдин Заитовның «иске тормыш алышыну вакытында бер без генә түгел, бөтен Русиядә без күргәнне яхшы тормышлы булган бар бәндәләр дә күрде» дигән сүзләре чынбарлыкны яктырта. Бай-җитеш яшәгәннәрне кулак итеп сөрүләр, мөлкәтләрен конфискацияләүләр башланган чорда «халык ярлылыкны, ярлы булуны теләй һәм шуңа омтыла башлап... халык үзе теләп ярлылана башлады һәм ярлыланды» дип язган мулла Мөхәммәтсәлах Жданов. Ул шулай ук хуҗалыкларны

берләштереп колхозлар оештыруның ялгышларын да пунктлап теркәгән:

«1. Колхозга өндәү аңлату, файдасын төшендерү юлы белән башланмый, куркыту, кыстау юлы белән башланды.

2. Колхоз күбрәк таланып алынган малларга нигезләнде. Шунлыктан, халык бондан гаять нәфрәтләнде, ничек тә кермәскә карар кылды.

3. Дин бетерелү, дин әһеле ябылып, мәсҗидләр клуб һәм башка ителү. Бу мөнәсәбәт белән җылаучылар күп иде.

4. Колхоз юлбашчыларының күпчелеге фәкать үз файдаларын күзәтеп, халык малыннан тиешсез, законсыз юл белән файдаланулары».

Шул ук хәзрәт язмасында Сталин чорындагы икътисади үсешне белдергән «бишьеллык» термины муллалар һәм кулакларга каршы дәүләт террорының биш еллыгы мәгънәсендә телгә алынуы ягыннан игътибарны җәлеп итә. Илнең беренче бишьеллык планы, чынлыкта да, индустрияләштерүнең бушка эшләүче ирексез миллионнар хезмәте кулланылган 1928–1932 елларына туры килгән.

Менә шундый фикерләүләр халыкның ул вакыттагы совет хакимлегенә мөнәсәбәтен, гомумән, яшәеш турындагы уйларын ачык белдерә.

Иманлы бәндәләр үз башларына килгән мондый дәһшәтле кайгы-хәсрәтләрне һәм вәхшәтле хәлләрне Аллаһы Тәгалә тәкъдире дип кабул иткәннәр һәм үзләрен «әсир бәндәләр», имансыз-денсез «кяфер кулына дучар» ителгән кешеләр итеп бәяләгәннәр. Шуның белән бергә, «тупаслыклар чиктән ашты» дип, рәхимсезлекнең гадәттән тыш масштабларга киңәюенә борчылганнар.

Мөхәммәтнәкыйп Түнтәринең транспорт хәрәкәте булмаган төньяк урманнардагы кышкы салкында «14-ндә аннан 120 чакрым ераклыкта булган Вишер суы буендагы «Вишерский лагерь»гә җәяүләп чыгып киттек һәм 19 нчы декабрьдә лагерьгә килеп йиттек» кебек сүзләре бик хәтәр. Ул лагерьда чакта аңа хатыны Өммегөлсем язган хатларда бәгырьләрне

телә торган хәлләре тулырак күзаллана. Иренә «җанымнан да кадерле иптәшем Мөхәммәтнәкыйп» дип дәшеп, «һәммә нәрсә бар, тик син генә юк. Шунысы үзәкләрне өзә... Бер нәрсәнең дә шатлыгы күзгә күренми. Синең китүне белгәч балалар бик борчылыштылар, берничә көнгә кадәр җуата алмыйча аптырадым. «Озак тормый ул, анда баргач, тизрәк кайтыр» дип, төрле хәйләләр белән җуата торгач, хәзер бераз алданып көтеп йөриләр әле. Ни генә булса да, син кайтуга җурыйлар. Балалар алдында борчылганымны күрсәтергә дә куркам инде, алар борчылуы бигрәк йөрәкне әрнетә» дип язганнары фаҗиганең эчке газабын да күрсәтә. Мөхәммәтнәкыйп лагерьдан соң Мәләкәс шәһәрендә мәҗбүри рәвештә яшәгән чагында анда Өммегөлсем бер баруында өлкән улын, икенчесендә кызын, өченче тапкыр барганда ике кече улларын алып баруы да уйландырырлык.

Китапта барлыгы 18 текст урын алды. Җидесенең авторлары мулла булганлыклары өчен эзәрлекләнгән. Шулай ук элекке сәүдәгәрләр, дәүләт салымнарының күплегеннән интегүчеләр, тоткынлык вакыты тулганнан соң туган җиренә кайту тыелган (административ сөргендәге) аерым бер кеше һәм 1937 елда репрессияләнүчеләрнең язмышларына бәйле материаллар. Географик җәһәтенә килсәк, алар – Казан, Ижевск, Богырослан шәһәрләреннән, Татарстанның Әгерҗе, Балтач һәм Кукмара районнарындагы, Башкортстанның Тәтешле һәм Яңавыл районнарындагы авылларда табылган кульъязмалар.

Хатирәләре басылган һәм язмышлары тасвирланган кешеләрнең бер үк концлагерьларда (мәсәлән, Беломорканалда), яки сөргендә (Магнитогорскида) булулары, шулай ук азат ителгәннән соң туган җирләренә кайтулары тыелып, Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри һәм Габдулла Апанаевның бер үк елларда Мәләкәс шәһәрендә торулары, бер лагерьда гына да берьюлы әллә ничә күренекле дин әһеленең булуы (Ш.Зарипов хаты) һ.б. шундый күренешләр җәбер-золымның масштабын күз алдына китерергә ярдәм итә.

Текстлары тәкъдим ителгән һәр материал авторларының

гына түгел, аларның гаиләләренең һәм якыннарының да язмышларына бәйле булган. Гомумән, куркынычлы елларның дәһшәте гаять зур икәнлеге аңлашыла.

Җыентыкта урын алган текстлардагы Ф.Заитовның Беломорканалда 1933 елда яхшы эшләгән өчен яңа киемнәр, юлга акча биреп җибәрүләренә шатлануы, С.Шәймәрдановның Магнитогорскида 1936 елда эш нормасын 200 проценттан арттырып үтәве, аның хәтта алдынгы эшче – «стахановчы» булуы – үз чорындагы вазгыятьнең әче ирониясен белдерә. Ә 1938 елда Медвежьегорск лагеренннан Ш.Зариповның «эшебез җиңел, бик тук, өс-баш бөтен, бер исәбем дә юк» дип язган сүзләре дөреслеккә бөтенләй туры килмәгәнлеге аңлашыла.

Китапта бирелгән бәет-мөнәҗәтләрнең шигъри төзелешләре, әлбәттә, төрле дәрәҗәдә. Арада зур осталык белән иҗат ителгәннәре дә, кайтышраклары да бар. Аларның нәфасәт һәм камиллек якларына караганда, бу җыентыкның темасына күрә, документальлек һәм фактик җәһәтләре өстенрәк. Авторлары шагыйрьләр булмаса да, халкыбызның шигъри әсәрләрен укып та, яттан да белгәннәр. Китапта бирелгән текстларда татар халык авыз иҗатындагы һәм шигъри әсәрләрендәгечә юллар, халык мөнәҗәтләренә хас булган моң-сагыш, чиксез хәсрәт чагылыш табуы, Габдерәхим Утыз Имәни, Һибәтулла Каргалый һәм Габделҗәббар Кандалый шигырьләренә аваздаш юллар булуы шуны раслый.

Бу китапта урын алганнарга охшаш материаллар матбугатта басылып килә. Мәсәлән, шундыйларның соңгыларыннан язучы һәм тарихчы Фәүзия Бәйрәмованың «Бутан бәете – татар язмышы» мәкаләсендә бирелгән «Бутан мөнәҗәте»[23] 1930 нчы елларда кулак итеп Себергә сөрелүчеләр турында.

Утызынчы еллардагы вәхшәткә бәйле әдәби һәм документаль әсәрләр матбугат мәйданында гомумән чыгып тора. Репрессия корбаннары һәм кулак дип сөрелгән татарларның аянычлы язмышына бәйле җанөшеткеч хәлләрне алардан

---

[23] Бәйрәмова Ф. Бутан бәете – татар язмышы... // Мәдәни җомга. – 2021. – 3 декабрь (№47). – Б. 14–15.

укып белергә мөмкин. Андый әсәрләр, әлбәттә, киләчәктә дә язылыр. Бу китапта урын алган мәгълүматлар шул чор турында язучы, милли хисләрне кимсетми һәм тарихка гаделлек-хөрмәт белән карый торган каләм әһелләренә документаль чыганак өлгеләре буларак та кулланылыр дип уйлыйбыз. Мисал өчен күркәм үрнәкләр дә булганын искәртик. Мәсәлән, Фәүзия Бәйрәмова романында Сабирҗан Шаһимәрдан улының Милли китапханәдә саклана торган мөнәҗәтеннән дә өзек бирелгән[24].

Китапта телгә алынган концлагерьлар
һәм сөрген урыннары

Китаптагы төрле текстларда Арча, Әгерҗе, Казан, Уфа, Мәскәү төрмәләреннән тыш, Архангельск, Кемь, Вишер, Беломорканал, Медвежьегорск, Темников, Магадан һ.б. урыннардагы лагерьлар, шахталар иле Анжеро-Судженск, Магнитогорск кебек корыч гигант-калалары телгә алынган. Андыйларның бер өлеше хакында астөшермәләрдә кыскача искәрмәләр бирелде, ә эре лагерьлар турында гомуми рәвештә язабыз. (Монда әйтеләчәк аерым географик атамалар – елгалар, күлләр, кала һәм бистәләр шулай ук текстларда очрый).

Алда искәртелгәнчә, 1930 нчы елларда тоткыннар индустрияләштерүнең төп эшче көче булган. Үзәкләштерелгән лагерьлар системасы – ГУЛАГ карамагында торган барлык лагерьларда тоткыннарның иң күп вакытындагы саны 2 миллион 600 мең кешене тәшкил иткән.

СССРда 1929 ел ахырында биш: Соловки (Соловецк), Төньяк, Вишер, Себер, Ерак Көнчыгыш гигант-лагерьлары булган һәм аларда 95064 тоткын исәпләнгән. Алардан иң зурысында – Соловки утрауларында 1929 елның 1 октябренә 53123 кеше тотылган. Шул ук вакытта Казакъстан һәм Урта Азия лагерьлары да оештырылган.

1929 елның җәендә Соловки лагерьлары идарәсе Ак

---

[24] Бәйрәмова Ф. Кырык сырт: романнар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2005. – Б. 51.

диңгез буендагы Кемь шәһәренә, ә 1931 елда Медвежья Гора станциясенә күчерелгән.

Кемьда Соловки утрауларының Кемь бүлеге булган. Анда 1920–1930 елларда (шәһәрдән 12 чакрымдагы Рабочеостровск бистәсендә, икенче төрле атамасы – Попов утравы) тоткыннарны Соловки лагерьларына һәм аерым базаларга бүлеп озату, шулай ук Кемь шәһәренең үзендәге предприятиеләргә урнаштыру буенча махсус пункт эшләгән. Әлеге пункт тоткыннар өчен аеруча куркынычлы урын булып саналган. Кыскарак сроклы җәза үтәүче Попов утравында калдырылган, анда даими рәвештә өч меңгә якын тоткын исәпләнгән. Сөргендәгеләрнең бер өлеше (гадәттә, югары культуралы һәм белемле кешеләр) шәһәрдә яшәүчеләрнең фатирларында торганнар.

Төньяк крае 1929–1936 елларда элекке Архангельск, Вологда, Төньяк Двина губерналарын, Коми автономияле өлкәсен, Ненец милли округын үз эченә алган һәм илнең «алдынгы промышленность комбинаты» вазифасын үтәгән. 1929 елдан аның башкаласы Архангельск шәһәре – СССРның урман (такта җитештерү) промышленностенең иң эре үзәге булган. Төньяк урманнарын күбрәк импортка – чит илләргә чыгарып, шул исәпкә техника (паровозлар, машиналар), электр аппаратлары, станоклар һ.б. алынган.

1929 елдан 1939 елга хәтле Архангельск шәһәре халкы 89 меңнән 281 меңгә хәтле арткан. Анда үз ирекләре белән эшкә килүчеләрдән тыш, сөрелгән кешеләр дә өстәлгән.

Төньяк крайда 1929 елның май аенда 2256 тоткын исәпләнгән. Кулакларны сыйныф буларак бетерү максаты белән 1929–1930 нчы елларның кышында оештырылган чаралар нәтиҗәсендә анда СССРның төрле төбәкләреннән 30 мең кулак һәм советка каршы элементлар (шул исәптән, 9 мең җинаятьче) китерелергә тиеш булган. 1930 елның гыйнварындагы мәгълүмат буенча, якын арада Төньяк крайда барлыгы 70 мең гаилә (350 мең кеше) урнаштыру күздә тотылган. 1930 елның февраль аеннан Архангельскига көн саен 5–7 мең кеше килүе ниятләнгән. Ул заманда бөтен Архангельск округында

250 мең кеше яшәгән. 1930 елның февралендә сөрелгәннәрнең эшкә яраклылары 70 мең кеше булган. Аларны монастырьларга һәм Архангельскига күршедәге авылларда урнаштырганнар. 1930 елда Архангельск шәһәренең үзендә ачлык котырган. Тоткыннарның яңа төркемнәре даими өстәлеп торган.

1931–1932 елларда Төньяк крайга тагын 300 мең кеше сөрелгән. Шул чорда эпидемияләрдән, ачлыктан, салкыннан һ.б. сәбәпләрдән үлемнәр иң югары санга – 51 процентка җиткән. 1930 нчы еллар башында мәетләр шәһәрнең үзәгендә, пристаньда, трамвай юлларында аунап яткан.

Ризык җитмәү һәм авырулар сәбәпле, 1932 елның 1 гыйнварыннан 1934 елның 1 гыйнварына кадәр Төньяк крайга сөрелгәннәрнң саны 51,5%-ка кимегән.

Вишлаг – Вишер лагерьлар системасы Пермь өлкәсенең Вишер елгасы буендагы лагерьларын берләштергән. Вишерда, Березникида һ.б. урыннарда «командировка» дип аталган лагерь бүлекчәләре шактый булган.

Вишер төзәтү-хезмәт лагере 1928–1934 елларда гамәлдә булган. Аңа төп бурыч итеп целлюлоза-кәгазь комбинатын һәм Березникидагы химия комбинатын төзү, шулай ук урман кисү йөкләнгән. Кәгазь комбинатын төзү эше 1930 елның апрелендә башланган һәм шул ук елның гыйнварында эшчеләр бистәсе дә корыла башлаган. Вишерда 1930 елның мартында 11 мең тоткын, шул ук елның июлендә 20 мең тоткын булган. Ә 1931 елның апрелендә Вишлагта 40 меңгә якын тоткын исәпләнгән. Аларга хезмәт нормасы югары итеп билгеләнгән, үтәмәгән өчен икмәк һ.б. азык киметелгән, үлүчеләр күп булган. 1932 елның ахырында тоткыннарны башка лагерьларга (Беломорканалга, Дальстройга) җибәреп, Вишлагта 8900 тоткын гына калган.

Әлеге лагерьлар төркеме урнашкан тирәдәге Соликамск каласыннан төньякка 1930 нчы елларда тимер юллар булмаган, тоткыннарны тайга буенча җәяүләп этап белән куганнар, күпләре үлгән.

Лагерьдагы кырыс тәртипләр сәламәт кешеләрне дә кыска

вакыт эчендә инвалидка әверелдергән. ОГПУ карамагындагы барлык лагерьлардан Вишлагтагылар инвалидлык буенча күпчелекне тәшкил иткән. Пермь шәһәрендәге ярыминвалидлар «командировка»сыннан тыш, 1 нче лагерь бүлегендә Кожин ярыминвалидлык участогы да оештырылган. Вишер лагере ОГПУ лагерьларының иң кырысларыннан берсе саналган. Анда үлүчеләр һәм авыручылар да иң күбе булган. Өстәвенә, 1932–1933 еллардагы ачлык һәм тиф авыруының күп таралуы үлемнәрне тагын да арттырган.

Карелиядәге **Беломор-Балтыйк** төзәтү-хезмәт лагере (Белбалтлаг) 1931–1941 елларда гамәлдә булган.

Төзелеш эшләре 1931 елның октябрь аенда башланган. 1932 елда Беломорканалны төзү активлашкан һәм Выгозеро күленең суы 6 метрга күтәрелгән. Майгуба бистәсен өлешчә су баскан һәм андагы агач эшкәртү заводы, шулай ук башка оешмалар Сегежага күчерелгән. 1933 елда урман-агач эшкәртү заводы продукция бирә башлаган.

227 чакрым озынлыгындагы Беломорканал төзелеше 1933 елның маенда төгәлләнеп, 2 августта ачылган. Шуннан соң 60 мең тоткынның сроклары киметелеп, бер өлеше азат ителгән. 1933 елның ноябреннән Сегежа урман-химия һәм кәгазь комбинаты төзелә башлаган.

Беломорканалда даими 126 мең кеше (шуның 115 меңе тоткын) эшләгән. Анда ел саен дистә меңнәрчә яңа тоткын китерелгән. Бу төзелештә барлыгы 250 мең тирәсе кеше катнашкан. Рәсми саннарга караганда, Беломорканалда 12300 (тарихчылар әйтүенчә, 50 мең яки 86 мең) кеше үлгән. Шуларның күпчелеге 1933 елда һәлак булган.

Бөек Ватан сугышы вакытында – 1941 елның 11 декабрендә дошман (финнәр) һөҗүменнән чигенеп баручы Кызыл Армия каналның соңгы шлюзын шартлаткан. Фронт сызыгы Беломорканал аша үткән. 1944 елның җәендә бу тирәләр азат ителгән.

СССР Эчке эшләр Халык комиссариатының Беломорканал төзелеше һәм лагерьның административ идарәсе Карелиядә, Онега күле буендагы **Медвежьегорскида** урнашкан.

1916 елда нигезләнгән тимер юл станциясе башта Медвежья Гора исеме белән аталган. 1930 елның 29 августында аны эшчеләр бистәсе итеп үзгәрткәннәр. 1938 елның сентябрь ае карары белән әлеге бистә Медвежьегорск шәһәре буларак яши башлаган.

Медвежья Гора (Медвежьегорск) лагеренда күпчелеге атарга хөкем ителеп, үлем җәзасы 10 ел белән алыштырылган, 58 нче маддә буенча хөкем ителгән кешеләр тупланган.

1941 ел ахырында Медвежьегорск каласын финнәр басып алган. Совет гаскәрләре аны 1944 елның 23 июнендә азат иткән.

Магнитогорск шәһәренә кулак итеп сөрелгәннәрнең саны һәм аларның язмышлары турында алдарак язып үттек. Анда әйтелгәннәргә гомуми мәгълүмат өстәү дә зарур.

Җаек елгасы буендагы Магнитогорск (Чиләбе өлкәсендә) – СССР металлургия промышленностенең иң эре үзәкләреннән берсе булган. Ул 1929 елның 30 июнендә нигезләнгән һәм 1931 елның 15 июнь көненнән аңа шәһәр статусы бирелгән.

1931 елның май аенда Магнитогорскида рудник эшли башлаган, 1932 елның февралендә беренче тапкыр корыч коелган, 1933 елның февраль–ноябрь айларында 4 мартен миче сафка бастырылган.

Магнитогорскиның беренче объектларын (рудник, домна мичләре, тимер юл тармагы, Җаек елгасы аша плотина һ.б.) төзүдә 40 мең кеше эшләгән. Аларның күпчелеген кулаклыкта гаепләнеп сөргенгә куып китерелүчеләр тәшкил иткән. Гомумән, 1930 нчы елларда андагы бөтен төзелешләрдә эшләүчеләрнең яртысыннан күбрәге сөрелгән кешеләр булган.

Тарихчылар язуынча, Магнитогорскига сөрелүчеләрнең өчтән ике өлеше Татарстаннан булган. Андыйлар 1931 елның 1 октябренә 42,5 мең кеше исәпләнгән.

Анжеро-Судженск – көнбатыш Себердәге (хәзерге Кемерово өлкәсендә) Анжера елгасы буенда урнашкан бистә. Уралдан Тын океанга кадәр бөтен Себер аша үтә торган Бөек Себер тимер юлын төзү һәм ташкүмер чыгару белән бәйле рәвештә

1896–1897 елларда нигезләнгән. 1928 елда күршесендәге Судженка бистәсе белән берләштерелгән һәм 1931 елдан Анжеро-Судженск шәһәре булып йөртелә башлаган. Андагы лагерьлар Себер (Сиблаг) системасына кергән. 1931 елның 21 августыннан башлап Анжеро-Судженскига Татарстан, Башкортстан, Чуашстан, Мордовия һәм Украинадан сөрелгән 2369 гаилә (12631 кеше) төялгән беренче эшелоннар килгән. Шуннан соң андый эшелоннар даими өстәлеп торган. Сөрелгән крестьяннар өчен махсус бистәдәге баракларда урын җитмәү сәбәпле, үзләре землянкалар казып, шуларда җан асраганнар һәм шахталарда, шулай ук урман эшендә, агач эшкәртүдә, төзелештә эшләгәннәр.

Магадан – СССРның төньяк-көнчыгыш читендә 1929 елда төзелгән Бухта Нагаева бистәсе, исеме соңрак Магадан дип үзгәртелгән. Андагы «Дальстрой» карамагында 1932–1953 елларда 900 меңгә якын тоткын булган, шулардан 121 меңнән артыгы үлгән.

Мәскәү каналы (Мәскәү исемендәге канал, 1947 елга хәтле «КиМ») – Мәскәү һәм Идел елгаларын тоташтыра торган, Мәскәү һәм Тверь өлкәләре, өлешчә Мәскәү шәһәре территорияләрендәге, 128 км озынлыгындагы канал. Мәскәү шәһәренә кирәкле эчә торган һәм промышленность суларының 60%-ын тәэмин итә.

«Мәскәү-Идел» каналын төзү турындагы карар 1931 елның 15 июнендә кабул ителгән. 1932 елның 1 июнендә бу төзелеш ике елда төгәлләнергә тиеш дигән бурыч куелган. Беломор-Балтыйк каналының белгечләре һәм шактый эшчеләре шунда күчерелгән. Бу гигант төзелеш өчен ГПУның 1932 елгы 14 сентябрь боерыгы белән махсус Дмитров төзәтү-хезмәт лагере оештырылган. Канал төзүдә эшләгән тоткыннарның саны иң күп вакытта 196 мең кешегә җиткән. Гомумән, Мәскәү каналын төзегәндә барлыгы 600–700 мең тоткын катнашкан. Шактый тоткыннар һәлак булган – хастаханәләрдә 23 меңгә якын үлгәннәрдән тыш, эш урыннарында да үлгәннәр һәм атып та үтерелгәннәр. Мәскәү каналы 1937 елда төзелеп беткән.

Китаптагы текстларда «командировка» дигән гыйбарә дә очрый. Ул 1920–1950 еллардагы СССР лагерьлары системасындагы иң кечкенә берәмлекне белдергән. Ягъни, лагерьлар иерархиясендә иң зуры – лагерь, аннан соң – лагерь бүлеге, аннары – лагерь пункты һәм иң кечкенәсе – командировка дип аталган.

Китаптагы кайбер текстларда «минус 12» рәвешендәге гыйбарәләр бар. Бу исә ГУЛАГ тарафыннан территориаль бүленешне күзәтү астында тотуны тәэмин итәргә тиеш булган чараларның берсе. Ягъни, тоткынлыктан азат ителүченең административ сөргендә булуын белдерә. 1930 нчы елларда тоткынлыктан азат ителүчеләр өчен «минус 5», «минус 10» кебек яшәү тыелган регионнар, зоналар, шәһәрләр билгеләнгән. 1953 елга андый чикләнгән урыннар 340-ка җиткән (шәһәрләр, тимер юл станцияләре, барлык чик буе зоналары һ.б.).

***

Китаптагы һәр текст алдында аның төп чыганагы кыскача тасвирланды, авторы һәм күчергән кешесе турында (ачыклануына күрә) мәгълүмат бирелде. Шунда ук һәм астөшермәләрдә текстка карата кайбер аңлатмалар һәм искәрмәләр язылды. Хатирәләрнең һәм бәет-мөнәҗәтләрнең авторларыннан тыш, текстларда телгә алынган аерым кешеләргә бәйле, үзебез ачыклый алган мәгълүматларны да теркәдек. Мәсәлән, татар археографы Әнвәр Нуриәхмәтевнең әтисе дә 1930 елда концлагерьга хөкем ителгән булган. Текстларда искә алынган яисә кульязма чыганакларда исемнәре теркәлгән кайбер кешеләрне төгәл ачыклау мөмкин булмаса да, ихтималга якын фаразлар белдердек.

Гомумән, бу китапта текстларның авторлары һәм аларда телгә алынган, шулай ук кереш мәкаләдә язып үтелгән совет чоры репрессиясе корбаннары булган җитмештән артык кешенең исемнәре аталды, үзләре турында кыскача мәгълүмат бирелде. Әйткәнебезчә, аларның күбесенең гаиләләре дә җәзага дучар булган. Китапта исемнәре телгә алынган корбаннарның рухлары шат булсын!

Текст кульъязмаларының факсимилеләре дә урнаштырылды. Җыентык ахырындагы сүзлектә гарәп, фарсы һәм рус сүзләре белән бергә, архаик гыйбарәләргә дә аңлатмалар бирелде.

Китапта басылган текстларда тел-стиль үзенчәлекләрен, аерым архаик сүзләрнең, шулай ук гади сөйләм телендәгечә язылышларны төп чыганаклардагыча сакларга тырыштык. Мәсәлән, *агус (август), агыр (авыр), ака (ага), әдрис, әрмия, багун (вагон), бән (мин), берлә, вахыт, дөрле (төрле), дөш (төш), җолдыз, җөз, җөрәк, җук, җыл, җырак, зиярат, илән, иткүче (итүче), йаным (җаным), йир (җир), кеби, крәстиян, күрәрмән, муча, өмит, өю (өй), параваз, парахут, пашпорт, пиштәр (биштәр), поез, пристен (пристань), сач (чәч), сачәк (чәчәк), сүләү (сөйләү), ыризык, Ысталин, ыстанса, эрәнҗү, язгучы* һ.б.

Кайбер кульъязмаларның кәгазьләре дефектлы булганга яки бүтән сәбәптән танылмаган сүзләр урынына күпнокталар куелды. Кульъязма чыганакларда төшеп калган сүзләр, кушымчалар һәм хәрефләр безнең тарафтан өстәлгәндә квадрат җәяләр эченә алынды.

***

Китапны басмага әзерләү дәвамында күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, КФУ доценты, тарих фәннәре кандидаты Фәрит Шәкүровка, тарих фәннәре кандидаты Рафилә Гыймазовага ихлас рәхмәтләремне җиткерәм.

«Гомернең бушка узуы – җәза»

Мөхәммәтнәкыйп Ишмөхәммәт улы Түнтәри хәзерге Балтач районындагы Түнтәр авылында 1888 елда дөньяга килгән. Туган авылы мәдрәсәсендә укыган, үзе дә шәкертләргә сабак биргән. 1909–1912 елларда Бохарага барып белемен арттырган, Сәмәркандта булган. Шуннан Истанбулга сәяхәт иткән һәм хаҗга сәфәр кылган. 1915 елда Сасна авылының Сөләйман хәзрәт[1] кызы Өммегөлсем белән никахлашып, гаилә корган. Аларның 1916–1929 еллар арасында алты балалары дөньяга килгән. Мөхәммәтнәкыйп 1915 елдан Түнтәр авылының икенче мәхәллә мәчетендә имамлык иткән, балалар укыткан. 1918–1919 елларда имамлыктан тукталып торган. Аннан соң укыту-мәгариф эшләре белән шөгыльләнгән.



Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри. XX гасыр башы

Мөхәммәтнәкыйп хәзрәт 1930 елның март аенда кулга алынган һәм 11 апрельдә 58 нче маддә буенча (совет власте чараларына һәм колхозга каршы коткы, дини агитация өчен) гаепләнгән, биш елга концлагерьга хөкем ителеп, июльдә Архангельск

[1] Сөләйман мулла Даут улы турында мәгълүмат алырга мөмкин: Мөхәммәтшин Г. Балтач мәчетләре: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2018. – Б. 245–246.

шәһәренә җибәрелгән. Декабрь аенда хәзерге Пермь өлкәсе территориясендәге Вишлагка озатылган. Андагы төрле лагерьларда булганнан соң, 1932 елның май аенда Беломорканал төзелешенә күчерелгән. 1932 елның көзендә азат ителгәч туган җиренә кайтырга рөхсәт булмаган, административ сөрелүче сыйфатында Ульяновск шәһәрендә яши башлаган, анда ачлы-туклы һәм салкыннан интегеп җан асраган. Бер елдан соң Мәләкәс (хәзерге Димитровград) каласына күчкән.

1935 елда туган авылына кайткан һәм имамлык хезмәтен дәвам иткән. Анда да мәҗбүри урман кисү һәм юл эшләренә җибәрелгән, авыр салымнар түләгән. 1939 елда, авыл мәчетләре хөкүмәт карамагына алынганнан соң, Мөхәммәтнәкыйп мулла гаиләсе белән Казанга күчеп киткән. Анда вакытлыча кеше фатирларында гомер сөргәннәр. Ул Казанда каравылчы, «Татарстан» кунакханәсендә швейцар һәм фабрикада ишегалды себерүче булып, төрле эшләр башкарган.

Бөек Ватан сугышы башлангач, зур авырлыкларга тарып, 1942 елның көзендә яңадан Түнтәргә кайтырга мәҗбүр булганнар, анда ачлы-туклы хәлдә һәм кеше өйләрендә торып, күп кыенлыклар кичергәннәр. Яшәргә урыннары булмагач, 1944 елдан Малмыж шәһәренә киткәннәр. Анда Мөхәммәтнәкыйп Ишмөхәммәт улы 1946 елның ахырына хәтле яшелчә һәм җимеш питомнигында каравылчы булып эшләгән. 1947 елдан сукырлар җәмгыятенә каравылчы хезмәтенә кергән. Ул чорда Малмыжда яшәгән мөселман татарлар хәзрәтне бик хөрмәт итеп, рәсми рәвештә булмаса да, имамлык вазифаларын башкаруын сораганнар. 1948 елда Мөхәммәтнәкыйп мулла гаиләсе Казанга күченеп китәргә мәҗбүр булган. Аннан соң яңадан Малмыжга кайтып яшәгәннәр.

Хәзрәтнең улы Фарук Нәкыйпов (1926–2005) әтисенең вафаты турында болай язган: «1954 елның гыйнварыннан Саба районы Икшермә МТСында мастерской мөдире булып эшли башладым. Шул ук елның көзендә, Малмыждан әтиләрне МТСтан бирелгән квартирга алып килдем. Әмма әти инде авыру иде. Аны Казанга алып барып, төрле врачларга күрсәтеп,

больницада дәвалап карасак та, ул инде терелә алмады. Казанда вафат булып, Пороховой зиратында җирләнде. Аңа әле 67 яшь тә тулмаган иде. Үз гомеренең күп өлешен кимсетелеп, каһәрләнеп, мәсхәрәләнеп, кыйналып гомер кичергән бу изге бәндәнең язмыштан зарланганын мин беркайчан да ишетмәдем. Күрәсең, Алла аңа иксез-чиксез сабырлык, түземлелек, киң күңел биргән булгандыр»[2].

Мөхәммәтнәкыйп Түнтәринең бу китапта тасвирланган биографик мәгълүматлары үзе тарафыннан 1948 елда язылган «Хәятым тарихында булып кичкән бәгъзе вакыйгалар вә хәлләр» дип исемләнгән дәфтәреннән алынды.

Бу дәфтәрдәге, 1904–1913 елларга караган язмалар безнең тарафтан матбугатта бастырылды һәм шунда ук әлеге кыйммәтле мәгълүматларның һ.б. тарихи материалларның саклануына бәйле мәкаләбез дә дөнья күргән иде[3]. Анда Фарук Нәкыйповның үз бабасы Ишмөхәммәт хәзрәт Динмөхәммәт улына һәм аның гаиләсенә багышланган язмасы һәм фоторәсемнәре дә басылды[4]. Ишмөхәммәт хәзрәт («Ишми ишан» дип тә танылган, 1841–1919) – Түнтәр авылы мәчетендә имам-хатыйп һәм мәдрәсәсендә мөдәррис булган күренекле дин эшлеклесе, мәгърифәтче, фаҗигале еллар корбаны. Совет власте тарафыннан 1919 елның 8 май көнендә Малмыж шәһәрендә атып үтерелгән. Кабере Балтач районының Борнак авылы зиратында.

Нәкыйповлар архивындагы язма истәлекләрнең бер өлеше – хатлар. Алар Ишмөхәммәт хәзрәт һәм аның улы

---

[2] Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык: хакыйкатьне тарихка әверелдерү юлында 15 ел. – Казан, 2006. – Б. 13.

[3] Мәрданов Р. Ишмөхәммәт хәзрәт оныгы Фарук Нәкыйповның шәхси архивына күзәтү // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №1. – Б. 215–220. Бу мәкалә, шулай ук хатлар һәм хатирәләр кабатлап басылды: Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык: хакыйкатьне тарихка әверелдерү юлында 15 ел. – Казан, 2006. – Б. 132–146; Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык: хакыйкатьне тарихка әверелдерү юлында 15 ел. – Казан, 2010. – Б. 99–109; Зарипов Р. Түнтәр авылының мәчет-мәдрәсәләре тарихы. – Казан: ун-т нәшр., 2018. – Б. 314–324.

[4] Нәкыйпов Ф. Тарих: сәясәт һәм дөреслек // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №1. – Б. 205–214.

Мөхәммәтнәкыйп тарафыннан тупланып, 3 төпләмгә берләштерелгән. Беренче төпләмдә XIX гасырның соңгы чиреге ннән алып 1910 елларга кадәр Ишмөхәммәт муллага һәм гаиләсенә язылган 42 хат теркәлгән. Аларның күпчелеге Чистайдан – Мөхәммәтзакир ишан Камаловтан, шулай ук төрле шәхесләрдән һәм төрле яклардан алынган хатлар. Икенче төпләмдә Мөхәммәтнәкыйпнең 1909–1912 елларда әти-әниләренә язган 37 хаты тупланган. Өченче төпләмдә Ишмөхәммәт хәзрәт гаиләсе әгъзаларының 1909–1952 елларда үзара язышкан 121 хаты җыйналган.

Әйтелгән өч төпләмдәге 200 данә хатның тарихи әһәмияте, һичшиксез, бик зур. Аларда дин һәм милләт язмышы да, җәмгыятьтәге төрле үзгәреш-вакыйгалар да, ата белән бала һәм искелек-яңалык мөнәсәбәтләре киң чагылыш тапкан.

Мөхәммәтнәкыйп хәзрәтнең «Хәятым...» исемле көндәлегендә 1903–1948 еллардагы тормыш юлы һәм төрле вакыйгалар теркәлгән.

Шулай ук үзе «Тоткынлык көннәрем» исемендәге тәфсилләрәк хатирә дәфтәре дә булганын искәрткән. Андый дәфтәре турында улы Фарук ага да әйткән иде[5], ләкин безгә күрергә насыйп булмады.

***

Китапта Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри үз тормышын язган дәфтәрнең 1930–1940 нчы еллар арасындагы өлеше күчереп тәкъдим ителде. Аның һәм якыннарының 1930 нчы еллардагы кичерешләрен тулырак күзаллау өчен сөрген чоры белән бәйле кайбер (үзе, хатыны һәм биатасы язган) хатларны да бастырдык. Мөхәммәтнәкыйп мулла Мәләкәстә торганда аңа ярдәмләшкән Гатаулла хәзрәтнең 1936 елгы хаты да, тарихи әһәмиятенә күрә, кирәкле дип табылды. (Хатның күчермәсе Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «4900т» шифры белән саклана).

[5] Мәрданов Р. Ишмөхәммәт хәзрәт оныгы Фарук Нәкыйповның шәхси архивына күзәтү // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №1. – Б. 216.



انا لله وانا الیه راجعون

١٢ آپریلده مفتی رضاءالدین بن فخرالدین حضرتلری وفات اولدیلر. ١٥ اپریل چهارشنبه
کون ساعت ١٢ ده دفن ایتدیلر. رحمة الله علیه رحمة واسعة.

Мәләкәстән Гатаулла хәзрәт хаты

Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри Гатаулла мулла белән якыннан аралашкан, аны зур хөрмәт белән искә алган. Гатаулла хәзрәт Гыйбадулла угылы (башка чыганакларда Гобәйдулла улы, 1874–1938) – Идел буе мөселманнарының күренекле эшлеклеләреннән. Ул Мәләкәс мәчетенә 1900 елда имам итеп билгеләнгән, 1923 елдан Самара губернасының икенче нахиясе (районы) мөхтәсибе вазифасын үтәгән. 1937 елның ахырында кулга алынган, «милләтче татар контрреволюцион хәрәкәтенең җитәкчеләреннән берсе» буларак гаепләнеп, 1938 ел башында атып үтерелгән. 1956 елда акланган.

Гатаулла хәзрәт үзе дә Мөхәммәтнәкыйп хәзрәтне бик хөрмәт иткән, хатында аны «газиз туганым» дип атаган һәм якын күреп «сезне бик сагынамыз» дигән. Хат ахырында авторы үзен «шәйхелислам» дип күрсәткән. Шәйхелислам – бу очракта кеше исеме булмыйча, мөселманнар җитәкчесе, дин эшләре буенча мөселманнар башлыгы дигән мәгънәгә ия. Гадәттә, мөфти вазифасындагылар «шәйхелислам» дип аталган. Бу хат язылган кәгазь битенең түбәнге өлешендә Мөхәммәтнәкыйп мулланың «Мәләкәс имамы мөхтәрәм Гатаулла хәзрәт мәктүбе» дигән язмасы бар. Хат чынлап та Гатаулла мулланыкы булганы аның башка бер (Фәхрелислам исемле муллага адресланган) хатының кулъязмасы белән дә раслана[6].

Дингә каршы көчле басым һәм гаять кыен заманда да Мәләкәс мулласы Гатаулла хәзрәтнең татар телендә «Мөгаллимел-гаруз» исемле әсәр иҗат иткәнлеге, гарәп телендәге «Касыйдәи бөрдә» исемле әсәргә гарәп телендә шәрех-аңлатма язу белән мәшгуль булуы, аларны исә Мөхәммәтнәкыйп Түнтәринең үзе өчен күчереп алуы турындагы мәгълүмат бик мөһим. Ягъни, бу – татар муллаларының гасырлар буе дәвам итеп килгән иҗади эшкә һәвәслекләре, гарәп телен камил белүләре һәм әсәрләр XX гасырның беренче яртысында да күчерелеп таралуының мисалы.

Гатаулла мулла хатында мөфти Ризаэтдин Фәхретдиннең ва-

---

[6] Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2018. – Б. 16–17, 93–94, 143.

фаты турында язылган өлеше дә бик мөһим. Хаттагы хәбәрләр мөфтинең үз кызы Әсма Шәрәф язган хатирәләргә[7] аваздаш. Ике чыганактагы мәгълүматлар бер-берсен тулыландыра.

Мөхәммәтнәкыйп мулланың Беломорканалдан язган хаты белән бергә үзе иҗат иткән шигъри әсәрен («Хифыз ит иманым, Алла») якыннарына җибәргән булуы аеруча игътибарга лаек. Концлагерь шартларындагы тоткын кешенең сагышлы күңелендә туган әсәр, биатасы Сөләйман хәзрәт хатыннан күренгәнчә, яхшы иҗат ителгән, яратып укылган һәм халык арасында да таралган.

Сүз уңаеннан искәртик, әтиләре Мөхәммәтнәкыйп мулла Мәләкәстә чагында аңа балалары язып җибәргән хатлар да сакланган.

Мөхәммәтнәкыйп мулла текстында тасвирланган заманнар турында аның улы Фарук Нәкыйпов хатирәләрен искә алу урынлы булыр. Ул, әтиләре лагерьда һәм сөргендә булганда үзләре ничек торганны теркәгән һәм, аерым алганда, түбәндәгеләрне язган.

«Мин, Нәкыйпов Фарук Нәкыйп улы, 1926 елның 14 февралендә Түнтәр авылында (Арбор волосте) гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килдем. Әтием Ишмөхәммәтов Нәкыйп гаиләгә бирелгән җир иманасында иген иккән, ат, сыер тоткан һәм авылның икенче мәхәлләсендә имамлык вазифаларын үтәгән. 1930 елның 4 мартында кулга алынып, Казан төрмәләрендә берничә ай тотылгач, биш елга төрмә җәзасына хөкем ителгән. Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турындагы закон нигезендә, 1993 елда, гаепсез дип табылды, акланды[8].

Безнең гаиләне, 1932 нче елларда булса кирәк, йортыбыздан чыгардылар. Иң элек алты кешелек гаиләбезне ярымпод-

---

[7] Ризаэтдин Фәхретдин: фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: научно-биографический сборник. – Казан: «Рухият» нәшр., 1999. – Б. 75–77, 141–143.

[8] Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык: хакыйкатьне тарихка әвереләдерү юлында 15 ел. – Казан, 2006. – Б. 10.

вал итеп эшләнгән түбән катка сөрделәр. Бу безнең Түнтәрне район үзәге итеп билгеләү[9] аркасында булган булса кирәк, югарыда Рәүф абый Ибраһимов дигән ипле генә бер кеше хатыны, ике улы белән килеп урнашты. Без алар белән бик тату яши идек. Әмма бераздан район үзәген Балтачка күчерделәр. Ибраһимовлар гаиләсе дә шунда китеп барды. Изге урын буш тормый дигәннәр урыслар, безнең өйне дә буш тотмадылар. Өске катның өч бүлмәсенә колхоз рәисе Ибрай хатыны Маһинур белән кереп утырды. Алар белән дә сыешкан булыр идек, мөгаен, әмма очраклы бер хәл безне өебездән бөтенләй сөрүгә сәбәп булды... Ике көннән әнине авыл советына чакырып, ярымподвалны да бушатырга әмер бирделәр.

Аннан соң без, өен бикләп, гаиләсе белән «читкә киткән» Фәйзерахман абзый йортында тордык. Бер ел чамасы үттеме, кимрәкме, Фәйзерахман абзый безгә йортны бушатырга кушты. Ул – йорт хуҗасы, аның әмере – закон. Без – бала-чага, тик әни белән әбинең безгә ишеттермәскә тырышып, пышылдашканнарын, борчылганнарын күреп кенә нидер сизенә идек. Борчылырсың да: инде көз, алда салкын кыш көннәре. Сиксән яшьлек сукыр әби, без балалар, авыру әнинең бердәнбер таянычы Мансур абый. Ул да, уйлап карасаң, үсмер малай. Әни кемнәргәдер барды, кемнәрдәндер үтенеп сорады булса кирәк. Әмма... Авылда ике йортлы кешеләр юк диярлек, гаиләләр зур. Без үзләре белән бер йортта торырга да шатланыр идек. Тик аны ничек кешенең үзенә әйтәсең? Алты җан иясе ич без! Төрмәгә утыртылган мулланың гаиләсен үз түбәсе астына сыендырырга куркучылар да булгандыр, мөгаен.

Өметсезлекнең чигенә чыккан шундый бер көнне, ут капкандай кабаланып, безгә Хәерниса апа килеп керде. Йөзендә куаныч, кош тоткан диярсең... Ул киң елмайды да, әйтеп куйды: «Абыстай, Фәйзерахман абзыйлар кайта икән, фатир таба алмыйсыз икән дип ишеткән идек без. Шуңа күрә, әйдә, безгә

[9] Өйләре конфискацияләнү вакыйгасы чынлыкта 1930 елда булгандыр. Чөнки Түнтәр районы 1930 елның 10 августында төзелгән, 1932 елның 2 март карары белән Балтач районы дип үзгәртелгән.

алыйк дип сөйләшкән идек Баһаветдин белән. Безнең өй ул, үзегез беләсез, әлләни зур түгел инде. Безгә алты кешегә тар була дип әйтмәсәгез генә инде». Әби белән әнинең куануының, Хәерниса апага яудырган рәхмәт һәм догаларының чиге-чамасы булмады. Кайда анда тар булу турында уйлау! Кыш чыгарга бер җылы куыш булгач, ни кирәк безгә?! Мин әле бүген дә сокланып, гаҗәпләнеп, Хәерниса апа белән Баһаветдин абыйны искә алам... Чама белән егерме квадрат метрлы бу йортның яртысыннан байтак артыгы олы як дигән бүлмә иде. Кече якка калган өлеш 7–8 квадрат метр булырмы, аның да чама белән яртысын мич биләп тора. Калган мәйданда өч җан иясе, бала бишеге...

1940 елның җәендә, Казанга күчеп киткәнче, безгә тагын дүртме-бишме йортка күчәргә туры килде. Алты кешелек гаиләне сыйдырыр өчен йортың никадәр генә зур булмасын, үзеңә кысанлыкка түзмичә булмый. Түзделәр кешеләр, безне урамда калдырмадылар. Мең рәхмәт аларга![10]

1934 елның сентябрендә Түнтәр мәктәбенең беренче классына укырга кердем. 1940 елда алты классны тәмамлагач, гаиләбез Казанга күчеп китү аркасында, укуны Казанның 49 нчы мәктәбендә дәвам иттем. 1941 елда җиде классны тәмамлап, укуны бүләргә туры килде. 1942 елның җәендә олы абыем Мансурның армиядән авырып кайтуы аркасында гаиләбез кире Түнтәргә кайтты һәм мин 1943 елның ноябренә кадәр Киров исемендәге колхоз тимерчелегендә чүкеч сугучы булып эшләдем. Ноябрьдә армиягә алынып, Белоруссияне азат итү сугышларында катнаштым. Авыр яраландым. Җиде ай Моршанск (Тамбов өлкәсе), Баку шәһәрләрендә госпитальләрдә дәваланып, җәрәхәтләр җөйләнгәч, икенче группа гариплек таныклыгы биреп, мине хәрби хезмәттән азат иттеләр. Һәм мин Киров өлкәсе Малмыж шәһәренә әти-әниләрем янына кайттым. Алар инде Түнтәрдән анда күчкәннәр иде. Шулай итеп, сугышның соңгы елы башында безнең гаилә бергә җыелды. Тик шуны-

[10] Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык: хакыйкатьне тарихка әверелдерү юлында 15 ел. – Казан, 2006. – Б. 89–95.

сы бар: әти белән әнинең сугыш башланыр алдыннан әле исән булган, инде үсеп җиткән дүрт баласыннан тик мин генә исән калдым... Химия-технология институтының механика факультетын тәмамладым. Укып бетереп, эшли башлагач та үтәлергә тиешле иң беренче бурычым – әти-әниләремә ярдәм итә башлау, аннан мөмкинлек табып, аларны үз яныма алып килү дип таный идем. Мин укуны дәвам иткән сигез ел вакытның алты елын алар миннән читтә кыенлыклар күреп яшәделәр. Икесе дә авыру, яшьтән үк тулы тазалыкка ия булмаган бу җан ияләре гомерләренең соңгы 35 елы дәвамында күргән иксез-чиксез золым, кайгы-хәсрәт, авырулар, куркытылулар, мәсхәрәләнүләр, мохтаҗлык, тагын әллә ниләр, әллә ниләр...»[11].

Бу өземтәдә «...үсеп җиткән дүрт баласыннан тик мин генә исән калдым» дигәндә Фарукның аңарчы вафат булган өлкән туганнары – Мансур (1916–1943), Мәрьям (1921–1941) һәм Касыйм (1924–1943) күздә тотылган. Тагын ике кардәшләре: Мәхмүт белән Хәсән кечкенә вакытларында вафат булганнар. Мансур исемлесе 1941 елда сугышка алынып, башта дәһшәтле Суслонгерда җәфалар чиккәнлеге мәгълүм. Касыйм исә сугышта яраланган һәм һәлак булган. Мәрьям фельдшерлык белгечлегенә укуын тәмамлап килгәндә, 1941 елның май аенда дөньядан киткән.

Фарук Нәкыйповның «Тарих һәм чынбарлык» исемле китабы 2006 һәм 2010 елларда нәшер ителде, соңгысында авторның, әти-әниләренең һ.б. туганнарының фоторәсемнәре дә бирелгән.

Мөхәммәтнәкыйп хәзрәтнең 1930 елда ГПУ тарафыннан хөкем ителүенә бәйле архив эше Татарстан Республикасының Милли архивында сакланган[12]. Әлеге тикшерү эшенең кыскача мәгълүматы Рәфхәт Зариповның «Бакыйлыкка күчкән әби-бабаларыбыз рухына бер дога» (Түнтәр, 2021) китабының 146 битендә басылган. Анда Мөхәммәтнәкыйп Ишмөхәммәтевнең 1917 елга кадәрге тормышы, әтисе – Иш-

[11] Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык..., 2006. – Б. 10–12.
[12] Нәкыйпов Ф. Тарих һәм чынбарлык..., 2006. – Б. 73.

мөхәммәт Динмөхәммәтевнең 1919 елда атып үтерелүе, совет чорында түләгән салымнарының күләме һ.б. турында язылган. Р.Зарипов Түнтәр авылында алар яшәгән йорт турында да искәрмә биргән.

Мөхәммәтнәкыйп хәзрәтнең һәм гаиләсенең тормышлары һәм катлаулы язмышлары турында аерым китапларда язылды, шулай ук газета-журналларда мәкаләләр булды. Балтач районындагы мәчетләр тарихына һәм дин әһелләренә багышланган махсус китапта бу хәзрәт турында бик кыска гына язылып (нибарысы 7 җөмлә), «...5 елга концлагерьга хөкем итә, гаиләсе авылдан куыла. Аның һәм гаиләсенең аннан соңгы язмышы билгеле түгел»[13] дигән сүзләр чынбарлыкка туры килми. Шул ук китапта Мөхәммәтнәкыйп хәзрәт имам булып торган Түнтәр авылы мәчетенең 1939 елда ябылганы язылса да, «кызганыч, шушы чоргача анда кем имамлык иткәне тәгаен билгеле түгел»[14] дип әйткәндә дә матбугат мәгълүматлары исәпкә алып җиткерелмәгәнлеге аңлашыла.

Фарук ага Нәкыйповта сакланган хатирә язмаларының һәм хатларның күчермәләре Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин тырышлыгы белән 2004 елда алдырылган иде. «Хәятым тарихында булып кичкән бәгъзе вакыйгалар вә хәлләр» кульъязмасының күчермәсе китапханәдә «4892т» шифры белән саклана.

1930–1935 нче еллар

1930 нчы елның 4 нче мартында кулга алынып, Арчага йибәрелдем. Арча хәбесханәсендә 25 нче мартка кадәр яткан соңында, 25 нче мартта Казанга йибәрелдем.

Казан хәбесханәсендә вакытта мине 5 елга концлагерьгә хөкем иткәнлекләрен игълан итеп, июль 19-нда ятап белән

---

[13] Мөхәммәтшин Г. Балтач мәчетләре: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2018. – Б. 289.

[14] Шунда ук. – Б. 292.

Архангельскигә йибәрделәр һәм Архангельскидән 15 чакрым читтә, Двина суы буенда «2 нче лесобиржа»[15] дигән лагерьгә китерделәр. Декабрь башларына кадәр анда эшләдек.

5 нче декабрьдә безне ул лагерьдән чыгарып йибәрделәр. 6-сында поездга утырып киттек вә 12-сендә Соликамски[16] дигән кечкенә бер шәһәргә килеп, 14-ндә аннан 120 чакрым ераклыкта булган Вишер суы буендагы «Вишерский лагерь»гә җәяүләп чыгып киттек һәм 19 нчы декабрьдә лагерьгә килеп йиттек.

Ул лагерьдә 30 нчы декабрьгә кадәр торган соңында, мине шуннан 6–7 чакрым ераклыкта булган «Соянка» исемендәге инвалидлар командировкасына[17] йибәрделәр.

31 нче ел 7 нче июньдә безне аннан «Кожинский участка» дигән икенче командировкәгә китерделәр вә беркадәр вакытлар шунда эшләп калдым. Авырып китүем сәбәпле, мине аннан 23 нче июньдә төп лагерьгә лазаретка озаттылар. Лазаретта 8 көн кадәр ятып, сәламәтләнгәч, беркадәр лагерьдә эшләгәннән соң, 7 нче июльдә «Сторожевой» исемендәге командировкәгә йибәрелдем.

15 нче августта безне район мәркәзе булган Бараний Лог[18] дигән урынга йибәрделәр. 8 нче сентябрьдә Щугор[19] дигән командировкәгә, анда бер атна торгач, кире Бараний Логка йибәрелеп, аннан 19-нда Пармага[20] килдек.

Аннан безне якындагы «58 нче квартал» дигән команди-

---

[15] Бу лагерь 1925–1937 елларда гамәлдә булган.

[16] Әүвәлге Пермь губернасында *(автор искәрмәсе).*

[17] «Командировка» дип төп лагерьнең кечкенә шөгъбәләренә әйтәләр *(автор искәрмәсе).*

[18] *Бараний Лог* – Вишер елгасы буендагы бистә, район үзәге. 1931 елда Вишлаг идарәсе тарафыннан 2 нче санлы санитар шәһәрчек буларак нигезләнгән. Анда лагерьның ремонт цехы, дезокамера, мунча, аптека, почта һ.б. оешмалар урнашкан. Илнең төрле почмакларыннан китерелгән тоткыннар 4 баракта яшәгән, алар трактор базасында һәм кәгазь заводында эшләгәннәр. Бараний Лог хәзерге вакытта Красновишерск шәһәренең бер өлеше.

[19] *Щугор (Щугер)* – хәзерге Коми Республикасындагы елга исеменә нисбәт ителгән атама. Печора елгасының уң ягындагы кушылдыгы.

[20] *Парма* – Пермь өлкәсенең Чердынь районындагы бистә.

ровкәгә йибәреп, шунда мин 1932 нче ел 28 нче апрельгә кадәр эшләдем. 28 нче апрельдә ятап белән без Пармага, аннан 7 нче майда Бараний Логка килеп, 8-ндә баржаларга утырып, аннан кузгалып китеп, 12-сендә Кама елгасы буендагы Усолье[21] шәһәренә килдек. 13 нче майда поездга утырып, аннан сәфәр кылдык һәм 19-нда Ленинград-Мурман тимер юлы өстендә булган Сегежа[22] ыстансасы якынындагы 12 нче лагерьный пунктка килеп төштек. Бу лагерь Ак диңгез белән Балтыйк диңгезләрен куша торган каналны эшләүчеләр өчен махсус ясалган бик зур лагерьдыр.

Беркадәр вакытлар анда эшләгәннән соң, безне 2 нче июльгә «Выг озер» дигән күл өстенә китереп, эшкә куштылар.

25 нче августта мин үземнең лагерьдән азат булуым хакында хәбәр алдым. 26-сында лагерь идарәсенә кайтып, тиешле язуларны алдым. Лагерь идарәсе Майгуба[23] дигән ыстансада иде. Миңа анда калган срокны тутыру өчен 12 шәһәрдән башка бер йирне («12 минус» дип әйтелә) ихтыяр итү хакында тәкъдим ясадылар. Мин дә Ульяновски шәһәрен ихтыяр итеп, миңа шунда кайту өчен азыклар һәм билет өчен акча биреп йибәрделәр.

2 нче сентябрьдә поездга утырып, Майгуба ыстансасыннан кузгалдык һәм 6-сында кич Ульяновскигә килеп йиттек. Шуның белән минем ике ел ярымлык тоткынлык хәятым тәмам булды.

(Үземнең тоткынлык вакытларымда үткән тормышымны тәфсиллерәк рәвештә «Тоткынлык көннәрем» исемендә бер рисалә шәкелендә язып куйган идем).

Югарыда әйтелгәнчә, мин җәза мөддәтемнең калганын тутыру өчен, үземнең ихтыяр итүем белән, Ульяновски шәһәренә кайттым. Лагерьдән миңа Ульяновски милиция идарәсенә тапшыру өчен кәгазь биреп йибәргәннәр иде. Ульяновскигә

---

[21] *Усолье* – Пермь өлкәсендәге шәһәр, район үзәге.

[22] *Сегежа* – Карелиядәге Выгозеро күленең төньяк-көнбатыш ярында урнашкан шәһәр.

[23] *Майгуба* – Выгозеро күле буендагы бистә.

килгәч мин шул язуны милиция идарәсенә тапшырып, кулыма өч айлык вакытлы бер документ бирделәр һәм «өч ай тулгач, монда килеп алыштырырсың» диделәр.

Мин Ульяновскидә ахунд хәзрәт, Мирсәед мулла һәм башка берникадәр мөселманнар белән таныштым. Ләкин анда һичбер фатир таба алмый, гаҗиз булдым. Кич белән «Колхозник йорты»на кереп йоклый идем. Ә көндез базарда, урамда йөреп үткәрә идем. «Колхозник йорты»нда иртә белән сәгать 6-дан соң, кичкә кадәр бер кешене дә тотмыйлар, бикләп куялар иде.

Көзгә таба һавалар суык вә яңгырлы, былчырак була башлады. Өст-баш та, әлбәттә, начар, тамак та ачлы-туклы гына. Көненә ике мәртәбә генә ысталавайга берәр нәрсә белән ризыкланып чыктым. Намаз вакытларында зиярат өстендәге мәсҗидкә барам. Бәгъзән аннан берәрсе өенә алып китеп вә бәгъзән йоклатып та чыгара иде.

Шулай йөри торгач, миңа Мирсәед хәзрәт (зияраттагы мәсҗиднең имамы) базарда инә белән сату итәргә киңәш бирде һәм үзе бер йирдән бераз инә дә табып бирде. Мин акрынлап сатуга керештем. Баштарак көненә 50–60 тиенлек вә соңрак 1–2 сум кадәр, хәтта бәгъзән көненә өчәр сумлык инә сата торган булдым. Соңрак моның чыга торган мәнбәгъләрен дә таптым. Шулай итеп, минем тамак мәсьәләсе бер дәрәҗә рәтләнеп китте. Бу вакытларда Сәгъди агай дигән бер адәмнең (Аллаһның рәхмәтендә булсын) өенең аскы катында бер бүлмәсе бушагач, миңа шунда кереп йокларга вә шунда торырга вакытлы рәвештә рөхсәт итте. Ләкин ул бина таш булып, ягылмаганлык сәбәпле, әлбәттә, салкын буладыр иде. Һәрхәлдә, минем өчен бу яхшы булды.

Ләкин тормыш шулай бер дәрәҗә юлга салына башлады дигәндә генә, икенче бер мәсьәлә килеп чыкты. Минем шикелле, лагерьдән кайткан берничә имамнар миңа очрап, хәлләрне сорашканнан соң, минем монда Ульяновскигә кайткач ГПУгә явитсә итмәгәнлегемә бик тәгаҗҗеб иттеләр һәм «Буңа кадәр анда бармый йөрүең белән син бик хата эшләгәнсең. Әгәр син

аларның бер кулына төшсәң, сине кире лагерьгә йибәрерләр» дип, бик куркыттылар. Мин дә аптырап калдым.

Берничә вакытлар шулай тәхәйердә йөргәннән соң, Аллага тапшырып, ГПУгә барып күрендем вә милициядән алган язуымны бирдем. Анда минем язуымны алып калдылар һәм икенче көнгә чакырып, миңа Мәләкәс[24] шәһәренә китәргә куштылар. 5 нче октябрьдән калмый, Мәләкәс ГПУ-сына тапшыру өчен кулыма язу бирделәр.

Мин бер ай кадәр вакыт үтеп тә ГПУгә күренми торуым өчен бер төрле дә шелтә-фәлән булмаганлыктан, аннан сөенеп чыктым. Чөнки мин әллә нинди берәр төрле җәза бирмәгәйләр иде дип, бик куркып барган идем. Нәтиҗә игътибары белән, бәлки, бу эш минем өчен хәерле дә булгандыр. Ләкин үземнең болай ГПУгә барып керүем бер зур хата икәнлеген мин соңыннан аңладым. Чөнки лагерьдән минем шикелле срогын тутырмыйча кайткан адәмнәрне, әгәр дә эшләре йиңелрәк булса, милиция карамакына йибәреп, авыррак вә зуррак эшлеләрне ГПУ карамакына йибәрәләр икән. Минем, кеше сүзе белән, анда барып керүем үземнең наданлыгымнан булган икән.

Мин Ульяновскигә килгәч тә, Сәгъди агайның адресын күрсәтеп, өюгә хат язган идем һәм мөмкин булганда рәфикамның килүен үтенгән идем. Шул сәбәпле, мин шул көннәрдә алардан бер хат килүен яки үзләренең килеп чыгуын көтә идем. Шул сәбәпле, минем өчен Мәләкәскә китеп бару уңгайсызрак булды.

Мин 4 нче октябрьдә Мәләкәскә китеп бардым. (Ульяновски белән ике арасы 5–6 сәгатьлек юл). Мәләкәс ГПУсы миңа һәр ай башында күренеп, кайд кылдырып торырсың, дип, Мәләкәстән чыкмау шарты белән, бер язу бирде.

Мин Ульяновскидән киткән көндә кич минем рәфикам, угылым Мансур белән бергәләп, Ульяновскигә килгәннәр. Иртәгесе көн минем артымнан алар да Мәләкәскә килеп, алар белән дә күрешеп шатланыштык, әлхәмде Лилләһи.

---

[24] *Мәләкәс* – Ульяновск өлкәсендәге шәһәр, исеме 1972 елда Димитровград дип үзгәртелгән.

Мәләкәстәге тормышым

1932 нче ел 4 нче октябреннән 1935 нче ел 2 нче февральгә кадәр булган гомеремне элекке Самар губернасы Мәләкәс шәһәрендә кичердем. Мин Мәләкәскә кайткан вә анда торган еллар тормышның кыйммәтчелек вә агыр еллары иде. Бинаән галәйһи, анда тормышым, хосусан әүвәлге елларда, яхшы ук агыр булды. Кулдан килгән бер төрле дә һөнәр юк (ул вакытта чабата да ясый белмидер идем). Агыр вә кара эшләр эшләргә көч вә хәл юк, йиңелчәрәк эшләргә безнең кебиләрне алмыйлар. Сату итәргә кабилият тә, акча да юк һәм ул эш, әлбәттә, куркынычлы да.

Әүвәлге елда акча түләп фатирда торырга тугры килде. Соңгы елымда мәсҗид астындагы (әүвәлдән мөәзин торган) бер бүлмәдә тордым. Мәләкәснең имамы Гатаулла хәзрәт Гыйбадулла угылының минем кеби йибәрелгән мөсафирләргә, хосусилә минем үземә, күп ярдәме тиде. Аның үзеннән һәм аның васитасы белән башка күп адәмнәрдән төрлечә ярдәмнәр күрдем.

Гатаулла хәзрәт бик яхшы гыйлем иясе вә күркәм холык сахибе, имсале аз табыла торган бер мөхтәрәм зат. Аның тарафыннан килгән төрле матди файдалардан башка, мәгънәви-гыйльми җәһәттән дә аннан күп истифадә иттем. Аның сәламәт хәлдә сакланган бай гына көтепханәсе дә минем өчен ачык булды. Ул вакытларда Гатаулла хәзрәт мәшһүр «Касыйдәи бөрдә»гә[25] төркичә шәрех язмакта иде. Минем башка эшем булмаганлыктан, аның шул әсәрен язып[26] бардым. Аннан башка тагын аның «Банәт сөгаде»[27] касыйдәсенә язган гарәбиел-гыйбарә шәрхе һәм гыйльме гаруздан язган төркичә

[25] *«Касыйдәи бөрдә»* – мәшһүр гарәп шагыйре Мөхәммәт әл-Бусыйриның (1213–1296) Мөхәммәт пәйгамбәргә багышланган шигъри әсәре. Бу әсәр мөселман илләрендә һәм татарлар арасында киң таралган. Аның кульязма күчермәләре (еш кына татарчага тәрҗемәләре белән) хәзер дә табылып тора. Әлеге китап 1917 елга кадәр Казан матбагаларында күп басылып чыккан.

[26] *язып* – бу урында «күчереп» мәгънәсендә.

[27] *«Банәт сөгаде»* – Мөхәммәт пәйгамбәрне мактау касыйдәсе, «Касыйдәи бөрдә»нең бер төре.

«Мөгаллимел-гаруз» дигән әсәрен дә күчереп алдым. Ләкин ул «Касыйдәи бөрдә» шәрхен мин аннан китеп барганчы тәмам итеп бетермәгәнлектән, анысы натәмам калды.

Ул вакытта Мәләкәстә мәсҗид дәвам итә торган булганлыктан, әүкате хәмсәгә мәсҗидкә йөрергә мөмкинлек булып, Гатаулла хәзрәт белән һәрвакыт күрешергә вә утырышырга тугры киләдер иде. Менә шул сәбәпле, Мәләкәстә торган вакытымда мин үземне артык горбәттә кеби хис итмәдем.

Миңа Мәләкәс ГПУсыннан бирелгән кәгазь буенча, миңа Мәләкәстән читкә чыкмаска тиешле булса да, һәм мин башта шулай шәһәрдән читкә чыкмыйча торсам да, тормышның иҗбаре буенча бәгъзән Мәләкәстән читкә дә чыккаларга тугры килде. Мәләкәстән 30 чакрымнар чамасы ераклыкта булган Өч Каен[28] исемле бер авылга, бәгъзән чакырылып вә бәгъзән чакырылмыйча, барып кайткаладым. Шулай ук аның якынында булган берничә пүчинкәдә дә булдым. Ул авыллар миңа зур ярдәм иттеләр. Алар икмәкле, тук авыллар иде. Болай да ул тараф халкы гыйлем әһеленә мәхәббәтле, ярдәмле халыклардыр.

1933 нче елның, җәе буенча дип әйтерлек, урманда нарат утырту эшләрендә (орлыгын җыю, аны чәчү, күчереп утырту, урыннарын йомшату кеби) эшләдек. Бу вакытта без (үзем кеби иптәшләр белән) күбрәк урманда гомер кичереп, шәһәргә – фатирымызга атнада бер-ике мәртәбә генә кайтып киләдер идек. Тагын көзгә таба беркадәр вакытлар ниндидер бер артельнең яшелчә бакчасында каравыл хезмәтендә тордым.

Мәләкәстә торылган ике ел да 4 ай кадәр вакыт эчендә рәфикам өч мәртәбә миңа зиярәтән килеп китте. Беренче мәртәбәсендә олуг угылым Мансурны, икенчесендә кызым Мәрьямне, өченчесендә кечек угылларым Касыйм белән Фарукны алып килеп күрештерде.

Шул рәвешчә, Мәләкәс шәһәрендә тиешле мөддәтемне тәмам иткәннән соң, мин 1935 нче елның 2 нче февралендә аннан китеп бардым һәм 14-ндә, сәламәт, ватаным Түнтәргә

[28] *Өч Каен* – Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районындагы авыл.

кайтып йиттем. Ул вакытта минем гаиләм авылымызның Газиз исемле бер адәмнең йортында торалар иде. Әнкәем, рәфикам, өч угылым вә бер кызым сәламәтләр иде. Фәкать әнкәемнең күзләре күрмидер иде инде.



Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри кульязмасы

1936–1940 нчы еллар

5 ел кадәр бер вакыт аерылып торган туган илемә – ватаныма кайту, андагы дуст-иш вә кардәш-ыруглар белән күрешү, хосусан, сөекле гаиләм янына кайтып күрешү, бигрәк тә 5 ел күрә вә күрешә алмыйча, сагынып торган кадерле әнкәм янына кайту-күрешү – минем өчен зур шатлык иде, әлбәттә. Моның белән мин хисапсыз шатландым. 5 еллык бер мөддәт тоткынлык вә горбәтчелек тормышында гомер кичереп, төрле агыр вә куркынычлы дәкыйкәләрне баштан уздырып та, сәламәт хәлендә ватанга кире кайту, әлбәттә, зур бәхет иде.

Ләкин авылга кайтып керү белән, минем күңелем тагын тынычсызлана башлады. Алдагы тормышта тагын әллә ниләр булыр кебек, күңел курка башлады. Үземне тагын бер җинаять эшләгән гаепле бер кеше кеби хис итә башладым.

Ул вакытта безнең мәсҗид әүвәлгечә дәвам итеп, анда карт мөәзинемез Мөхәммәтҗан абзый имамлык хезмәтен үтәп торадыр иде. Мин кайткач, халыкның үтенүе буенча, башка төрле тормыш юллары хакында уйлап карамыйча, әүвәлге хезмәтемә, ягъни имамлык хезмәтенә керешеп киттем.

Әүвәлге ел тыныч узды дип әйтергә мөмкин. Фәкать аннан соң авыл советы тарафыннан бер-ике мәртәбә урман кисәргә йибәрү, юл эшләргә чыгарулар булгалады һәм азлап налоглар вә ит заданияләре дә сала башладылар. Болар елдан-ел арта барды, торган саен авырая барды. Хәтта соңга таба гаҗизлек дәрәҗәсенә китерде.

Олуг угылымыз Мансур 35 нче елда 7 классны мәктәпне тәмам иткәч Казанга китеп, бер эшкә кереп урынлашты. Берәр елдан кызымыз Мәрьям дә Казанга фельдшерлек мәктәбенә укырга китте. Вә аннан соң икенче угылымыз Касыйм да мондагы мәктәпне тәмам итеп, Казанга – Елга техникумына укырга китеп барды. Без авылда әнкәмез һәм кече угылымыз Фарук белән дүртәү калдык. 1939 нчы ел гыйнварында әнкәмез дә вафат булды, без өчәү калдык. Шуннан соң без үземез дә Түнтәрдән китеп бару хакында фикер йөртә башлап, шул хакта бәгъзе тәшәббесләр дә иткәләдек.

Түнтәрдәге көн күрешемездән без разый булсак та, налоглар безне бик борчыйлар иде. Моның өстенә, шул 39 нчы елның июль аенда безнең мәсҗидемез дә алынды. Инде мәсҗид булмаган хәлдә, анда имам исемен күтәреп тору, әлбәттә, бик мәгънәсез бер эш булачак иде. Халыкның да бу мәсьәләгә карашы салкынчарак күренде. Бинаән галәйһи, без инде Казанга барып, балаларымыз белән бергә торуны уйлап, бөтен налогларымызны бар көчемез белән түләп бетереп, авыл советыннан тиешле язуларны алгач, 1939 нчы елның 13 нче декабрендә рәфикам белән икәвебезгә паспортлар алдык.

Ләкин Казанда безгә квартир табуы бик авыр булды. Моның өчен озак йөрергә тугры килде. Ниһаять, 1940 нчы елның 11 нче июлендә без бөтенләй күченеп, Түнтәрдән чыгып киттек һәм 12-сендә Казанга килеп йитеп, иля машаллаһ, шунда торып калдык.

Мөхәммәтнәкыйп Түнтәри гаиләсенең шул елларда язышкан хатлары

1. Мөхәммәтнәкыйпкә хатыны Өммегөлсемнән. 1930 ел.

Кадерле вә кыйммәтле иптәшем!

Догалар үтенеп, өзелеп-өзелеп сагынган сәламнәремне йибәреп, сәламәтлегеңне теләп калам.

Әнкәй һәм балакайлар һәммәсе сагынулы сәламнәрен йибәреп, дога үтенәләр.

Бездә, әлхәмде Лилләһи, бер хәлчә, сәламәтлек әлегә. Тик балакайлар гына йөткерешеп, авыргалап йөриләр.

Июнь 25-ндә язган ачык хатыңны алып, сәламәтлегеңә сөендек, язуың өчен зур рәхмәт. Көннәр дә бик суык булгач, юлда яңадан авырып китүеңнән бик куркып торган идек. Җәнабе Хак моннан соң да барчаларыбызга хәерле сәламәтлек биреп, тизлектә шатлыклар илә күрештерсә иде, амин.

Яңадан озын хатың килерме дип көн дә көтәм дә – күренми әле. Хат килгәч тә салырга хәзер булсын – язып куярга уйладым.

Син киткәннән соң, киткәнеңне ачык белә алмыйча, Ка-

занда 3 көн йөрдем, 22-сендә[29] кайттым. Аннан соң әткәй дә Казанга йөреп, шушы көннәрдә генә туганым белән бергә кайтты. Тәлгатьләр элек кайтканнар иде. Әткәйнең күзенә операция ясатыр өчен сентябрьдә килергә кушканнар.

Балаларда коклюш булыр ахры, йөткеренәләр. Мәрьям, Фарукның бераз сирәкләнеп баргандай. Касыйм яңарак йөткерә башлагангамы, аның бик куәтле әле.

Менә хатым шушы йиргә йиткәндә генә синең тарихы язылмаган, адреслы хатыңны алып, сәламәтлегеңне белеп сөендек. Ходаем моннан соң да сәламәтлегеңдә даим әйләп, бергә-бергә шатлыклы тормышлар насыйп әйләсә иде, амин.

Эше бик авырдыр, инде Хода үзе ярдәмче булсын. Сәламәтлегең ни хәлдә соң? Бу яктан иптәшләр бармы? Кемнәр бар?

Сиңа бик озын итеп хат язмакчы булып утырган идем, хатыңны укыгач рәтем китеп барды әле. Яза белмим инде.

Халык печән артыннан йөриләр, «бер атнадан арыш та ура башларлык булыр» дип сөйләшәләр. Арыш уртача, сабан яхшы диләр. Ашлыкларны бер дә күргән юк. Каты суканы сукалаттык, 2 дисәтинәдән аз гына кимрәк булырга кирәк. Мансурга уракка йөрү өчен йирләр бик ерак инде. Ялгыз бик кыен булыр дип, үзем дә йөрергә уйлап карыйм да, әнкәйнең күзе күрмәгәч, балалар белән калдырып булмый. Аның үзен тәрбияләргә кеше кирәк.

Тормыш, әлхәмде Лилләһи, мохтаҗлык юк, һәммә нәрсә бар, тик син генә юк. Шунысы үзәкләрне өзә... Бер нәрсәнең дә шатлыгы күзгә күренми.

Синең китүне белгәч балалар бик борчылыштылар, берничә көнгә кадәр җуата алмыйча аптырадым. «Озак тормый ул, анда баргач, тизрәк кайтыр» дип, төрле хәйләләр белән җуата торгач, хәзер бераз алданып көтеп йөриләр әле. Ни генә булса да, син кайтуга җурыйлар. Фарук һәр көнне чәйгә ипиен сала да, үзе «Әти кайта!» дип сөенә. Җәнабе Хак шулар хакына тиздән шатлыклы көннәр насыйп әйләсә иде, амин.

...нең беләсең инде, аның кайгы белән күп эше юк. Һаман

---

[29] *22-сендә* – 1930 елның 22 июле күздә тотылган. Ире Мөхәммәтнәкыйп аңарчы – 19 июльдә Архангельскига җибәрелгән.

да бакчага агачлар утыртып, чәй урыннары ясау белән аптырата әле.

Бөтен кайгы ялгыз башыма кала. Балалар алдында борчылганымны күрсәтергә дә куркам инде, алар борчылуы бигрәк йөрәкне әрнетә. Бер Алланың үзенә тапшырдым.

Сасналар[30] исән, әти сиңа сәлам язарга кушкан иде. Бу арада анда барып кайттык әле. Кызлар Арчада, абзый өйләнердәй әле. Әнәс тә вафат, абзыйны бик борчыла, диләр.

Шодалар[31] да исәннәр, ил-күрше дә исәннәр. Фатыйма түти вафат, Әхмәтша карчыгы.

Бәрәңгеләр чәчәк атты, әле ашый башлаганнар юк. Алма агачлары бар да чәчәк аткан иде, суык тиде.

Хуш, җаным! Сәламәт торып, шатлыкта күрешүләребезне теләп, иптәшең Өммегөлсем.

1930 нчы ел.

2. Мөхәммәтнәкыйпкә хатыны Өммегөлсемнән. 1932 ел.

Җанымнан да кадерле иптәшем Мөхәммәтнәкыйп!

Сине бик-бик сагынып, йөрәгемнең эчләреннән чыккан самими сәламнәремне йибәреп, догалар үтендем вә Ходадан сиңа сәламәтлек һәм тиздән шатлыклы күрешүләр теләп калам.

Әнкәй һәм балакайлар: Мансур, Мәрьям, Касыйм, Фаруклар сагынып-сагынып, күп сәламнәр әйтеп, догалар үтенәләр.

Бездә бер хәлчә, сәламәтлек әлегә. Гыйнварда (ничәсе икәнлеге хәтеремнән чыкты) бер көнне телеграм илән 10 сум акча, 2 нче көнне балалар ябык, мин ачык хат, 3 нче көнне посылка салган идек, тапшырылулары [ничек булгандыр]? Тапшырылуын белмәгәч эч пошып тора. Үзеңнән бер дә...

Хуш, җаным! Сәламәт бул, рәхәт тор!

1932 нче ел, февраль 20.

... иптәшең Өммегөлсем.

---

30 *Сасналар* – хат авторы Өммегөлсемнең Сасна авылында (Балтач районында) яшәгән этиләре һәм башка туганнары.

31 *Шодалар* – Мөхәммәтнәкыйп хәзрәтнең Шода авылында (Балтач районында) яшәгән бертуган апасы Фатыйма гаиләсе.

3. Мөхәммәтнәкыйптән биатасы Сөләйман хәзрәткә. 1932 ел.

Би-исмиһи Сөбханәһә.

Әлфазыйлел-мөхтәрәм бабамыз хәзрәтләреннән догаи хәйрләрен риҗа итеп, тәслимате халисанәләремне юллыйм. Шулай ук мөхтәрәмә әбиемезгә вә газиз бөрадәрләр Фатих вә Закир әфәнделәргә вә Әминә, Хәдичә, Хафизә, Мәрзия вә Фәритләргә – барчасына махсус сәламнәремне юллап, догаи хәйрләрен үтенеп калам.

Үзем, әлхәмде Лилләһи, бер хәлчә, сәламәтлектәмен. Моңа кадәр 20 нче лагпунктка табигъ буларак, су өстендә ай ярымнан артыграк эшләдек. Инде ошбу көн безне ул хезмәтемездән алып, икенче урынга алып баралар. Анда нинди хезмәтләр булыр – хәзергә мәгълүм түгел. Бер Аллаһның үзенә тапшырдык. Җәнабе Хак хәзрәтләре һәркаюларымызга хәерле тормышлар насыйп итсә иде.

Бу хатымны юлдан язамын. Моңа кадәр бу урынымыздан өч мәртәбә хат язган идем, тапшырылу вә тапшырылмавы хәзергә кадәр мәгълүм булмады. Үзем фәкать Өммегөлсемнең ике хатын алдым, берсе 5 июль вә икенчесе 18 июль тарихлы. Башка хатлары тапшырылмады. Үзем соңгы хатларымның берсен Түнтәр адресы, берсен Шодалар адресы белән вә берсен дә сезнең адрес белән йибәргән идем.

Бу хатым бәрабәрендә балаларга дип язган бер нәрсәмне йибәрәмен һәм сездән үтенәмен шуны бер мәртәбә күздән кичереп, хатасы булса, төзәтүеңезне вә үземә тәнбиһ итүеңезне, һәм шул нөсхәне балаларга йибәрүеңезне.

Аз булса да, бәгъзе вакытларда укырга һәм язарга фәрагать булгалый. Ләкин укырга кулымда һичбер нәрсәм юк. Өюгә «әгәр посылка йибәрә калсаңыз, «Касыйдәи бөрдә» вә «Әсма Аллаһуль-хөснә» йибәреңез!» – дидем. Ихтимал, үткәрмәсләрме дип өмид итеп яздым. Ягъни, тиешле мөәссәсә тарафыннан. Русларның кулларында Инҗилләре күренгәли. Бу китаплар мәсьәләсе мәшәкать булса да, әгәр кәефеңез вә вакытыңыз мөсагадә кылса, сезнең дә ярдәмеңезне үтенәм. Башка бер файдаланырдай китап булса да ярый. Мусхәф

Шәрифне сорарга, тапшырылмый калса, кадерсез урыннарда әрәм булмагай иде дип куркам.

Мондагы тормышның хезмәт вә мәшәкатьләренә ул кадәр читенс[енмим], бигрәк гомернең бушка вә файдасызга узуына борчылам. Инде бер хәлемез дә юк, һәрбер эш бер Аллаһның үзеннән. Хәер, ирекле вакытларымызда да безнең бушка үткән газиз вакытларымыз күп булгандыр һәм булды да. Аллаһ хәзрәте үзе гафу кылса иде.

Мөхәммәтфатих кайда хезмәт итә вә башка балалар кайдалар вә ничек торалар? Хат яза калсаңыз, шуларны да язуыңызны үтенәм. Үзеңез дә мәсҗидкә керә аласызмы? Саснадагы башка имамнар кайда?

Хөрмәтле бабам хәзрәтләре! Мондагы тормыш шәраиты, гомернең бушка узуы җәза гына түгел, бәлки касвәтне мөҗәб булуы җәһәтеннән дә күңелне бик борчый. Ничек тә тиз көннәрдән Җәнабе Хак хәзрәте хәляс итсә иде. Зинһар, догада була күреңез?

Безне сораучы ил-күрше вә әхбабның барчасына махсус сәламнәремне сөйләп, догаларын үтенеп калам.

Ихтирам белән киявеңез Мөхәммәтнәкыйп бине Ишмөхәммәд.

20 август, 1932 сәнә.

Әүвәлге адресым белән хәзергә хат язмый торыңыз, икенче хатым булганчага кадәр.

Янымда марка вә акчам булмау сәбәпле, хатымны түләп ала торган итеп салам, гаеп итмәңез?!

4. Мөхәммәтнәкыйпкә биатасы Сөләйман хәзрәттән. 1932 ел.

Әлфазыйлел-мөхтәрәм киявемез Мөхәммәтнәкыйп хәзрәт җәнабенә халис вә самими сәламемне гарыз итеп, хәер-догаларын үтендем.

Бу тараф без һәм әүлад, вә әүладел-әүлад һәммәләребез дә исәннәрбез. Барысы да җәнаб хәзрәтеңезә сәлам әйтеп, догаихәйреңезне үтенәләр.

Тарафыңыздан Ульяновскига килгәч сентябрь 11 нчедә мәктүб бер хат, 14 нче мәрсүм 2 нче хат ирешеп, фәүкыльгадә мәмнүн булдык. Моннан соң үзеңезне күреп, күрешеп, мәсрурияте там насыйп улгай дия, Җәнабе Раббил-галәмин хәзрәтендин өмид тотып торырмыз.

Без бер төрле генә, сәламәтбез. Картлыкка башка зарарлы эш юктыр. Әмма картлык килеп җитте. Сезне күргәнчә тора алсам ярар иде диям, насыйп нәдер – белмәм. Бу мәктүбемлә бәрабәр 11 сум гына иганәт пиреват кылдым, аз һәм булса мәкъбүл итәсез.

Ульяновскига килүеңезгә барыбыз да шат булдык. Өммегөлсем якында барырга хәзерләнеп йөрер. 25 сентябрь бездә булды, 30 [су]м иганәт пиреват салганыны сөйләде. «Касыйдәи бөрдә»нең ике шәрхене һәм мәтенене Өммегөлсем тапшырыр, инша Аллаһу Тәгалә.

Үзеңезнең Балтыйк лагереннан мәрсүл хатыңызда «Хифыз ит иманым, Аллаһ» касыйдәсе сәвелеп укылмак вә тәкрар ителмәктәдер. Сәгыеңез иншадыңызлә мәшкүр вә мәәҗүр улгайсыз. Аллаһы Тәгаләдән тәкрәр бунын имсаленә муаффәкъ улгайсыз, дия сорыймыз. Мулла Зариф Орыйга язып ирсаль итеп ирдем, күп рәхмәтләр әйтеп, хәер-дога кылып язмышлар.

Ул зат җәнабеңезә сәлам әйтеп, хәер-дога үтенмешләр. Аяклары бик зәгыйфьләнеп калды, быел үз йортыннан чыкып йөри алмаганы беленәдер.

«Ин талә гомри фә-Аллаһу йәҗмәгуна вә ин җаәә мәүтуна сәламүн галәйкүм» дия, хәтме кәлям иттем.

Әһлиям илә һәр икәвемез хәер-догалар үтенеп, ракыйм Сөләйман ибне Дауд.

1352 һиҗри 27 нче җөмадел-әүвәл, 1932 нче м[илади] 27 нче сентябрь.

Балтыйк лагереннан мәрсүм мәктүбеңездә касвәттән мәшьүм улуны белдерепсез. Бездәге касвәтләр фәүкыльгадәткә әверелде инде, әзаләһү Аллаһу Тәгалә би-фазлиһи вә кәрәмиһи җәлли җәлаләһү.

Мөхәммәтнәкыйп муллага
Мәләкәс шәһәре имамы Гатаулла хәзрәт язган хат. 1936 ел.

Инна Лилләһи вә инна иләйһи раҗигун.

12 апрельдә мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәт вафат улып, 15-ндә, чәһаршәнбә көн, сәгать 17-дә дәфен ителмеш. Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васыйгатән.

Яше 78-дә улып, ике җомга кадәр сырхау вә хәлсез вә карыйлык сәбәпле вафат итмеш. Үлгәнчә гакылы сәламәт, теле ачык булган. Фәкать үләргә 1/2 сәгать[32] калган соң дөнья сүзене куеп, зикер-фикер берлә мәшгуль улмышдыр.

Җеназасында меңнән зиядә әһали хазир улып, бөек ихтирам берлә тәшйигъ итмешләрдер. Үзенең васыяте буенча, җеназасыны мәхәллә имамы Җиһангир Абызгилдин[33] укыган. Җеназа мәрасимендә һичбер төрле нотык-фәлән сөйләнмәгән. Нәзарәтнең дә матди җәһәте шәп вакыт тугры килү сәбәпле, зиратта күп сәдакалар өләшелгән.

Үзенең бөтен әсәрләрене Диния Нәзарәте файдасына вәкыф итеп калдырган. Иң соңгы әсәре 3 бөек мөҗәлләд хәдис китабы «Әл-бәлягыль-мөбин» исемле китаптыр.

Фәкыйреңез һәм җеназасында булу фикере берлә бардым. Ләкин поезд ул көндә 15 сәгать кадәр тәәххер итте (крушение булган). Фәкать дәфен кыйлып, җәмәгать тәмам кайтып киткәч йиттем, сәгать 20-дә.

---

[32] *1/2 сәгать* – ярты сәгать.

[33] *Җиһангир Абызгилдин* – дин эшлеклесе, педагог, ахун Җиһангир Талха улы Абызгилдин (1875–1938). Дин гыйлеменә, фәлсәфәгә, риторикага, астрономиягә һ.б. багышланган хезмәтләр авторы, 1907–1918 елларда Уфа шәһәренең Беренче җамигъ мәчете имам-хатыйбы һәм «Госмания» мәдрәсәсе җитәкчесе. 1923–1928, 1932–1936 елларда Уфадагы Диния Нәзарәтендә казый. Репрессия корбаны. Кулга алынып хөкем ителгән һәм 1928–1932 елларда Томск өлкәсендәге Нарым краенда сөргендә булган. 1936 елның 22 октябрендә тагын кулга алынып, 1938 елның 17 июнендә атып үтерелгән. 1994 елда акланган.

17 апрельдә, җомга намазында рухына дога кыйлынып, һәүл намазы укылды. Фәкыйрь[34] мәсҗиддә:

– Мөхтәрәм җәмәгать! Мөфти хәзрәтнең тарихе вафаты «Билләһи фәзә бил-Бәлягыль-мөбини, 1355»[35] җөмләсе улачак! – дидем.

Хөсне кабул илә тәләкъкый иттеләр вә шул җөмләне язып алдылар. Тәрҗемәи хәле хакында язылачак рисаләгә дәреҗ иттеләр. Иншалла, тарих сәхифәләрендә сакланачактыр.

Мәрхүм үзе ухрави сәгадәтне шул «Әл-бәлягыль-мөбин» нам китабыны язуыннан өмид итә иде. Шуңар күрә, тарихе вафаты өчен шул җөмләне тәртип иттек. Фә-җәзааһу Аллаһу ганьна хәйрәл-җәзаи.

***

Бөрадәре газиз! Мәктүбеңезне вакытында алдым, рәхмәт илтифатыңызга! Һәм Сибгатулла ага хаты берлә күндерелгән мәктүбеңез дә вакытында тапшырылган иде. Фәкать җавап язу хакында бөек мөсаһәлә иттем. Гафу итәсез?

Һәмишә шул мастерской мәсьәләсе хәл ителгәч язарым дия-дия, калып куядыр. Ул мәсьәлә һәмишә хәл ителми тора.

Бездә, Лилләһил-хәмд, сәламәтлек, тынычлык та бар, тамак тук. Сезне бик сагынамыз. 2 елдан зиядә тордыңыз, ләкин кахытлык еллары тугры килү сәбәпле, сез дә, без дә тамак кайгысыннан күп бушый алмадык.

Әлхаль, Лилләһил-хәмд, туклык бар, нигъмәт күп. Әһали дә мәҗлесләрне ясап торалар, хәтемнәр дә булып тора. Фәкать мастерской юк инде. Май аенда да кайтмаса, бер кечерәк кенә итеп бер бина тәэсис итәрмез диләр. Горсовет «урын бирәмез» диләр. Догада буласыз?!

Сибгатулла агадан хат бар иде, сәламәт икән.

Мәхәллә картлары һәрберсе сәламәт.

Язарлык яңа вакыйгалар юк. Базарлар ачык, ашлык хаклары искечәдер.

---

[34] *фәкыйрь* – хат авторы үзен шулай атаган.

[35] *билләһи фәзә* – билләһи, ул җинде; 1355 – һиҗри (мөселман) календаре буенча 1355 ел григорианча 1936 елга туры килә.

Җәнабе сәгадәтләреңездән догаларыңызны үтенеп, бөтен гаиләңезне шөмулән сәламем, ихтирамым гарыз итәм.

Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Хуш, саг уласыз!

Бөек ихтирам берлә шәйхелислам.

21 апрель 36 ел.



Мәләкәстән Гатаулла хәзрәт хаты

«Төрмәдән юк булды»

Казан шәһәренең мәшһүр сәүдәгәрләре, химаячеләр һәм җәмәгать эшлеклеләре нәселенең вәкиле Габдулла Мөхәммәтйосыф улы Апанаев (1873–1937) 1930 елның февралендә кулга алынып, 1931 елда 58 нче маддә буенча гаепләнгән һәм 5 елга концлагерьга хөкем ителгән.

Габдулла Апанаев лагерь хөкеменнән 1932 елда азат ителеп, «ирекле сөрген» вакытын 1935 елның май аена кадәр Мәләкәс шәһәрендә уздырган. 1937 елның җәендә аны тагын кулга алганнар һәм 26 сентябрьдә атарга хөкем итеп, үлем җәзасы 28 сентябрьдә башкарылган. 1989 елның октябрендә аның гаепсез булганлыгы танылып, акланган.

Габдулла Апанаев.
1920 нче еллар

Апанаевлар шәҗәрәсен һәм Мөхәммәтйосыф Апанаев белән улы Габдулла тарафыннан XIX гасырдан алып 1930 нчы елларга хәтле теркәп барылган нәсел язмаларын бастырган идек[1]. Ул мәгълүматлар арасында Г.Апанаев үзенең 1930–1935 еллардагы тоткынлыгы турында кыскача язып куйган.

[1] Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 47–60.

Ә аның 1937 елда кулга алынуына бәйле хәбәр башка кеше (мөгаен, хатыны Зөләйха) кулы белән теркәлгән. Шул ук елның октябрендә төрмәдән юк булуын белдергән сүзләргә караганда, Г.Апанаевның үлем җәзасына хөкем ителүе һәм атып үтерелгәне якыннарына вакытында белдерелмәгән. Шул ук кулъязмадагы 1938 елда бөтен нәрсәләре конфискацияләнү турындагы сүзләр дә Габдулла Апанаев гаиләсенә карый.

Сәлман Газиз улы Гобәйдуллинның казанлы Казаковларга багышланган мәкаләсендә Мөхәммәтшакир Казаковның өлкән кызы Зөләйха (1874–1954) һәм аның җәмәгате Габдулла Мөхәммәтйосыф улы Апанаев турында да хатирәләр бар[2]. Мәкаләдә аларның тормышы, гаиләсе, сәүдә һәм җәмәгать эшчәнлеге тасвирланган. Мәсәлән, Казан шәһәрендә 1906 елда ачылган мөселман-татар китапханәсе «Китапханәи исламия»не һәм 1908 елда гамәлгә куелган «Шәрык клубы» китапханәсен оештыруга Г.Апанаевның көче кергән. 1913 елда милли музей оештырып, анда Казан шәһәренең мәшһүр гаиләләрендәге борынгы китаплар һәм кулъязмалар, башка төр экспонатлар туплау турында тәкъдим белән чыкканлыгы әйтелгән.

Мәкалә авторы Г.Апанаевның үз улы Ягъкуб кебек, яшерен рәвештә Төркиягә качарга теләп, чиктә кулга алынганын һәм шуның өчен 5 елга сөргенгә җибәрелүе турында язган. Габдулла Апанаев азат ителгәннән соң Казанга – Тукай урамындагы коммуналь фатирның кечкенә бер бүлмәсендә яшәгән хатыны Зөләйха янына кайткан. Аны эшкә алмаганнар. Көннәр буена кибетләрдә чиратлар торып, ризык юнәтергә тырышкан. С.Гобәйдуллин шул авыр чордагы моңсу хатирәне дә теркәп куйган: бервакытны арып һәм туңып кайткан Габдулла Апанаев җылы мичкә сөялеп, башын иеп, акрын тавыш белән күңеле әрнүләрен белдергән икән.

[2] Губайдуллин С. Казаковы // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №2. – С. 214–216. Журнал мәкаләсендә Г.Апанаевның һәм хәләл җефете Зөләйханың, шулай ук башка кардәш-якыннарының фоторәсемнәре дә бирелгән.



Габдулла Апанаев кульъязмасы

«Их, Алла! Ник кенә лагерьдан кайттым соң мин?! Анда мин бригадир булып эшләдем, көнгә өч мәртәбә ашаталар иде. Постельләрне алыштырдылар. Кайгы-хәсрәт юк иде. Минем кул астымда мәдәни, укымышлы кешеләр эшләде. Без дус һәм килешеп яшәдек. Кичләребез кызыклы әңгәмәләр белән узды. Ә монда мин, оясыз эт кебек, шәһәр буенча ризык эзләп йөрим. Гомер шундый кызыксыз һәм буш. Яңадан лагерьга эләгүең хәерлерәк» дигән ул. Ләкин аны озакламыйча – 1937 елда кулга алгач, лагерьга җибәрмәгәннәр инде, ә атканнар, дип яза Сәлман Гобәйдуллин[3].

Апанаевлар теркәп барган язмалар арасында 1930 нчы елда илнең төньягындагы лагерьларга җибәрелгән кешеләрдән икесе турында кыскача булса да, түбәндәгечә мәгълүмат бар.

«1930 нчы ел 26 нчы фибралда хат килде, Кемь[4] шәһәренә административный җибәрелгән Казаков салган. Мәсҗиднең имамы Гаяз хәзрәт Сәгъдетдин угылы авырып балнисәгә кергән һәм шунда ике көн генә авырып, вафат булган. Бүген ахшамдин соң мәрхүмнең рухы хушнудлыгына һәүл намазы укыдык... Мәрхүм Казанга килгәнче Набережный Чаллыда имам иде, хафизы Кәлямулла иде һәм бик яхшы вагыйзь иде. Казанда имам булган заманында мәсҗидендә һәр атнада сиһшәнбә көннәрдә хатын-кызга вәгазь итәдер иде. Вәгазене тыңларга өч-дүрт йөзләп хатыннар җыела иде».

Монда фамилиясе генә күрсәтелгән Казаков, мөгаен, Мөхәммәтрәхим Мөхәммәтшакир улы Казаков (1873–1937) булгандыр. Туганы Сәлман Гобәйдуллин язганга караганда, Мөхәммәтрәхим Казаков XX гасыр башында Казан шәһәренең эре сәүдәгәрләреннән берсе булган, хаҗга барган. Ул хакимият эзәрлекләвеннән котылу өчен 1920 нче еллар уртасыннан хатыны белән бергә шәһәрдән-шәһәргә күчеп, эш урыннарын

---

[3] Губайдуллин С. Казаковы // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №2. – С. 215–216. Мәкаләнең аерым өлешләре татарчага безнең тарафтан иректә тәрҗемә ителде.

[4] Кемь – Карелиядәге шәһәр.

еш алыштырып йөргән. Һәрвакытта да кулга алынуга хәзер булып, беренчел кирәк-яракларны үзеннән беркайчан да калдырмаган. 1930 нчы елларда Мөхәммәтрәхим Казаков кулга алынган һәм тоткынлыктан кайтмаган[5].

Габдулла Апанаев үзе белән бергә хөкем ителгән Юнысовларны искә алган. Ачыкланган мәгълүматларга караганда, Габделвәли Исхак улы Юнысов (1881 елда туган) һәм Гобәйдулла Мөхәммәтрәхим улы Юнысов (1883 елда туган) икесе дә Бакуда яшәгәннәр, эре эшкуарлар. 1931 елның февралендә ОГПУ Коллегиясе тарафыннан 58 нче маддә буенча (совет хакимлеге белән көрәшү өчен ил чиген яшерен үтүдә гаепләнеп), икесе дә унар елга концлагерьларга хөкем ителгәннәр. Гобәйдулла Юнысов лагерьда – Беломорканал төзелешендә үлгән. Икесе дә 1989 елның 9 октябрендә акланганнар.

Юнысовларның ил чиген үтәргә омтылганда кулга алынуларына караганда, алар белән хөкем ителгән Габдулла Апанаевның да бергә булганлыгы аңлашыла. Бу – С.Гобәйдуллин язганны раслый. Югыйсә, Г.Апанаевның репрессияләнү гаепләренә караган мәгълүматларда чикне кичүенә бәйле сүзләр очратмадык.

Текст хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «903г.(776)» шифры белән саклана торган кулъязманың 11а–11б кәгазьләреннән алынды.

***

1930 нчы ел 18 нче фибралда Мәскәүдә ГПУ мине, Вәли һәм Гобәйдулла Юнысовларны (мине биш елга, ике Юнысовны унар елга) хөкем итте. Мин Баку ГПУсында өч ай, Казан хәбесханәсендә 6 ай, Мәскәү «Бутырка» хәбесханәсендә 3 ай хәбес кыйлынып, 31 нче елда 18 нче фибралда хөкем кыйлынып, Уралда Вишер концлагерена җибәрделәр.

[5] Губайдуллин С. Казаковы... – Б. 212. Мәкаләдә М.Казаковның һәм башка кардәшләренең фоторәсемнәре дә бирелгән.

Анда бер ел да ике ай тотып, Тамбау губернасында Темниковский лагерьга[6] җибәрделәр.

Анда өч ай тотып, вольный высылка биреп, «минус 12»[7] илә үзем Мәләкәс шәһәрене ихтыяр [итеп], 1932 нче ел 20 июльдә Мәләкәскә килдем. 35 нче ел 4 нче апрельдә тәмам котылдым.

1935 нче ел 12 нче майда Мәләкәс шәһәрендин вольный высылкадин Казанга сәламәт кайттым. Бу биш ел мөддәте сәфәремдә, Ходага шөкер, ачлык-ялангачлык һәм рәзаләтләр күрмәдем. Өюдән Зөләйха һәр заман пасилкәләр җибәреп, ярдәм кыйлып торды, Хода аңар әҗерене биргәй иде.

Габдулла Апанаев. 1937 ел (фото интернет челтәрендәге ачык чыганактан алынды)

***

1937 нче ел 30 нчы июльдә Габдулла Йосыф угылы Апанаев хәбескә алынды. Һич кайда икәне мәгълүм түгел. Шул ук җылны октябрьдин 2 нче төрмәдән юк булды.

1938 нче ел 3 нче сентябрьдә бар нәрсәләрне конфисковать итеп алып киттеләр. Аллаһы Тәгалә ахырын хәерле кылса иде.

---

[6] *Темниковский лагерь* – Мордовия АССРның көнбатышында, урман хәзерләү өчен 1931 елда махсус оештырылган, тоткыннарны төзәтү-хезмәт лагере. Мәскәү шәһәрен утын белән тәэмин итү дә шул лагерьга йөкләнгән. 1932 елда анда 18 мең кеше (тоткын) хезмәт куйган.

[7] *«минус 12»* – совет иленең 12 зур шәһәрендә яшәүнең тыелган булуы.

«Таланган малда бәрәкәт юк»

Мөхәммәтсәлах Әгъләҗетдин улы Жданов хәзерге Актаныш районындагы Иске Балтач авылында 1878 елда дөньяга килгән. Туган авылында, Чакмак мәдрәсәсендә һәм Казан шәһәрендәге Апанаев мәдрәсәсендә белем алган. 1905 елда Саусбаш авылында (Яңа Җәнәй; хәзерге Башкортстан Республикасының Кызыл Кама районында) балаларны җәдитчә укытырга керешкән, 1906 елдан алып шул ук авылда имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасына расланган. Алдынгы фикерле, мәгърифәтче, киң мәгълүматлы, тирән белемле шәхес буларак, XX гасыр башында нәшер ителгән татар матбугатында (бигрәк тә, Оренбург шәһәрендә чыккан «Шура» журналында) мәкаләләре һәм шигырьләре басылган. 1909–1917 еллар арасында «Шура»да аның барлыгы 13 публикациясе (шәҗәрә, дин, мәгариф һ.б. мәсьәләләргә караган мәкаләләре һәм шигырьләре) чыккан. Бер мәкаләсе исә 1914–1915 елларда сигез санда дәвам итеп басылган.

1917 елда совет хакимлеге урнашкач та, Мөхәммәтсәлах хәзрәт имамлыгын һәм укытуын дәвам иткән. Әмма «1919–20 уку елында инде безнең бөтен Башкортстанда совет хөкүмәте җирләшеп, безнең мәктәп тә «Эш мәктәбе» булып әверелде. Мин һаман рәсми мөгаллим булып дәвам иттем. Һәм шул елда ук хөкүмәт мәктәпләрендә дин укыту тыелып, мәктәпләрдә, көтепханәләрдә булган бөтен Коръән-кәримнәр һәм дини китаплар җыелып юкка чыгарырга кушылды. Мин исә шул көнгәчә бөтен көчем белән дин дә укытып һәм милләт балаларына дини вә дөньяви белем бирергә тырышып килгән бер имам һәм укытучы булганыма күрә, бу тыюлар миңа бик начар тәэсир итте. Һәм әгәр дин укытмасам, авыл халкым да миңа тагын бик начар карап, күңелсез хәлләр туачагы да бик билгеле иде.

Шуларны уйлап, мин укытучылык эшеннән бөтенләй истигъфа кылырга уйладым», – дип язган.

Мөхәммәтсәлах хәзрәт 1923 нче елдан Бөре кантонының 3 нче нахиясендә мөхтәсиб вазифасына сайланып, 1927 елга хәтле хезмәт иткән һәм 1928 елның ноябренә кадәр Саусбаш авылында имамлыгын башкарган.

1930 елның февралендә мөлкәте конфискацияләнеп, гаиләсе белән йортларыннан чыгарылганнар. Шул ук елның августында мал-мөлкәтләре кире кайтарылган. 1937 елның февраль аенда Мөхәммәтсәлах мулла кулга алынып, дүрт ай дәвамында Уфа, Бөре һәм Николо-Берёзовка төрмәләрендә тотылып, тикшерүләр үткәннән соң азат ителгән.

Беренче хатыны 1907 елда вафат булганнан соң, Мөхәммәтсәлах хәзрәт Яңа Кабан авылының имам һәм ахун Нуретдин Солтаный кызы Мәдинәгә (1885–1937) өйләнгән. Шул хатыны турында язганда хәзрәт чиксез кыен еллардагы халәтен болай тасвирлаган: «...1930 нчы елда өйдән чыгарылганда бергә чыктык. 6 ай кеше өендә яшәдек. Соңра мин төрмәләргә алынган чакларда аңа ул-бу зарар китерелмәде һәм бишьеллык[1] көннәрендә аның кебек башка остазбикәләр рәвешендә авырлык күрмәде. Бүтән хатыннар, галибән, мулла хатыннары аркаларына пиштәр киеп, урыс авылларында чабата сатып, бәрәңге алып кайтып тамак туйдырганда бу мәрхүмә өйдә тыныч ятты... Үзебезнең башларыбызга килгән авырлык сәгатьләрдә һич артык пошынмады. Ике агасы сөргенгә җибәрелгән чорларда, атасы йорттан чыгарылып, авырлык астында калган вакытларда, ата вә анасы үлгән чакларда һәм башка шундай чакларда һичбер ва вәйла кубармады, кычкырып җылаганы беленмәде һәм һичбер вакыт зарла-

[1] *бишьеллык* – СССР халык хуҗалыгын тиз арада үстерүне күздә тоткан 1928–1932 нче еллардагы икътисади план. Ул чордагы төп игътибар авыр промышленностьне үстерүгә юнәлтелгән бишьеллык планнары Советлар Союзын индустрияләштерү өчен кабул ителгән. Әмма монда М.Жданов бишьеллык гыйбарәсен аның рәсми мәгънәсендә түгел, муллалар һәм гомумән кулак дип танылган сыйнфый дошманлыкның котырган заманы буларак телгә алган.

ныр йөрмәде. Шундай сәгатьләрдә күп вакыт: «Әйдә, Ходай язмаган эш булмас!» – дип, язмышка ризалык күрсәтер, зарланмай түзәр иде».

Аның үз нәселе шәҗәрәсе һәм Җәнәй нәселе тарихын өйрәнүгә багышланган материаллары, шул исәптән, кыскача тормыш юлы безнең тарафтан хәзерләнгән «Шәҗәрәләр» китабында басылган иде[2].

Мөхәммәтсәлах Ждановның утызынчы еллар мәхшәре турында бу китапта тәкъдим ителгән тексты аның 1940 нчы елларда гарәп хәрефләре белән теркәгән үз кульязмаларыннан («Саусбаш авылы» тарихын тасвирлаган дәфтәреннән) күчереп алынган иде. Ул кульязмалар белән Ижевск шәһәрендә 2000 нче еллар башында таныштык.

***

...НЭП чорында һәм аннан соң авылымызда ике өйле һәм такта капкалы кемсәләр 20-ләп булган иде. Кунак чанасы, тарантас, җилгәрү машиналары 50-ләпкә якын иде. Җиде сугу машинасы, бер суырткыч, өч җил тегермәне бар иде. Кулак белән көрәш чорында инде болар юкка чыгарылды. Юлбашчылык итүчеләр авылымызда шул законны иң каты ягы белән генә түгел, бәлки арттырып гамәлгә кую аркасында, байлар – кулак булырга яраклык кемсәләр генә түгел, урта тормыштан түбәнрәкләр кулак ителеп, мөлкәтләре мөсадәрә ителде, үзләре хәбескә ябылды, сөргенгә җибәрелде. Хәлбуки, күрше авылларда шундайлар исән калды. Нәтиҗәдә, халык ярлылыкны, ярлы булуны теләй һәм шуңа омтыла башлап, өйне, атны, сыерны бирәргә калдыру, аларны бирсен әле үсеп тә җитмәгән угылына биреп, башка чыгару, гаиләләрне ваклау, көчне тарату китте. Кыскасы, халык үзе теләп ярлылана башлады һәм ярлыланды!..

Колхозлашу башлангач, әллә бу хәл төзәлерме дип уйланса да, ул да файда бирмәде. Чөнки алда күреләчәк үзрә, бердән,

[2] Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 99–124.

халык колхозны аңлап, аңа ихлас куеп кермәде. Икенчедән, колхозны идарә итүчеләр күбесенчә идарә көченнән мәхрүм, колхозның файдасы кайдалыгын үзе дә төшенмәгән, шәхси мәнфәгать артыннан йөрү белә мөбтәля кемсәләр булганлыктан, колхоз авылның икътисади хәлен күтәрә алмады. Алмады гына түгел, түбәнәйтте. Олуг сугыш башланып китү нәтиҗәсендә исә колхоз яхуд авылның икътисади җәһәте эштән чыкты дисәк тә ярарлык булды.

...1930 нчы елда гомуми колхозлашу заманында мәсҗид дин әһеле, дини җәмгыять кулыннан дөньяви җәмгыять кулына алынып, клубмы, ышкулмы итәргә хәзерләнелде. Ләкин шул ел яз көне колхоз таралган-таратылган заманында мәсҗид кире дин әһеле кулына кайтарылды.

1937 нче елда, аны да иртәгә Корбан бәйрәме дигән төндә, дәхи дин әһеле кулыннан алырга карар ясалып, иртәгесен Корбан гаете укырга рөхсәт ителмәде, имамлык итүче Мөхәмммәтмөнәүвәр Хәсән угылы тәүкыйф ителеп алып кителде. Шул көннән бирле мәсҗиде шәриф клуб булып хезмәт иттерелә. Манарасы исә төшерелмәде.

Шул ук 1930 нчы елның февраль аенда мөәзин Зәкиҗан ага илә минем мөлкәтем мөсадәрә кылынып, үземез йорттан чыгарылдык. Мине Маһикамал Шәһидулла кызының ихатасыз һәм хаҗәт үтәргә һичбер урыны булмаган, мунча кебек төтен тула торган өенә чыгарып, аны минем өйгә керттеләр. Мөәзин аганы исә Харис Хәйдәр угылының 4–5 аршинлы өенә чыгарып, Харисны аның өенә керттеләр.

Алты ай тулган вакытта, августның 25 нче көнендә йортка кертелүгә тиеш табылып, һәр икәвебез өйләребезгә кертелеп, алынган мөлкәтебез кире кайтарылды.

Шуралар хөкүмәтенең кануннары буенча, безнең элекке хәлебезгә, тормышыбызга караганда, мөәзин илә мин өйдән чыгарылмаска, бәлки Мирсәед мулла чыгарылырга һәм кертелмәскә тиеш иде. Ләкин шул көннәрдә авылымызда укытучы булып торган Тимкин Мөнир дигән шәхес Мирсәедтә фатирда торып, Мирсәед һәм хатыны Хөршидә бәгъзебер вакытларда

безгә булган ачуларын кайтару, үч алу өчен мәзкүр Тимкинны котырттылар. Ниһаять, безне чыгартуга муаффәкъ булдылар.

Ләкин безне Тимкин чыгартса да, Аллаһ хәзрәте чыгартмаган икән. Шунлыктан, хөкүмәт кәмисиясе безне кире кертеп, мөлкәтемезне кайтарды. Әмма Мирсәед һәм хатынын Аллаһ хәзрәте чыгарды, ә һичкем кертмәде. Шөйлә ки, әлгаязе билләһи, Мирсәед чирләгәч, хатыны ташлап Пермь әтрафына китеп, шуннан кайтмады. Мирсәед исә рәнҗү хәлендә тәрбиячесез калып, үз өендә торырга рәт калмады. Әле теге, әле бу кемсәдә торып, тамак туйдыру өчен соранырга мәҗбүр булып, адәмнәр аннан җирәнеп, ниһаять, беренең өендә вафат булып (тәхминән 31–32 елларда), кемнәрдер илтеп күмделәр.

Без исә, әлхәмде Лилләһи, үз йортымызда гаиләмез илә берлектә, иң ләззәтле булган бакчамыз, китапларымыз арасында яшәймез. Аллаһы Тәгалә хәзрәте гаять вәрта вә мөһликәләрнең һәрбереннән сәламәт алып калды һәм әле дә сәламәт алып барадыр. Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин, әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин, сүммә әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин!

Төрле хәлләрнең теләве буенча, мин дә, мөәзин ага да урыннарыбызны куеп (30 нчы елда) гәзитәләрдә игълан кылдык. Мин мөхтәсиблекне исә 1929 нчы елда куйган идем. Мәншүрсез хәлемдә, үз йортымда гаиләм илә берлектә, китапларым арасында авылның бер карты булып яшәймен.

30 нчы елда мәсҗид кире бирелгәч халык Мөхәмммәтмөнәүвәр Хәсән угылын сайлап, имам вә мөәзин итеп куйган иделәр. 37 нче елда ул тәүкыйф ителеп алып кителгәч, хәбәрсез югалды.

***

...Ниһаять, халыкны колхозлаштыруга, кулак белә көрәшү эшенә җитди керешелгәч, гомуми һәм көчле рәвештә колхозга өндәү башлана. Ләкин халыкның күпчелеге гаять зур шөбһә белә карай, язылмай. Язылганнар да ныклы кыстау соңында яки курку сәбәпле языла.

Шул ук вакытта (1929 нчы ел) кулак белә көрәш башланып,

авылымыздан алты кемсә: Гәрәйхан һәм Морзахан Ыждани-лар, Мөхәммәтгали Төхфәтулла угылы, Хөснетдин Фәхретдин угылы, Мирзаһид Гыйльмулла угылы һәм Мөхәммәдсәлах мулла Әгъләҗетдин угылы кулга алынып, шул вакыттагы вулыс Яңа Кабанга җибәрелделәр. Аларгача 81 кемсә ябылган иде, болар белән 86 кемсә булды.

Авылымыз ярлылары, кызыл партизаннарның химаясе аркасында мине – Мөхәммәтсәлахны – ошбу мәхбүсләрне җыеп, ябып ятучы ГПУ вәкиле коткарып, калган биш кемсә мәзкүр 80 кемсә белә сөргенгә озатылдылар. (Гәрәйхан Архангел якларында Биржа Каргавина дигән җирдә, Хөснетдин Кузбасста үлеп, башкалары сөрген елларын тутырып кайтып үлделәр).

1930 елда мәзкүр кемсәләрнең мөлкәтләре мөсадәрә ителде һәм мөәзин Зәкиҗан ага да, мөлкәте мөсадәрә ителеп, йортыннан чыгарылды. Аның белән мине, сәбәпләргә-законга караганда һәм халык вә кызыл партизаннарның теләмәүләренә караганда, раскулачивать итү тиеш булмаса да, мулла Мирсәед һәм хатынының, укытучы Мөнир Тимкин аркылы чыгартуга иҗтиһад итүләре аркасында, чыгарылуга дучар булдык.

Ул елның башы белән һәр урында гомуми колхозлаштыру дәвам итә, хәтта колхозлар колхозы оештырыла[3] иде. Һәр урында мәсҗидләр ябыла, кулаклар белән бергә мулла-мөәзиннәр дә ябыла, мөлкәтләре мөсадәрә кылына иде. Кулакларның гаиләләре көтү-көтү сөргенгә читкә озатыла иде.

Хәтеремдә хата калган булмаса, безнең Яңа Кабан вулысыннан шундай кулак гаиләләре барлыгы 80 ат йөге кемсә озатылып, безнең авылдан җибәрелгәннәрнең байтагы шәрә диярлек, киемсез булып, Яңавыл ыстансасыннан кире кайтарылганнар. Озатылучылар эчендә Яңа Кабан авылының 80 яшьлек карт, чирле имамы ахунд Нуретдин хәзрәт Солтанов[4] та булып, ГПУ вәкиле буны коткарган, җибәрмәгән. (Мәзкүр

---

[3] *колхозлар колхозы оештырыла* – күрше-тирә авыллардагы берничә колхозны берләштереп эреләтү һәм бер үзәккә буйсындыру күздә тотылган.

[4] *Нуретдин хәзрәт Солтанов* – язма авторы Мөхәммәтсәлах Ждановның биатасы.

хәзрәтне кызганып җыелган халык арасында кайберәүләр җылай башлагач, вулыс башлыгы – безнең авылның һәм минем шәкертем Шәйхелгыйлем Нуркәев: «Җыламагыз! Җылаучыларны хәзер яптырам!» – дип, куркытып туктаткан.

Бер-ике елдан соң Нуркәев үзе начар хәлгә төшеп кулга алынды. Шул вакыт Кабан авылыннан берәү: «Нуркәевне кызганам, хәтта җылар идем, ләкин җылаганга ябалар, шуннан куркып кына җыламаем», – дип, Нуркәевкә үзенең сүзен искәрткән.

Менә ошбу көннәрдә инде авылымызда мәзкүр партизаннар башлык итәләр. Фәрдетдин беркадәр йомшаклык итсә дә, Минһаҗетдин бөтен катылыгы белән алып бара иде. Авылга колхозга өндәү көчле һәм акрын-акрын керү дә дәвам итә иде.

30 нчы ел яз көне хөкүмәт «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкалә нәшер итеп, гомуми колхозлашуны туктатты, колхозга көчләп өндәү тукталды һәм һәр урында колхоз таралу башланып, бездә һәм таралды. Мәсҗид кире кайтарылды, авылга имам вә мөәзин итеп Мөхәммәтмөнәүвәр Хәсән угылы сайланды.

Ошбу 30 нчы ел җәендә яхуд 31 ел[5] җәендә авылымыздан дүрт яшь гаилә (махсус күчерелүчеләр) «спецпереселенец» исеме белән Анжиргә[6] җибәрелделәр. Икәвесе Морзахан Ыждани угыллары Илдархан һәм Сәлимҗан Ыждановлар, 3 нче – Шәйхелимам Муса угылы (бу өчәү Кызыл Әрмиядә хезмәт итеп кайткан кемсәләр), 4 нче – Мирзашәех Мирзаһид угылы. Болар һәрбере күптән түгел аталарыннан башка чыгып, күп тырышлык белән тормышларын рәтләп килүче гаиләләр иде. Болар хатын вә балалары белә китеп, китүләре чебешләре белән берлектә төйләгән тарафыннан алып кителгән тавыкка охшады – искәрмәгәндә, бер ара озатылдылар.

Болардан соң да җибәрелү дәвам итеп, Заһретдин һәм Насретдин Фәтхетдин угыллары, Әхмәтвәли Мөхәммәтнәгыйм угылы, Мөхәммәтхан Әхмәтхан угылы, Әмирхан һәм Шәрифҗан Гәрәйхан угыллары җибәрелеп, мөлкәтләре мөсадәрә

---

[5] Дөресе 1931 елда.

[6] *Анжир* – хәзерге Кемерово өлкәсендәге Анжеро-Судженск шәһәре.

ителде. Җибәрелүгә багышланган Муса Гайнетдин һәм Фәрхетдин Гайса угыллары үзләре качып котылдылар исә дә, мөлкәтләре мөсадәрә ителеп, йортлары сатылды. Һәм Габдеррәфыйг Шаһиәхмәт угылы үзе җибәрелеп, мөлкәте мөсадәрә ителде. Пермяк авылыннан килеп, күп еллардан бирле сату итеп баеган Анна Михайлә кызы үзе качып өлгерде, мөлкәте мөсадәрә кылынды. Болар һәрбере беренче бишьеллык дәверендә булып, 37 елда – троцкийчылар[7] белән көрәш заманында, Мөхәммәтмөнәүвәр Хәсән угылы җибәрелеп, мөлкәте мөсадәрә ителде. Шулай ук элекке җибәрелүдән җылын тутырып кайтып, тормыш башлаган Заһретдин Фәтхетдин угылы дәхи эләгеп җибәрелде (ошбу китүдә 5 нче ел тулганда Уфада Киркинстройда вафат булды).

Шулай итеп, авылымыздан 23 кемсәнең мөлкәте мөсадәрә кылынып, икәүсенең кире кайтарылды. Калган 21-дән 17 кемсә сөргенгә җибәрелде, 4 кемсә үзләре качып өлгерделәр. Шулардан 4 кемсә кайтып, авылда вафат булды, өч – читтә сөргендә вафат булды, берәү (Мөхәммәтмөнәүвәр) гаиб-хәбәрсез, 3 кемсә кайтып, авылда яшәйләр, дүрт гаилә Анжиркәдә, дүрт гаилә төрле урында читтә яшәйләр. Шулардан биш кемсәнең йортлары читкә сатылды, беренең йорты колхоз идарәсе булып яши, беренеке ышкул ителде, калганнарының авыл кемсәләренә сатып бетерелде.

Шундай куркыныч хәлләр булып торса да, кысулар төрле рәвештә һәм көчле дәвам итсә дә, халыкның колхозга керүе акрын, менә дигән колхозга керердәй кемсәләр кермәй, урта тормышлылар гына түгел, фәкыйрьләр карышалар иде. Карышуның (авыр керүнең) сәбәбе минемчә түбәндәгеләр иде.

---

[7] *троцкийчылар* – сәяси һәм дәүләт эшлеклесе Лев Давидович Троцкий (Бронштейн, 1879–1940) исеме белән бәйле, марксизм-ленинизмга һәм халыкара коммунистик хәрәкәткә каршы агымда гаепләнүчеләр. «Троцкийчылар» дигән атамага Л.Троцкийның якын туганнарыннан алып, аны бөтенләй белмәгән һәм аңа бернинди мөнәсәбәте булмаган кешеләр дә кергән, алар совет властена каршы хәрәкәттә, шпионлыкта, корткычлыкта һәм террористик эшчәнлектә гаепләнгәннәр.

1. Колхозга өндәү аңлату, файдасын төшендерү юлы белән башланмай, куркыту, кыстау юлы белән башланды.

2. Колхоз күбрәк таланып, мөсадәрә кылынып алынган малларга нигезләнде. Шунлыктан, халык бондан гаять нәфрәтләнде, ничек тә кермәскә карар кылды. (Кул көче белән торучы балта остасы Мөхәммәдьяр угылы Ислам: «Колхоз ул әбрәкәй! Менә шуңа илтеп малны салалар да, «алып файдалан», диләр. Моны ничек җирәнмәй алырга – колхозга керергә кирәк?!» – дия иде).

3. Дин бетерелү, дин әһеле ябылып, мәсҗидләр клуб һәм башка ителү. Бу мөнәсәбәт белән җылаучылар күп иде.

4. Колхоз юлбашчыларының күпчелеге фәкать үз файдаларын күзәтеп, халык малыннан тиешсез, законсыз юл белән файдаланулары. Бу хакта бер сүз әйтүчене «контр, вредитель» кебек сүзләр белән куркытулары, хәтта ябып һәм сөргенгә җибәрүләре. Һәм шул юлбашчыларның күбрәк эчү, сыйлану, хатын-кыз белә шаяруга бирелүләре һәм башка шундайлар халыкны колхоздан нәфрәтләндерә иде.

Шушы ук хәлләр колхоз эчендә яшәүчеләрнең колхозга ихлас куймауларына, колхозны үз итмәүләренә, колхоз эшен сөепяратып түгел, көчләнеп, авырлык белән начар эшләүләренә сәбәп иде. Колхозчыларның болай начар карап, эшне начар, акрын, аз эшләүләре колхоз хуҗалыгының көннән-көн артка калуына сәбәп булуы белән бергә, колхозчылар артка калуны югарыдагы сәбәпләрдән күрәләр; «Менә таланган малда бәрәкәт юк. Колхозның таланып алынган 120 башлап умартасыннан хәзер 12 баш кына калды, йөзләрчә аттан барлык 15 баш калды» һ.б. дия сүләнәләр!

Авылның кулак ителмеш кемсәләре

Болар үткәндә язылды исәләр дә, бонда аерым рәвештә язуны дәхи тиеш таптым.

1. Гәрәйхан Әхмәтхан угылы Ыжданов. Тормышы иркен, 10 баштан артыграк ат асрап, сыеры юк, малы күп, суырткычы

бар, 100 баштан артык умартасы бар, игенне күп чәчә. Гаять тырыш, тормыш дигәндә ял һәм йокыны белмәй иде.

1929 нчы ел кулга алынып, Төньяк Двина суы буенда Бирджа Каргавина дигән җирдә үлеп калды. Бөтен мөлкәте алынып, колхозга бирелде.

2. Морзахан Әхмәтхан угылы Ыжданов. Түбән тормыштан күп тырышу аркасында баеган иде. Ике өй, ике амбар, ике ат, ярты җил тегермәне[8], бераз гына умартасы бар иде. Инкыйлабкача күп ел ыстароста булып торды. Җыелышларда күп сүләүче иде.

29 нчы ел кулга алынып, 3 яки 5 елдан соң кайтып, кечкенә өй салып тереклек итеп, авылда вафат булды[9].

3. Мөхәммәтгазиз Төхфәтулла угылы. Күп тырышлык аркасында баеп, ике өй, ике амбар салып, ат-сыеры өчәр баш иде. Соңгы елларда сату да итте.

29 елда җибәрелеп, 3 ел соңында кайтып, угылларында атналап туенып[10] йөреп, авылда вафат булды[11].

4. Хөснетдин Фәхретдин угылы. Фәкыйрьлек белән тормыш башлап, күп тырышлык һәм мал белән сату итү аркасында бераз иркенләп киткән иде.

29 ел кулга алынып, шуннан кайта алмады, Кузбасста вафат диделәр.

5. Мирзаһид Гыйльмулла угылы. Фәкыйрь тормыштан күтәрелде, мал белә сату итеп файда күрер иде.

29-да кулга алынып, Архангелдан качып кайтып, дәхи җибәрелеп, ниһаять, авылда вафат булды.

---

[8] *ярты җил тегермәне* – ике хуҗаның уртак тегермәне булып, шуның ярты өлешенә ия булу күздә тотылган.

[9] Электрон мәгълүмат чыганакларында Жданов Морзаханның (1870 елда туган) 1929 елда 22 октябрьдә кулга алынып, 58 нче маддә буенча гаепләнгәнлеге, 3 елга сөргенгә җибәрелгәне һәм 1989 елда акланган булуы турында язылган.

[10] *атналап туенып* – ягъни, бер атнада бер улында, икенче атнада башкасында тукланып.

[11] Мөхәммәтгазиз Төхфәтуллин 1929 елның 23 декабрендә кулга алынып, 58 нче маддә буенча хөкем ителгән булуы турында мәгълүматлар бар.

6. Мөхәммәтхан Әхмәтхан угылы. Фәкыйрьлектән баеп, яхшы йортлар салган иде. Ярты җил тегермәне бар иде.

31 елда булса кирәк, кулга алынып, 3 яки 5 елдан кайтып, авылда вафат булды.

7. Заһретдин Фәтхетдин угылы. Атадан ятим калып, фәкыйрь хәлдән күтәрелеп, 2 йорт салган, ике ат тота иде. Өч ага-энегә бер сугу машиналары булып, шуның белән көн-төн эшләп, байлык арттыралар иде.

Мөхәммәтхан белән бергә кулга алынып, шәрыкътә Бухта Нагаевада[12] җылын тутырып кайтып тормыш башлагач, троцкийчылар алыну заманында дәхи кулга алынып, Уфада Киркинстройда вафат булды.

8. Насретдин Фәтхетдин угылы. Бу һәм туганы Заһретдин кебек ятимлек, фәкыйрьлек эченнән чыгып, күп тырышу һәм сугу машинасы аркасында тормышы аруланган иде.

Заһретдин белән бергә кулга алынып, җылын тутырып кайтып вафат булды.

9. Әхмәтвәли Мөхәммәтнәгыйм угылы. Бу кемсә балык тоту белән шөгыльләнеп, тырышлык һәм саранлыгы аркасында тормышы аруланган иде.

Заһретдиннәр белән бергә кулга алынып, җылын тутырып кайтып, хәзер авылда балыкчы булып яши.

10. Әмирхан Гәрәйхан угылы. Атасы бер өй салып биргән һәм үзе дәхи тырышып берне салган, ике ат җигә, улы-кызы җиткән иде.

Заһретдиннәр белән кулга алынып, Мәскәү каналында эшләп, җылын тутырып кайтып, хәзер Пермь әтрафында яши.

11. Шәрифҗан Гәрәйхан угылы. Атасы сөргенгә җибәрелгән соңында мөлкәт аның кулында калган иде. Ул мөсадәрә кылынып, үзе Коми АССРга сөргенгә җибәрелде. Җылын тутырып кайтып, хәзер Иж[13] ягында яшәй диләр.

[12] *Бухта Нагаева* – СССРның төньяк-көнчыгыш читендә 1929 елда төзелгән бистә (исеме соңрак Магадан дип үзгәртелгән). Андагы «Дальстрой» карамагында 1932–1953 елларда 900 меңгә якын тоткын булган, шулардан 121 меңнән артыгы үлгән.

[13] *Иж* – Ижевск шәһәре.

12. Габдеррәфыйг Шаһиәхмәт угылы. Тормышы уртача, бала-чагасы юк, кара тормышлы бер кемсә иде.

Мөхәммәтхан, Заһретдиннәр белән кулга алынып, котылып кайткач, хәзер урыс арасында яшәй.

13. Мөнәүвәр Хәсән угылы. Тормышы уртача, күп тырышлык белән генә бара, 30 елда авылга имам вә мөәзин булып сайланып, шул хәлдә дәвам итә иде.

37 ел кулга алынып, хәбәрсез югалды.

14, 15, 16. Муса, Гайнетдин, Фәрхетдин Гайса угыллары. Тормышлары уртача, тегермәннәре бар, тырышлык белән баралар. Соңгы икәвесе кешедән көлү белән мөбтәля иде, диләр.

Өчәвесе дә кулга алынганчы качып котылып, мөлкәтләре мөсадәрә кылынды.

Муса ага соңыннан кайткач, өен юллап алды.

Гайнетдин Бумстройда[14] карарланды.

Фәрхетдин Пермьдә кулга алынып, җылын тутырып кайткач шунда яшәделәр. Хатыны Шәмсекәй Пермьдә поез юлына кысылып вафат булган, балалары Пермьдә.

17, 18, 19, 20. Илдархан, Сәлимҗан Морзахан угыллары Ыждановлар; Шәйхелимам Муса угылы[15], Мирзашәех Мирзаһид угылы.

Дүрт гаилә берлектә 30 нчы елның җәендә (яки 31 елда), һич искәрмәгәндә, Себер ягына – Анжиргә җибәрелеп, хәзер дә шунда шахта эшчесе булып яшәйләр.

[14] Бумстрой – монда, күрәсең, Пермь өлкәсендә 1929 елда кәгазь җитештерү комбинаты төзелә башлаган һәм Бумстрой дип аталган бистә күздә тотылгандыр. 1931 елның башында анда Татарстаннан кулак дип сөрелгән ике мең крестьян китерелгән, алар уннан артык баракта урнаштырылган. Алардан соң яңадан-яңа тоткыннар өстәлеп торган. Бумстройның исеме 1933 елдан Краснокамск дип үзгәртелгән һәм 1938 елдан шәһәр статусы алган.

[15] Электрон чыганаклар мәгълүматына караганда, Имам Мусин (1899 елда туган) 1931 елда кулак буларак хөкемгә тартылган һәм Анжеро-Судженскига сөрелгән. 1947 елның май аенда исәптән төшерелгән. И.Мусин һәм аның белән бергә сөрелгән иптәшләренең авылдан җибәрелгән елын М.Жданов «1930 яки 1931 елда» рәвешендә язган. Электрон мәгълүматка караганда, ул вакыйга 1931 елда булган.

Лагерьда моңаеп-сагынып җырлаган җыруларым

Фәттахетдин Камалетдин улы Заитов (1883–1972) хәзерге Әгерҗе районындагы Кыдырлы авылында туган һәм яшәгән, төбәкнең күренекле сәүдәгәрләре һәм муллалары нәселеннән. Фамилияләре Заһит (1759–1836) исемле мулла бабаларыннан килгән. Илдә совет хакимлеге урнашкач, бу нәселнең кайбер вәкилләре Урта Азиягә күчеп китәргә мәҗбүр булган, калганнарын кулак итеп Магнитогорскига сөргәннәр яки йортлары-мөлкәтләреннән мәхрүм итеп, лагерьларга озатканнар.



Фәттахетдин Заитов. 1960 нчы еллар

1917 елга кадәр сәүдә белән шөгыльләнгән һәм шактый яхшы тормыш иткән Фәттахетдин Заитов гаиләсенең бөтен йорт-җирләре, мал-мөлкәтләре 1930 елның гыйнвар аенда конфискацияләнгән, үзләре фәкыйрь бер хатынның кечкенә генә өендә җан асрарга мәҗбүр булганнар.

Ул вакытта Фәттахетдин Заитовның хуҗалыгы-мөлкәте 30500 сумлык дип бәяләнгән. Аның йорты гына да 30 мең сумлык булган, ике амбары – 140 сум, өч кәнүшние – 150 сум, сыеры – 70 сум һ.б. Чагыштыру өчен: шул ук вакытта авылдагы

башка кулак хуҗалыкларының гомуми мөлкәтләре 3 мең, 1700 һәм 1340 сумга бәяләнгән.

1930 елның көзендә Ф.Заитов кулга алынып, Казан төрмәсенә җибәрелгән.

Кыдырлы авыл советының кулак Фәттах Заитов турында тикшерү эшенә беркетелгән, 1930 елның ноябрь аендагы белешмәсендә түбәндәгечә язылган.

«Революциягә кадәр булган хәле.

Заитов Фәттах электән зур сатучы баласы булып, сату итте. Аталары белән бергә торган вакыттагы йортлары ике катлы, кара-каршы йорт иде. Бер таш кладовой һәм ике амбар һәм бөтен нәрсәләр – тулысынча бар иде. Атлары дүрттән дә ким булмады, сыерлары да шулай ук өчтән ким булмады. Боларның кәсепләре эре сату белән булып, базардан-базарга йөреп һәм авылда да кибетләре бар иде. Хезмәткәрләр икедән дә ким булмады. Хезмәткәрләренә хезмәт хакларын тулы итеп бирмәде. Һәм бу сату гына аларны тәэмин итмәй, үзләренә тигән җирләреннән тыш, Кыдырлы авылының ярлы хуҗалыкларның җирләрен арендага алып, шул хуҗаларына өчәр хак белән эшләтте. Һәм аннан башка чыгып, йорт алды. Йортының зурлыгы: буе 35 аршин, иңе 12 аршин таш йорт, асты буйдан-буйга подвал, өч амбар, кәнүшниләр. Аты өчтән дә ким булмады, сыерлары да шулай ук булды. Кәсебе шул искечә – сатучы булып, сатуга гына разый булмай, Кыдырлы авыл гражданнарыннан, бигрәк тә фәкыйрь хуҗалыклардан җирләрен арендага, сатып алып, ул җирләрне үзе эшләми, фәкыйрь хуҗалыкларга ярымярты хак биреп эшләтте...

Революциядән соң булган хәле.

1928 нче елларда өч иске кибәне бар иде. Шул иске кибәннәре була торып, аңар канәгатьләнмәй, үзенең кибетендә булган резиновый калошларны акчага сатмай, Вотобластьтән килгән арларга икмәк белән алышып ятты... Үзенең кибете алдына халыкны җыеп: «Икмәкне хөкүмәткә бирмәгез, бәясе очыз. Частный кыйбат ала», – дип, үзенең малларын күрсәтеп, чут белән чутка салып күрсәтә иде, халыкка агита-

ция таратып ятты. Үзе шул вакытта галантерея малы белән сату итә иде.

Коллективизация вакытында безнең күз алдыбызда каршылыклары күренмәсә дә, астан эшләүләре булыр. Без бу турыда материал бирә алмайбыз. Кулак бит ул. 1929 нчы ел өчен трактор задаткасы турында: 50 сум салынган (арест наложить итеп йортлары, йорт җиһазлары алыну сәбәпле) трактор задаткасы аз салынды. Шул салынган 50 сумны түләүдән баш тартты һәм сатарга нәрсәләре булмады. Икмәк хәзерләүдә һәрвакыт каршы килде. Шул салынган икмәген, ягъни 29 нчы елда салынган икмәген түләмәгән өчен штраф салынып, нәрсәләре сатылды».

Заитов Фәттахетдин 1930 елның 1 декабрендә хөкем ителеп, Беломорканал төзелешенә озатылган. 1933 елның язында азат ителгән һәм гаиләсе янына кайткан.

Рәсми мәгълүматлар буенча, Фәттах Заитов 1930 елның 12 октябрендә кулга алынган, 58 нче маддә буенча (совет власте чараларына каршы агитация алып барган өчен) гаепләнеп, шул ук 1930 елның 1 декабрендә 3 елга концлагерьга хөкем ителгән – 1989 елның августында акланган.

Фәттахетдин Заитовның Казан шәһәрендә яшәүче оныгы Шамил әфәнде Заитов 1999 елда бабасының гарәп язулы дәфтәрен күрсәткән иде. Ул дәфтәр «1931, 1932, 1933 нче елларда лагерьда йөргән вакытымда моңаеп-зарланып җырлап йөргән җыруларымны язып куйган дәфтәрем» дип исемләнгән һәм андагы текст башына «Монда шуны яздым: мине кулга алып, лагерьга җибәргәчтен, яхшы тормыштан инде алама тормышка калгач, лагерьда йөргән вакытымда моңаеп-сагынып җырлаган җыруларым» диелгән.

Түбәндәге язмалар шул дәфтәрдән күчереп алынды[1].

Фәттахетдин Заитов язмасында үзе белән бергә өч елга

[1] Шамил Заитовка без күчереп биргән әлеге текст бераз кыскартылып, төбәк тарихына багышланган китапта басылды: Әгерҗе төбәге: тарихи сәхифәләр = Агрызский край: исторические страницы. – Казан: «Сүз» нәшр., 2008. – Б. 203–204.

хөкем ителүчеләр арасында исемнәре күрсәтелгән кешеләр турында да мәгълүмат биреп үтик. Заитовның авылдашы Нигъмәтулла Камалетдин улы Гайсин (1884 елда туган), кулак буларак, 1930 елның 12 октябрендә кулга алынган. Шул ук елның 1 декабрендә 58 нче маддә буенча хөкем ителеп, өч елга Коми Республикасына концлагерьга җибәрелгән. Хатынының үтенече буенча (1931 елның маенда булса кирәк) Чиләбе өлкәсенә (мөгаен, Магнитогорск шәһәренә) күчерелгән. 1994 елда акланган.

Сүз уңаеннан искәртик, Нигъмәтулланың бертуган энесе Сабирҗан Гайсин да (1887 елда туган), 1932 елның февралендә кулга алынып, май аенда 58 нче маддә буенча 5 елга концлагерьга хөкем ителгән. 1989 елда акланган.

Текстта «Тәбәрленең бер яшь малай» телгә алынган. Бу очракта Кыдырлы авылыннан ерак булмаган (Әгерҗе районындагы) Тәбәрле авылының Хаҗи Нуриәхмәтов күздә тотылган. Аның да кулга алынуы Заитов язмасында әйтелгән вакытка тәңгәл килә, хөкем ителгән «гаепләр»е дә бер төрле үк. 1883 елда туган Фәттахетдин бай өчен Хаҗи чынлап та, «яшь малай» кебек тоелган.

Хаҗи Нуриәхмәтов. Ленинград. 1930 нчы еллар

Хаҗи Нуриәхмәт улы Нуриәхмәтов (1905 елда туган) кулак буларак һәм совет хөкүмәтенә буйсынмаган өчен 1928 елда мөлкәтеннән һәм хокукларыннан мәхрүм ителгән. 1930 елда 58 нче маддә буенча (советка каршы котырткан өчен) 3 елга концлагерьга хөкем ителгән. 1989 елда акланган.

Нуриәхмәтов фамилиясенең төрки-татар археографиясенә турыдан-туры мөнәсәбәте бул-

ганлыктан, тагын бер фактны искә алып китәргә тиешбез. Тоткынлыктан азат ителгәч Хаҗи Нуриәхмәтов, ничектер җаен табып, Ленинград шәһәрендә төпләнгән. Аның Тәбәрле авылында 1930 елда дөньяга килгән улы Әнвәр Нуриәхмәтов 1951 елда Ленинград дәүләт университетының Шәрык факультетына (төрки телләр филологиясе кафедрасына) укырга кергән һәм 1956 елда тәмамлап, «шәрыкчы-филолог» белгечлеген алган. 1957 елдан СССР Фәннәр Академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлегендә Төрки-монгол кабинетында кече фәнни хезмәткәр буларак, төрки телләрдәге кульъязмаларны тасвирлау һәм каталоглаштыру төркемендә эшләгән. Төрки-татар кульъязма истәлекләренең тасвирлама хезмәтләре авторлары арасында Ә.Х.Нуриәхмәтовның да исеме бар. Аның басылмаган фәнни хезмәтләре булуы да мәгълүм.

***

1930 елның 1 гыйнварда элек сату иткән, яхшы тормышлы бәндәләрне барын да раскулачивать итеп, йортларыннан чыгарып, фәкыйрьләрнең йортына керттеләр барын да. Без үзебез дә шул ударга эләктек. Йортыбыздан чыгып, бер тол хатын йортына кереп, 9 ай торгач, менә тагы да шунысы авыр булды: раскулачивать иткән бар сәүдәгәрләрне кулга алдылар.

1930 елның сентябренең ахырында, көз көне безнең барыбызны да Казанга җибәрделәр. Казанга барып җиткәч барыбызны да 1 нче камерага, төрмәгә яптылар. Без өч ай чамасы төрмәдә тоткын булып яткан вакытыбызда барыбызның да эшләрен, безне тикшереп карап, кайсыбызга күпме вакыт эшләргә – срок язганнар. Менә шул язылган срокка безнең барыбызны да лагерьга эшкә җибәрделәр, кемгә күпме срок эшләргә аңлатып. Безнең өчебезгә өч елга: миңа, бәгъдендә Гайсин Нигъмәтуллага, Тәбәрле бер яшь малайга, калган иптәшләргә төрлечә срокка, кайсына 5-әр ел, кайсына 10-ар елга хөкем иткәннәр. Менә шушыларның барысын да Балтыйк диңгезе белән Ак диңгез арасына, канал ясалган җиргә канал казырга эшкә – лагерьга җибәрделәр.

Без үзебез дә шул канал казыган җиргә бардык. Баргач мине чәй кайнатып торырга диеп, кипятокка куйдылар. Шул кипяток эшендә 2 ел 7 ай эшләгәч, эшләгән эшемне яхшы дип тапкач, миңа 5 ай льгота бирделәр дә, минем 3 ел срогым тәмам булды. Миңа өйгә бөтенләй кайтырга яхшы итеп язып, кулыма язу бирделәр. Бәгъдендә яхшы эшләгән өчен бүләк итеп яңа киемнәрдән куфайка, чалбар, кәстүм, ыштан, күлмәк, бәгъдендә юлда ашап-эчеп кайтырга полный акча да биреп җибәрделәр.

Аллага шөкер, шул тоткынлык эшеннән котылып, 1933 елның 19 майда, җомга көн җәмәгатем белән кадерле газиз балаларым янына кайтып та кердем. Әлхәмделилла, Ходамның рәхиме булгач, исән, таза-сау, сәламәт йөреп кайтканыма зур куанычлар белән шатланып, шөкерана кыламын. Бүгенгедән түбән, калдык гомерләребездә, барчабыз да бергәләп, тынычлык, тазалык белән куанып яшәргә насыйп булсын, амин.

Вә бәгъдендә монда менә нәрсә яздым. Күрәселәребез шулай булгач, һич гөнаһсыз тоткын булып йөрүебез, без үзебез юк булып, начар юлларда йөргәнлектән түгел. Күрәсебез шулай булгандыр Аллаһы Тәгалә тарафыннан диеп, күргән кайгы-хәсрәтебезне юатыр өчен, йөргән җирләребездә үткән гомерләребезне искә төшереп, моңаеп-сагынып җырлап йөргән җыруларым, үзем исән чакта менә монда язып куйдым. Бу язуларымны, бәлки, бер вакыт танучы булса, укып карарлар.

Шулай, иске тормыш алышыну вакытында бер без генә түгел, бөтен Русиядә без күргәнне – яхшы тормышлы булган бар бәндәләр дә күрде.

Киләчәктәге бәндәләр тынычлык белән, тазалык белән яшәсеннәр, амин. Илаһи, Раббым, без күргән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне башка бәндәләргә тәкъдир кылма, йа, Рабби?! Хәтәр-хәвефләрдән, бәла-казалардан, дошманнардан сакла, йа, Рабби?! Дөньяда вә ахирәттә мәхрүм итмә, барчабызны да, йа, Рабби?! Амин.

Менә хәзер инде монда шуны яздым:
сагынып-саргаеп җырлап йөргән җыруларымны

Ходай безгә тәкъдир кылдың
Авыр заманаларыңны.
Рәхимеңнән ташлама
Газиз балаларымны?!

Бу җыруларымны яздым
Мин үткән гомерләремни.
Шул гомерләр искә төшсә,
Ятам ябынып юрганнарымни.

Шундай җыруларым яздым
Йөрәкләрем янганга.
Балаларның гомеренә җитәрлек
Дәүләтләрем калганга.

Бик моңаеп җырлаймын,
Нигә моңаям микән?
Яшь гомернең кадерләрен
Нигә белмәдек микән?

Яшь вакытларыбызда
Бик рәхәт яшәдек.
Фәкыйрь-фокарасы булсын –
Рәхәтләнеп ашады.

Тугыз йөз дә унҗидедә
Замана авыр булды.
Яхшы тормышлы бәндәләр
Бар да йорттан куылды.

Безнең чыбык бакчабызда
Төрле кошлар сайрады.
Йортларыбызны алыр өчен
Явызлар тешен кайрады.

Йортыбызны алыр өчен
Бик күп налог салдылар.
Тешен кайраган явызлар
Йортларыбызны алдылар.

«Йортыгыздан чыгасыз» дип,
Килеп хәбәр иттеләр.
Ике сәгать срок куеп,
Кулга язу куйдылар.

Йортыбыздан чыгып киттек
Иртәнге сәгать тугызда.
Бар йортларым өелеп калды
Инде хәзер калхузга.

Йортларыбыздин чыкканда
Барыбыз утырып еладык.
Авыр хәсрәт булса да,
Ходадин сабыр теләдек.

Йортыбыздан чыгып киттек
Барыбыз да елашып.
Теш кайраган бәндәләр
Сөенеп калды шаулашып.

Йортыбыздан чыгып инде
Барып кердек фәкыйрьгә.
Балаларым елаштылар –
Бер нәрсә юк ятарга.

Без барып кергән тол хатынның
Яшел булган морҗасы.
Оҗмах кебек йортдин чыккач
Нигә безгә дөньясы?!

Шул хатынның йортында
Җиде ай гомер кичердек.

Шулай фәкыйрьгә калсак та,
Налуглар түләп, эчердек[2].

Тагын шунысы авыр булды –
Үземне кулга алдылар.
Үзем чыгып киткәндә
Балалар елашып калдылар.

«Әткәй, кайчан кайтасың?» – дип,
Сорады кызым Кәфиям.
Елап муеныма асылындылар
Йосыф белән Мирдием[3].

Шул балаларның елашканы
Саргайтты минем үземне.
Шундай авыр хәсрәткә
Ходаем бирсен түземне.

Кулга алгач җибәрделәр
Казан дигән шәһәргә.
Яхшы тормыш аркасында
Калдык инде каһәргә.

Барып җиткәч Казанга
Яптылар безне камерга.
Саргаеп, тилмереп яттык
Өйдән килмәгән хәбәргә.

Казаннан безне җибәрделәр
Архангел дигән калага.
Салкынлыкка чыдап булмай,
Казаннан да алама.

---

[2] *налуглар түләп эчердек* – ягъни, автор түләгән салым акчаларына хакимият вәкилләре – җирле җитәкчелекнең аракы эчүе күздә тотылган.
[3] *Мирди* – Мирзыя.

Шулай хәсрәт күрсен диеп,
Явызлар дога кылгандыр.
Явызлар догасы төшмәстер,
Күрәсебез шулай булгандыр.

«Үһ, Алла» дип, бер сөйләсәм,
Бөтен күңелем хушлана.
Бик күп йөреп, бик күп күрдем,
Әкрен торырбыз, иншалла.

Чит илләрдә ризык булгач,
Күп җирләрдә булдык без.
Авыр хәсрәт булса да,
Сабырлыкка килдек без.

Ярты гомеребез үтте безнең,
Ашап-эчеп, рәхәттә.
Күпме гомеребез калды хәзер –
Баш ватыйк булып хәсрәттә.

Чит җирләрдә йөреп инде
Сау-сәламәт кайттык без.
Күрәсебез шулай булгач,
Юк гөнаһны яптык без.

Кара атта камыш дага,
Менеп бара үрләргә.
Күрәчәкне күрәлмайчы,
Кереп булмай гүрләргә.

Иртә торып, тышка чыксам,
Ай түгәрәк шикелле.
Үзем үлсәм, җаным кайтыр
Бер күбәләк шикелле.

«Сөргеннәргә сөргән җирдә әрәм булырбыз микән?»

Сабирҗан Шаһимәрдан улы Шәймәрданов (1894–1955) хәзерге Әгерҗе районының Яңа Бәзәкә авылында туып үскән һәм яшәгән. 1931 елда кулак буларак гаиләсе белән Магнитогорскига сөрелгән.

Әтисе Шаһимәрдан Мөхәммәтшакир улы (1856–1930) XX гасыр башында төбәкнең эре сәүдәгәрләреннән булып, якынтирәдәге биш авылда кибетләр тоткан, шулай ук базарларда да сату иткән, тегермәннәре булган, җирләр арендалаган. Әтиләренең сәүдә эшенә уллары ярдәм итеп, үзләре дә шул кәсепкә тартылганнар.

Совет хакимлеге урнашканнан соң хөкүмәт күп кенә байлыкларын тартып алган. 1920 нче елларда мохтаҗлар исемлегендә йөртелүләре дә никадәр авыр тормышка төшерелгәнлекләрен раслый. 1929 елда кулаклыкта гаепләүләр көчәйгәч, Шаһимәрдан Шакиров «кулак итеп әллә кайларга җибәрерләр» дип, үзенең һәм улларының өй базларында качып ятып, үпкәләренә салкын тидереп, 1930 ел башында 74 яшендә вафат булган.

Ул вакыттагы Яңа Бәзәкә авыл советының 1930 ел февраль мәгълүматында язылганча, бу авыл советы карамагындагы биш авыл да 100% колхозга кергән, элекке иң эре бай сәүдәгәр Шаһимәрдан Шакировның ике катлы таш йорты, тегермәннәре, амбар-келәтләре һ.б. каралты-мөлкәтләре тартып алынган. Өйләре озак еллар мәктәп өчен кулланылган. Совет чорында репрессияләнгән сәяси корбан Шаһимәрдан Шакиров 2016 елда реабилитацияләнде.

Шаһимәрданның олы кызлары Камиләнең гаиләсе дә

(башка авылда) кулак буларак таланып-туздырылган, ике улы – Миңнәхмәтнең һәм Сабирҗанның мал-мөлкәтләре конфискацияләнеп, гаиләләре белән Магнитогорскига сөрелгәннәр.

Миңнәхмәт хатыны, бер улы һәм ике кызы белән сөрелгән. Тагын ике кызлары 1932 һәм 1936 елларда Магнитогорскидагы баракта дөньяга килгәннәр. Шулардан бер яшендәге уллары белән 1932 елгы кыз вафат булган.

Шәймәрданов Миңнәхмәтнең кызы Мәндүмә (1924–2016) болай дип сөйләгән иде: «Магнитогорскига китергәннәр дә безне урамга ташлаганнар. Урамда ятканны хәтерләймен. Анда кешеләр җаңгыр астында ятып, шунда урамда үләләрие. Безгә дигән баракның әле баганалары гына утыртып куйган иде, җиткермәгән. Ә без шунда көз көне яңгыр астында ятканбыз. Безгә хәтле килгән кайбер кешеләрнең палаткалары барые, биргәннәр. Ә безнең өскә кияргә бернәрсә югые. Безне шәрә, ялангач җибәргәннәр. Магнитка Сабирҗан абайлардан соң китерделәр, аларның палаткасына барып яңгырдан кача идек. Баракны җиткергәч шунда бер сәке булган инде бөтенебезгә. Шунда ятканбыз. Баракта җуынырга су юк, урын юк. Магнитогорскида кешеләр бик чиләнеп торды. Ач. Ялангач. Мин хәер дә теләнеп йөрдем әле. Бик озак булмады, ахры, ул. Көз көнеме, яз көнеме йөргәнемне беләм. Кешеләр янына барып, кулны сузадырыең, биргәннәр инде. Минем иске пәлтә барые, шуның кесәсен тишеп аска төшерәдерием. Мәгъсүмә апа базарда көнбагыш сатып, акчасы да барые, тамагын туйдырып кайта торганые. Башның күрмәгәне калмады. Магниткада садикка йөрдем, мәктәпкә язылырга киемнәр юк иде. Аннары, соңрак укырга кердек, 4 ел татарча укыдым. Аннары Чиләбегә – Митрофанов совхозына күчтек, анда яңадан 4 нче класска, тик русча укыдым. Митрофанда бер бүлмәдә 2 семья тордык. Мәгъсүмә апа сугышка кадәр Бәзәкәгә кайтып килде, килгәч тә аны «за побег» берничә көнгә ябып тордылар. Әти, әни сугыш беткәч кайтып килделәр. Әти: «Анда да ачтан үлгәннәр, ярый монда җибәргәннәр, монда әйбәт яшәгәнбез», – диде».

Мәсхүдә Миңнәхмәт кызы. Магнитогорск

Мәндүмәнең сеңлесе Мәсхүдә түбәндәгеләрне сөйләде. «Әтиләрне кугач, башта Магнитогорскида торганнар, баракта. Мин шунда 1936 елда 29 апрельдә туганмын. Верхнеуральскида укыганда 1955 елда ул баракны барып күрдем мин. Магнитны төзүчеләр бар да кулаклар бит. Абыстайлар Магнитта домна мичендә эшләгәннәр, төзелештә. Әйтә торганнарые: «Ач килеш эшкә алып китәләр. Ураза вакыты булса да, конвой белән алып китәләр, конвой белән китерәләр», – диләрие».

Миңнәхмәт Шәймәрданов гаиләсе 1997 елда акланган[1]. Шул исәптән, 1–2 яшьләрендә үк үлгән сабыйлары һәм баракта 1936 елда туган кызлары Мәсхүдә дә акланган. Гүяки, ул кечкенә нарасыйларның да туганда ук гаепләре булган.

Шаһимәрдан байның уллары Миңнәхмәт һәм Сабирҗан гаиләләре шул заманда алып барылган коточкыч мәгънәсез кампаниянең корбаннары булган. Әйтерсең лә, зур җинаять кылганнар. Миңнәхмәт тә, Сабирҗан да шушы ил һәм шушы ватан өчен Беренче бөтендөнья сугышында каннарын түккәннәр, яра-җәрәхәтләр алганнар, энеләре Галиәхмәт аягын өздереп кайткан, кече энеләре Лотфулла да фронтта булган... Бер атаның дүрт улы сугыш кырында кан түккән бул-

[1] Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы. Унтугызынчы том: административ репрессияләр. Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш районнары = Книга памяти жертв политических репрессий. Том 19: административные репрессии. Агрызский, Азнакаевский, Аксубаевский, Актанышский районы. – Казан: «Хәтер китабы» нәшр., 2007. – Б. 60.

са да, бәгырьсез ватанның һич исе китми – аталарының да, балаларының да тормышларын астын-өскә китереп туздыра, күпме яшь түктерә, хәсрәткә сала һәм туган җирдән каерып, газиз кардәшләрдән аерып читкә куа...

Татарстаннан читкә сөрелергә тиешле «кулак гаиләсенең шәхси эшендәге» 1931 елның 14 июль мәгълүматларында Сабирҗан Шәймәрдановның 1917 елга кадәр игенчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнүе, 4 тегермән һәм өч кибет тотканлыгы, шулай ук базарларга сәүдә итәргә чыкканлыгы әйтелгән. Патша армиясендә хезмәт итүе, үз теләге белән акларга ияреп китеп, 6 айдан кире кайтканлыгы, шулай ук Кызыл Армиядә дә хезмәт иткәнлеге язылган. 1931 елда чәчү вакытында үзенең чәчүлек орлыкларын яшергән. Ләкин тентү вакытында 15 пот чәчүлек орлыгы табылган.

1931 елның 28 июнендә колхозчылар, авыл советы һәм активистларның гомуми җыелышында Сабирҗанның гаиләсен раскулачивать итү (ягъни барлык йорт-җирләрен, мал-мөлкәтләрен конфискацияләү) һәм сөргенгә җибәрү турында карар кабул ителгән. Авылдан җибәргәнче күршеләре, шулай ук авыл советы рәисе белән секретаре кулак С.Шәймәрданов гаиләсен сак астына алулары турында ГПУ вәкиленә имзанамә биргәннәр. Ягъни, аларны качудан, милекләрен яндырудан яисә башка төрле хәлләрдән (документта язылганча «терракт»лардан) сакларга тиеш булганнар.

Сабирҗан Шәймәрданов гаиләсендә алты кеше – үзе, хатыны Маһинур, кызы Нәкыя (1922 елда туган), улы Фәйзрахман (1926 елда туган), кызы Фаика (1929 елда туган), 70 яшеннән узган әнисе (Шаһимәрданның җәмәгате) Шәмсенниса бергә җибәрелгәннәр.

Кечкенә кызлары Магнитогорскида 1931 елның 25 сентябрендә вафат булган. Ә уллары Фәйзрахман 1933 елның 29 мартында үлгән. Әниләрен авылдагы туганы Хаҗиәхмәт 1931 елның 1 октябрендә авылга алып кайтып киткән.

Сабирҗанның энесе Галиәхмәтнең ятимә кызы (ул кече яшендә әбисе Шәмсенниса тәрбиясендә яшәгән) Миңнерәшидә

(1924–2015) болай дип сөйләде: «Мин Сабирҗан абыйларны җибәргәнне беләм. Иртәгә алып китәбез дигән төнне Сабирҗан абый кайтып керде дә: «Әнәй, безне иртәгә алып китәләр инде», – диде. Хәзер әби еларга ябышты, әби елагач мин дә еларга ябыштым. Әбине дә җибәргәннәр иде кулак итеп Сабирҗан абыйлар белән. Бүгенге кебек хәтеремдә. Иртә белән, ишегалды тулы кеше. Әбине чардакка бастырдылар да, ике милиция наган төбәделәр. Сорыйлар нәрсәдер булса. Икесе дә берьюлы атып җибәрде. Әби чардакка егылган инде куркып. Моннан, җирдән күренми бит инде егылгач. Мин кеше арасында, җирдә. Елыймын сикерә-сикерә: «Әби үлде, әби үлде-е-е...», – диеп. Аларның да, әбинең дә өйдәге, хуҗалыктагы бөтен әйберләрен алып чыгып киттеләр. Аннан соң әби белән Сабирҗан абыйларны алып киттеләр. Ике ат белән Әгерҗегә кадәр озаттылар. Мине Хаҗи абыйларга алып калдылар, сугыш инвалидының баласы, диеп. Авыл башына кадәр бик күп кеше озатырга барды. Мине бер ир-ат күтәреп калды. Ике аякларым белән чабаланып елап калдым: «Әбием китә, әбием китә-ә-ә...», – диеп. Аларын бүгенгедәй хәтерлим. Хаҗи абый әбине «Аның улы сугыш инвалиды» диеп (әтәй аркасында), эзләп, артыннан йөреп, алмага барды. Алмага баргач поезд белән кайткан вакытта бер стансада Хаҗи абый әбигә сөт алырга төшкән. Ул төшкәч поезд китеп барган. Әбине Әгерҗегә җиткәч төшергәннәр. Әйберләре-ниләре – бөтенесе поездда киткән инде».

Шәймәрдановлар гаиләсе Магнитогорскида башта палаткада, аннары 6 нчы санлы үзәк баракта яшәгәннәр. Сабирҗан тимер юл трактында һ.б. эшләрдә эшләгән. Архив мәгълүматларына караганда, ул һәрвакытта эш нормасын арттырып үтәгән, 1936 елда хәтта аның эш үтәве 209% булып, «стахановчы» икәнлеге дә теркәлгән.

Җәмәгате Мәһинур сөргендә чакта поезд астына эләгеп һәлак булгач Сабирҗан икенче хатынга – Фатыймага өйләнгән, ике уллары туган.

Сөрген тормышын, әлбәттә, бик кыен кичергәннәр. Авыр

еллар булса да, Яңа Бәзәкәдәге туганнары белән элемтәләрен өзмәгәннәр, хат-хәбәр алышып торганнар. Сабирҗанның бертуган абыйсы Гыйльмегаянга язган хатлары һәм үзенең кичерешләрен моңлы мөнәҗәт-бәет рәвешендә теркәгән дәфтәре дә хәзергәчә сакланган.

Сабирҗан Шәймәрданов мөнәҗәте язылган дәфтәр хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «324т» шифры белән саклана. Аны бу юлларның авторы 1994 елда тапшырган иде. Дәфтәр 10х11 см. зурлыктагы, барлыгы 12 кәгазьдән (24 биттән) гыйбарәт. 1–9, 15–16 битләрендә сөрелү тарихы тасвирланган «мөнәҗәт» язылган. Авторы «мөнәҗәт» дип атаса да, ул дөресрәге бәет һәм мөнәҗәт үзенчәлекләрен берләштергән әсәр. Шуңа күрә аны мөнәҗәт-бәет дип атау дөресрәк булыр. Аның кайсы елда язылганлыгы төгәл билгеле булмаса да, 1931–1939 еллар арасында дип чамаларга мөмкин[2].

Сабирҗан Шәймәрданов мөнәҗәтенең аерым дүртьюллыклары язучы Фәүзия Бәйрәмованың кулакларны сөрү фаҗигаләрен тасвирлаган «Кырык сырт» исемле романына кергән (Казан, 2005, 51 бит).

1954 елның җәендә Сабирҗан Шәймәрданов гаиләсе белән Яңа Бәзәкәгә кайткан. Туганнары белән күрешкәннәр, Сабан туйларын караганнар. Яңадан Магнитогорскига киткәч ул озак яшәмәгән, авырып дөнья куйган. Хатирәләргә караганда, туган авылын сагынып, җирсеп үлгән.

Бу гаиләнең барлык әгъзалары (шул исәптән кечкенә вакытта үлгән ике баласы һәм әнисе) – барлыгы 6 кеше 1993 елның 2 ноябрендә сәяси репрессия корбаннары буларак акланганнар[3].

Сабирҗан аганың кызы Нәкыя апа белән 2004 елда очрашкач (сөрелгәндә аңа 9 яшь булган) кайбер хатирәләре белән уртаклашты. 1931 елда эшелоннарга төяп китергәч, әремнән

---

[2] Тексты өлешчә басылды: Татарстан яшьләре. – 1991. – 28 май; Әдәби мирас: икенче китап / төз. Г.Гыйльман. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 69–74.

[3] Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы. Унтугызынчы том... – Б. 60.

Нәкыя Сабирҗан кызы.
1990 нчы еллар

башка нәрсә үсми торган таптакыр кырга урнаштырганнар. Башта чатыр-палаткалар корып яшәгәннәр. Олыларны сак астында, домна мичләрен төзергә йөрткәннәр. Кар төшеп, кышка кергәч кенә 150-200 кешелек, түбәсе дә төзелмәгән озын баракларга урнаштырганнар. Баракның ике башында ике тимер мич булып, озаклап чиратлар торып ашау-эчүне шунда әзерләгәннәр. Ике як стена буйлап эшләнгән озын сәкеләрдә гомер сөргәннәр. Ачлыктан, суыктан, төрле йогышлы авырулардан бик күп кешеләр, бигрәк тә, балалар үлгән. Әнкәләре Маһинур 1939 елда еракка су алырга барганда поезд астына эләгеп һәлак булган. Нәкыя апаның ире – Гөлем Ваһапов (1912–1990) Әгерҗе районындагы Исәнбай авылы мулласының улы булган. Аларның да алты кешелек гаиләсе йорт-җирләре һәм мөлкәтләреннән мәхрүм ителеп, 1931 елның җәендә Магнитогорскига җибәрелгән булган. 1993 елда акланганнар[4].

***

Мөнәҗәтләр яздым сезгә,
Укып карарсыңыз сез дә.
Мөнәҗәтләрне укыгач,
Дога кылыңыз сез безгә?!

Һавадагы аккошларны
Тотам дисәң, тотып булмай.
Үтә безнең яшь гомерләр
Гамәлләр бер дә кылып булмай.

---

[4] Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы. Унтугызынчы том... – Б. 15.

Кулыма алдым каләмемне,
Язаем дип сәламемне.
Гаеп итмәңез, туганнарым,
«Аһ» гына иткән сүзләремне.

Ки «бисмилла» илә башлап,
Җазамын хәсрәтем фашлап.
Ике күзем тула яшьләп,
Кыламын зар илә гөрьян.

Моны язмак нәкышь иде,
Каләмнәрем камыш иде.
Моны язган ки чакларда
Күземдин яшь тотылмады.

Атамның былбылы идем,
Анамның һөдһөде идем.
Бу хәлләргә мөбтәля булдым,
Сабыр бирсен Тәгалә Алла.

Әй, Ходаем, нитәем мин,
Чит илләргә китәмен мин,
Чит илләрдә сездин башка
Ничек гомер итәем мин?..

Кеше үз ихтыярыннан
Китәрме илләрен ташлап?!
Җыяр ыризык, эчәр сулар –
Алар барыр алдан башлап.

Кеше хәлен кеше белмәс,
Яна бәгърем, уты сүнмәс,
Сагынмакдин кеше үлмәс,
Ирешмәсә әҗәлләргә.



ای اتقایم ای انقایم ؛ بقا چیر دعا قیلک
حدادین کوب عمر صرب ؛ قاوشدرسن بزنی الله

حدایم دین مزه‌ت بولسه ؛ اچوب قایتی ایدم انی
کی حالکزنی بیان قلوب ؛ کیری کیلر ایدم موندا
حدای بیرمن ازادنجو ؛ صالدی باشیما زور قایغی
حابالهادم هیچده زارو ؛ صابر بیرسن تعاله الله
برمنکده طوی یودلارده ؛ اوطز برنچی یللار دنا
ابر دیلار طوعایلار دین ؛ صابر بیرسن اوزی الله
کی برمکده طوکم یوقده ؛ اوطز برنچی یللار دنا
ابر دیلار مالالار موان ؛ صابر بیرسن اوزی الله
شونی درینم یازغانم ؛ ایلمدن باشم نی الغانم
جللا صاغد اچار ابو قدر ؛ کوررمز حقنک یازغانن
چعوب قارایمن ابیعا ؛ تمام اون بیشلری جیتقاچده
قاوشوی جیتمی ایکان ؛ براق ایللرگه کیتقاچه یق
تاعدا اینده ی کز بز باشلار ؛ نیلدر کوررمز میعار
سوردگانلرگه ؛ سوردگان بیرده ادم بولر بز میعان

Сабирҗан Шәймәрданов кулъязмасы

Егълау да булмады файда,
Кавышмаклык безгә кайда?
Өмид бар әле Ходайда,
Кавыштырсын үзе Алла.

Сабыр итмәк кирәк безгә,
Безнең кебек коллар түзә.
Шулай да бик җөрәк өзелә,
Сабыр бирсен үзе Алла.

Хода насыйп итәр микән,
Бу сагынулар бетәр микән?
Бәнем газиз гомерләрем
Һаман шулай үтәр микән?

Әй, Әткәем! Әй, Әнкәем!
Бәңа хәер-дога кыйлың,
Ходадин күп гомер сорап?!
Кавыштырсын үзе Алла.

Ходаемдин мәдәд булса,
Очып кайтыр идем анда.
Ки хәлләрне бәйан кыйлып,
Кире килер идем монда.

Ходай бирсен аз эрәнжү,
Салды башыма зур кайгы.
Табалмадым һич тә дару,
Сабыр бирсен Тәгалә Алла.

Бер мең дә тугыз йөзләрдә
Утыз беренче елларда
Аердылар туганнардин,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ.

Ки бер мең дә тугыз йөздә
Утыз беренче елларда
Аердылар малларымнан,
Сабыр бирсен үзе Алла.

Шушыдыр бәнем язганым
Илемнән башым алганым.
Җыласак та, чара юктыр,
Күрермез Хакның язганын.

Чыгып караймын айга,
Тәмам унбишләре җиткәчтен.
Кавышуы читен икән,
Ерак илләргә киткәчтен.

Тагын инде газиз башлар
Ниләр күрермез микән?
Сөргеннәргә сөргән җирдә
Әрәм булырбыз микән?

Барак эчләрендә янадыр
Электр утларымыз.
Кайда безнең бергә булган
Рәхәт минутларымыз?

Йөрәкләремне әрнетә
Кайгы-хәсрәт утлары.
Кая китте бу дөньяның
Кадерле минутлары?

Ул кадерле минутларны
Булмый алып кайтарып.
Кайгы-хәсрәт күплегеннән
Йөримен янып-көеп.

Илдә вакытларда булсак,
Болай ук булмас иде.
Әсир бәндәләр булмасак,
Күңелләр тулмас иде.

Бар да фани маллар икән
Бу дөньяның маллары.
Бигрәк авыр хәлләр икән
Туган илдән калулары.

Вәйран булып йөрер өчен
Туган икән җанымыз.
Кайгы-хәсрәт күрер өчен
Үскән икән башымыз.

Дүрт кич кунгач, Әгерҗедән
Безне алып киттеләр.
Тәрәзәсез багуннарга
Безне илтеп керттеләр.

Тәрәзәсез багуннарның,
Паравазы ыжгыра,
Паравазның ыжгырганы
Йөрәк маен сыздыра.

Без барамыз багуннарда
Сохарилар кимереп.
Сохарилар кимергәчтен
Эчәр суга тилмереп.

Барып баксам ишегенә,
Ишекләре бикләгән.
Бер йотым су сорар идем,
Башлыклардин шикләнәм.

Җитәр инде, артык язмыйм
Кәкре каләм каурыйсын.
Алла безне барчамызны
Тугры юлына салсын.

Илдә калган туганнарны
Безләр кайтып күрсәкче.
Калган ярты гомерләрне
Туган илдә сөрсәкче.

Бу Магнит җирләрендә
Безне кылма, Ходаем?!
Гомер иткән илләремә
Кайтарсаңчы, Ходаем?!

Әй, Ходаем, инде сәндин
Ниндәй теләкләр телим?
Гомер иткән илләремә
Кайтарсаңчы дип сорыйм?!

Төнге сәгать уникедә
Безләр суга барамыз.
Салкын төнне суга барып,
Гомерлек чир аламыз.

Бөтен Магнитны яктырта
Электр кабынганда.
Өзелеп-өзелеп моңнар язам –
Укырсыз моңайганда.

Безнең маллар булган икән
Бар да фани, вәйран мал.
Әсир бәндә була торып,
Аерылып китү авыр хәл.

Дүрт-биш симиям[5] берлә
Илемездин чыктым мин.
Быел җәйләрнең эчендә
Күп хәсрәтләр йоттым мин.

Мәүлед ае башы берлә
Өемезгә керделәр.
Таң атып, көн җәелгәнче
Илемездин сөрделәр.

Туган илдән чыгып киткәч
Карадым күмелгәнче.
Туган илемне онытмамын
Гүрләргә куелганчы.

Бер Ходайның тәкъдиренә
Юк икән һичбер чара.
Мондин авыр хәсрәтләргә
Җөрәкләрем тулы җара.

Әбәү, Алла, уф, Алла!
Күп кайгылар башымда.
Кыямәт көнне бу кайгылар
Нурлар булсын каршымда?!

Агачның башын җил алыр,
Илтеп дәрьяга салыр.
Безнең газиз башларымыз
Кайда китеп югалыр?

Әбәү, Алла, уф, Алла!
Күкрәгемнән зарланып.
Безнең гомер узар инде
Моңлы коштай зарланып.

[5] *Дүрт-биш симиям* – гаилә әгъзалары күздә тотыла.

Өй турында бодаем,
Көн дә чыгып ураем.
Урталай өзгән җылан кебек
Аерды бер Ходаем.

Биек тауның башында
Өелеп үскән ак сәрдә.
Дөньялыкта кавыша алмабыз,
Кавыштырсын мәхшәрдә.

Ак Идел буйлары ямьле,
Шаулай аның камышы.
Нурлы йөзләрем саргайды,
Хәләлемнең[6] сагышы.

Индениләр язаем,
Бетмәйдер лә сүзләрем?!
Кыямәтсез күрмәм инде
Хәләлемнең йөзләрен.

Илаһи, җөмлә галәмне
Яраттың кодрәтең берлә.
Рәхим кыл рәхмәтең берлә
Бәңа төшкән җәфаларны?!

Мөнәҗәтем яза-яза
Каләм тоткан кулым тала.
Күземдин канлы яшь ага,
Фирак булдым бән анлардин.

Языйм микән, җитәр микән,
Бу кайгылар бетәр микән?

---

[6] Сабирҗанның хәләле (хатыны) Маһинур 1939 елда поезд астына эләгеп, фаҗигале төстә һәлак булган.

Бу кайгылар бетәр булса,
Бетергүче үзе Алла.

Ак Иделләрне кичкәндә,
Җырлап ишкәк ишкәндә,
Кычкырып җылап җибәрәм
Хәләлем искә төшкәндә.

Биек тауның башында
Орым-орым түтәлләр.
Бән аерылдым, булды читен,
Аерылмасын бүтәннәр.

Бу бәетләрне язганда
Зиһеннәрем җыелмады,
Бу сүзләрне дә язганчы
Күземдин яшь тыелмады.

Языйм микән, җитәр микән,
Язып сүзләр бетәр микән?
Сагынмаклык җәрәхәте
Күңелләрдин китәр микән?

Үләр идем, үләр хәл җук,
Бик сагынамын, түзәр хәл юк.
Ерак булдым туганнардин,
Сабыр бирсен үзе Алла.

Кемнең артык зиһене булса,
Дәхи дә бераз сипләсен.
Кем укыса бу нәзымны,
Язучыны, ки, сүкмәсен.

«Гаиләмне ач калдырды»

Авыр салымнарга бәйле 1931 ел башында язылган гаризаның авторы Канәфия Мортазинның элек дин әһеле булганлыгы әйтелмәгән. Ихтимал, ул XX гасыр башында таза тормышлы, бәлки, сәүдә белән шөгыльләнгән крестьян булгандыр. Гаризаның язылган датасы илдә кулакларга көрәшнең һәм читкә сөрүләрнең аеруча көчәйгән чорына туры килүе дә шул фикерне куәтли.

Башкортстанның Яңавыл районы прокуроры ярдәмчесенә адресланган гаризаның каралама тексты 17,5x22 см. зурлыгындагы ике кәгазьдә (дәфтәрнең куш битендә) гарәп хәрефләрендә ике мәртәбә кабатлап язылган. Текстларның эчтәлекләре бер төрле үк диярлек. Бер-берсен тулыландыра торган урыннары монда берләштереп бирелде.

Әлеге кульязма китапханәгә 1995 елда Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Башкортстанның Тәтешле районы, Кодаш авылында Әмир Кәшфиевтән алынган иде. Хәзер ул Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1592т» шифры белән саклана. Кәгазьнең 1а–2б ягында гариза шәмәхә төстәге кара белән, ә 1б–2а тарафында гади карандаш белән язылган. Сакланышы уртача. Кайбер сүзләрдә «җ» хәрефе урынына «й» язылган.

***

Яңавыл райо[ны] прокуроры могавиненә[1]
Башкортстан Җөмһүрияте
Яңавыл районы

[1] *могавиненә* – бу сүз кульязмада ялгыш «мәгарифенә» дип язылган.

Югары Кодаш авылының гражданы
Канәфия Мортазиннан
гариза.

1930 нчы елның 25 нче октябрендә Түбән Кодаш авылы шурасының утырыш карар[ы] булып, шул утырышта минең хуҗалык тормышымны тикшереп карамастан, хуҗалыгыма зәгыйфьлек китер[ер]лек, индивидүәлнәй заданиягә кертеп, 274 пот икмәк, 55 пот бәрәңге, 12 пот орлык, 3 пот житен сүсе, 30 кадак киндер сүсе заданиясен салып, 274 пот ашлык салдырып, хуҗалыкта булган симиямне ач калдырды. Дәхи икмәк союзы икмәк акчасын алган вакытта 130 сум акчага 30 сум крәстиян займын бирде. Үзем сельсоветтан добровольный 5 сум заём алган идем. Шушыларга карамастан, 15 сум заём – барысы 50 сум салдылар.

Аның бәгъдендә 2 яшьтәге ике ат өчен көчем житмәслек каты задания – урман биреп, кисеп ташырга, ат башы өчен 180 кубометр урман чыгарырга дип аңлаттылар. Ташу өчен и[л]тәсе жир – урманнан пристен[гә] 25 чакрым.

Бу йөкләтмәләре һич тә көчне житкереп буласы түгел и була торган да түгел. Бу гына булмады, 31 нче елның 23 нче фибралында хуҗалыгымдагы бердәнбер сыерымны жибәрде задания мясыга 1931 нче елның 22 нче фибралында.

Беренчедән, хокуклы гражданмын. Төп көнкүрешем атам вакытында да, фәкыйрьлек берлән көн күрдем. Атадан калып та көн итәмен түбән дәрәҗәдә. Атамнан калган бертуганнар бергә жыелып, бер йортта көн итәбез ике хуҗалык булып. Ике хуҗалык туганга бер ат, бер сыер, 5 баш сарык, җан хисабы задания салган вакытта 8 җан идек, хәзер көн 6 җан булып, ике хуҗалык булсак та аерым түгел. Ике хуҗалыкта атабыздан калган ике ызба, бүтән нәрсәбез – бергә эшләп тапкан бер келәт, бер муча. Чәчеп алган иг[ене]мез 8 дисәтин 15 сутык. Эшче кулдан 8-дән түбән – бер җан, 60-тан[2] юкары – бер җан. 30 нчы ел сельхозналог түләдем 19 сум 15 тиен.

Бер игенче крәстиянне шушылай изүе сельсоветның үзеннәндер дип хисап итмәдем. Үземнең хуҗалыкка караган-

[2] *«8-дән», «60-тан»* – ягъни, 8 яшьтән, 60 яшьтән.

да, шушы – югарыда күрсәтелгән сүзләрем өчен, сельсоветтан алынган дөрес ысправкалар копияләремне беркетеп, безгә баш булган мәхкәмә – прокурор могавиненең тикшереп хәл кылуын түбәнчелектә сораучы Мортазин.

23/II–31 г.


23 / II-31г.

Канәфия Мортазин гаризасы

1931 елда чыккан мөнәҗәт

Шундый исем белән аталган бу мөнәҗәт укымышлы муллаларның һәм элек яхшы-җитеш тормышта яшәгән бик күп татарларның кулак итеп чит-ят җирләргә сөрелгән чорына турыдан-туры бәйле.

Текстның кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1112т» шифры белән саклана. Аны Казан шәһәренең Дуслык бистәсендәге Лениногорск урамында яшәүче Мөкаддисә Хәлиуллина китапханәгә 2001 елның 22 мартында тапшырган.

Мөнәҗәт тексты 16,5х20,5 см. зурлыгындагы, 1940 нчы елларга нисбәтле, 3 кәгазьдән гыйбарәт дәфтәр битләренең 1а һәм 1б кәгазьләренә шәмәхә төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә язылган. Кулъязманың 2а һәм 2б кәгазьләрендә – «Сарим Садыйк угылы чыгарган мөнәҗәт», 3а һәм 3б кәгазьләрендә – Шәрәфетдин белән Хәдичәгә кардәшләре язган хат. Ягъни, бу өч текст шул хатны язган кеше кулы белән бер үк вакытта теркәлгән бербөтенне тәшкил итә. Хат өлешендә Лаешларны үтеп Казанга килеп йөргән вакытлары искә алынган. Сакланышы яхшы. Текстларда хәреф хаталары шактый.

***

Бән өемдин чыгып киттем,
Ки мисле дөньядин үттем.
Хода тәкъдире дип белдем,
Сабырлыклар бирсен инде.

Бәнем илем ерак калды,
Туганнарым елап калды.
Йөрәгемне сагыш алды,
Сабырлыклар бирсен инде.

Елашалар атлар җиккәч,
Кайталмас диеп, бер киткәч.
Кайтырбыз вахытлар йиткәч,
Сабырлыклар бирсен инде.

Туганнарым еламагыз,
Безне читкә ташламагыз!
Кавышырбыз, еламагыз,
Сабырлыклар бирсен инде.

Кайда бәнем газиз атам,
Бер күрергә җаннар атам.
Күзем бетә ки еласам,
Сабырлыклар бирсен инде.

Ки бән киттем чыгып ерак,
Туганнар калдылар елап.
Ничек түзә бәнем йөрәк?
Сабырлыклар бирсен инде.

Газиз атам, газиз анам,
Аерылды газиз балаң.
Күзләр бетәр, күп еламаң,
Сабырлыклар бирсен инде.

Адәм угыллары уйнагай,
Бәнем анам ки йоклагай.
Зарый[лар] кылып егълагай,
Сабырлыклар бирсен инде.

Атам-анам калды анда,
Дучар булдык ки без монда.
Сары булды кызыл йөзләр,
Сабырлыклар бирсен инде.

Кичкә керсәм бән сайрыймын,
Һавадан йолдыз саныймын.
Сагынып ки бән елыймын,
Сабырлыклар бирсен инде.

Кайда безгә хәер бирмәк,
Кайда безгә ураза тотмак?
Бәхил булың, вафат булсак!
Сабырлыклар бирсен инде.

Оча кошлар, китә казлар,
Ки сайрыйдыр сандугачлар.
Ничек түзә газиз башлар?
Сабырлыклар бирсен инде.



Мөнәҗәтнең кулъязмасы

«Мин мулла да түгел, кулак та түгел»

Ибраһим Мөхәммәтшакир улы Төхфәтуллин 1867 елда Манзарас авылында (хәзерге Кукмара районында) дөньяга килгән, данлыклы Түнтәр мәдрәсәсендә белем алган. 1890 елның 23 декабрендә Алабуга өязенең (хәзерге Менделеев районындагы) Тогыҗа авылы мәчетенә икенче имам итеп расланган. Совет хакимлеге чорында (бигрәк тә, 1920 нче еллар ахырында), башка имамнар кебек үк, сыйнфый дошман буларак эзәрлекләүләргә дучар булган.

Монда тексты бирелгән гаризаның кайсы елда язылганлыгы төгәл билгеле түгел. Шулай да, 1931 (яки 1932 елда) язылгандыр дип фаразларга мөмкин. Аның «үзем 67 яшемдә» дигән сүзенә караганда, әлеге документ 1934 елда язылган дип аңлашылырга да мөмкин. Әмма элекке чорда гомумән (дин әһелләре арасында бигрәк тә) кешенең яше һиҗри (мөселманча) ел буенча исәпләнгәнен искә алганда, 1867 елда дөньяга килгән Ибраһим хәзрәткә һиҗри белән 67 яшь 1932 елда тулган. Тогыҗа авылының административ бүленеш буенча 1930 елның 23 июленә кадәр Чаллы кантоны Камай волостенә кергәнлегенә дә игътибар итмичә булмый. Дөрес, бу очракта, ягъни Ибраһим мулланың үз гаризасын ерак Себердән язып җибәргәненә һәм өлкән яшенә бәйле рәвештә, туган төбәгендәге административ төгәллекләрне саклап бетермичә, элек гадәтләнгәнчә язган булуы ихтимал.

Ибраһим мулла, күрәсең, Себердә вафат булгандыр. Тогыҗа авылындагы өлкәннәр аның хәләл җефетен – абыстайны гына хәтерлиләр икән.

Әлеге кулъязма Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «555т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә бу юлларның авторы та-

рафыннан 1995 елда тапшырылды. Без аны 1985 елда Ибраһим хәзрәтнең Әгерҗе районындагы Тәбәрле авылында яшәгән кызы Мөнәвәрә Габдерәхимовадан алган идек. Ул гаризадагы «угылым Мәгъсүм куып җибәрде» дигән сүзләрнең, катлаулы заманга күрә, карт мулланың улларына һәм башка туганнарына зыян-зарар килүдән куркып язганын елап искә алган иде.



Ибраһим Шакир улы гаризасы

Гариза 14,5х20,5 см. зурлыгындагы бер кәгазьнең (дәфтәр битенең) ике ягына гарәп хәрефләрендә, шәмәхә кара белән язылган. Сакланышы уртача.

Зәйәблиния.

Чаллы кантоны Камай булысы Туйгыҗа авылының Шакиров Ибраһимнан шул хосуста – мине Себердә булган туганым, авыру сәбәпле чакырып, хат йибәрде. Мин аларга хат яздым: «Барырга акчам юк, акча йибәреңез?» – дип. Алар янә хат йибәргәннәр: «Кил, акча бирермез, ничек тә тырыш, әнкәй бик көчкә[1]», – диеп.

Үзем карт – алтмыш җиде яшемдә. Мине сельски сәвит хуҗалыктан чыгарып, угылым Мәгъсүмне хуҗа кылды. Шулай булгач, мин сәвиттән язу алып, Чаллыга барып, пашпорт алдым да монда – Себергә туганым янына килдем. Кайтырга акчам юк, монда бирмиләр, акчалары юк. Инде мин кайтмаймын, шушында – бертуганымга симия булып керәмен.

Ошбу язу баргач ыспракы бирүеңезне үтенәм.

Вә һәм Туйгыҗа авыл халкына бик күп сәлам, картларынаяшьләренә.

Вә һәм Мәгъсүм угылым мине куып йибәрде, анда торырга мөмкин булмады. Курыктым. Минисияләргә мәгълүм иттем Камайда. Монда да мәгълүм булдым.

Мин мулла да түгел, кулак та түгел. Мәгъсүмнәрдән аерылдым. Җитмешкә җиткән бер карт булдым.

Бәхил булыгыз, үлсәм. Авырыбрак торам, сихәтем юк. Тәкъдир безгә шулайдыр, бер сүз дә әйтеп булмый.

Ысправкы бирә күреңез, монда торырга тазарып.

Ибраһим Шакир угылы.

[1] *бик көчкә* – авыр хәлдә, авыру.

Төрмәдә яткан мулланың мөнәҗәте

Бу мөнәҗәт-бәетнең авторы һәм язылган елы мәгълүм түгел. Шулай ук кайсы төбәктәге нинди авыл кешесе тарафыннан иҗат ителгәне дә билгесез. Шулай да аны язган кеше элекке имам икәнлеген белдергән, хатыны Әшрәфелҗамал исемле булуын һәм үзен тоткынлыкка дучар иткән кешенең (Садыйк улы Йосыф) исемен теркәгән. Кулъязма дәфтәрнең Богырослан шәһәрендә табылуын исәпкә алганда, ихтимал, мөнәҗәтнең авторы да шул төбәкнеке булгандыр.

Мөнәҗәтнең ахырында (кулъязманың 6б кәгазендә) «Бик сагынган вакытларымда язылган мөнәҗәтләрем бу. Укучылар, гаеп итмәгез, укыгач дога кылыгыз?!» дигән сүзләре бар.

Текст Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1785т» шифры белән саклана торган, 1940 нчы елларга нисбәтле мәктәп дәфтәренең 1б–2б кәгазьләреннән алынды. Дәфтәрдә ул нәкъ шулай – «Төрмәдә яткан мулланың мөнәҗәте» дип исемләнгән. Кулъязма китапханәгә 1998 елда Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Богырослан шәһәре мәчетеннән алынган иде.

Гомуми күләме 22 кәгазьдән торган, 16х20,5 см. зурлыгындагы дәфтәрдә барлык текстлар да гарәп хәрефләрендә, шәмәхә төстәге кара белән теркәлгән. Әлеге мөнәҗәттән башка, анда бүтән мөнәҗәтләр һәм бәетләр (Сак-Сок һ.б.), «Хәзрәти Мәрьям» исемле шигъри әсәр текстлары да язылган.

Дәфтәрнең башындагы тышлыгында үзбәк телендә «43 нче мәктәпнең 1 нче сыйныф укучысы Шәяхмәтова З-ның арифметика дәфтәре» дип язылган. 43 нче мәктәп дигән санга карганда, ул зур шәһәрдә, ихтимал, Ташкент шәһәрендә булгандыр.

Дәфтәрнең ахыргы битендә (22б кәгазьдә) гарәп хәрефләре белән Миңнезифа дигән язуы бар. Ә 1а кәгазьдә рус хәрефләре белән «Хисамидинова Минзифа Сайфутдиновна, родилась 1890, Садритдинов Хазиахмед Гизетдинович, 1933 г.» исемнәре теркәлгән. Бу исемнәрдән дәфтәрнең иясе Миңзифа Хисаметдинова икәнлегендә шик юк, ә Хаҗиәхмәт (1933 елда туган дип аңлашыла), аның якын кешләреннән берсе булгандыр.

Электрон мәгълүмат чараларында Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Күки авылыннан 1931 елның июлендә Чиләбе өлкәсенә сөрелгән, 1882 елда дөньяга килгән Миңзифа Сәйфетдинова турында мәгълүмат бар. Бу Миңзифа белән дәфтәрдә исеме теркәлгән Миңзифа, бәлки, бер үк кеше булгандыр дип гөманларга мөмкин.

Дәфтәрдәге исемнәргә туры килгән башка исемнәрне дә теркәп куярга булдык. Гыйззетдин Садретдинов исемле бер кеше 1879 елда хәзерге Башкортстанның Дәүләкән районында дөньяга килгән, 1941 елның 3 октябрендә 58 нче маддә буенча гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителгән, 1993 елда акланган. Шулай ук Гыйззетдин Гыйльметдин улы Садретдинов хәзерге Чистай районының Савинов авылында 1914 елда туган, 1930 елда кулга алынып, 58 нче маддә буенча гаепләнгән (колхозга каршы котырту, дини агитация) һәм 2 ел 6 айга ирегеннән мәхрүм ителгән.

***

Хода исеме илә башлыймын кәлямем,
Дәхи пәйгамбәрә улсын сәламем.

Ирәрмән бер мәхәлләнең имамы,
Ул Илаһым үзе Һадиел-имами.

Яшем бәнем кырык бергә җитептер,
Хода миңа каза тәкъдир итептер.

Хода тәкъдире бөйләдер колына,
Гөрифтар улмышам кяфер кулына.

Бәне ошбу хөкүмәт кулга алды,
Дәхи мәхбүс итеп зинданга салды.

Камыш тик нечкәреп калды беләгем,
Итем бетте, мәгәр калды сөягем.

Безем тик ничәләр мәхбүс улыптыр,
Бу зинда[нда] бәгырьләре көептер.

Кемесе егълайур «атам, анам» дип,
Кеме егълайур зар «калды балам» дип.

Кемесе егълайур калмыш малы өчен,
Кеме зар егълайур газиз җаны өчен.

Кемесе аерылып җөмлә малындин,
Җөда улмыш мәхәббәтле ярындин.

Кирәк, улсын сәнең бәгърең кара таш,
Түзеп булмый, бу күздин түгәбез яшь.

Утырып һәр тарафта сөйләшәбез,
Түзә алмый, ахырда агълашабыз.

Бу ни гаҗәп – сагынмакны куя алмыйм,
Сезнең нурлы йөзегезгә туя алмыйм.

Әгәр ятсам, йокым килми, уянам.
Төшем эчрә сезне күреп куанам.

Уянсам әмма юк булып каласыз,
Йөрәккә янган утларны саласыз.

Сагынсам да сезне иртә вә кичә,
Өмид итәм күрәрмән дип һәмишә.

Ки кичләрдә йокым килми ятамын,
Укып Коръән гариб күңлемне ачамын.

Ерак җирдә бу Коръән юлдашымдыр,
Сагынсам, сандугачлар моңдашымдыр.



Мөнәҗәтнең кулъязмасы

Сәлам улсын карый калган атама,
Дәхи сакалы агарган агама.

Бәнемчөн хәсрәтә куйма башыңни,
Кичә-көндез акызма күз яшеңни?!

Өмидем шул карый калган атадан –
Онытмагыл безе хәер-догадан?!

Сәлам улсын сәңа Әшрәфҗәмалем,
Шәрафәтле, мәхәббәтле хәлалем!

Бәнем өчен чигәрмесән мәшәкать,
Кичә-көндез күреп михнәт вә хәсрәт?

Васыятем будыр сәңа, хәлалем –
Бәнемчөн кайгырып йөрмә, һилялым?!

Исән булсак, озакламай, килербез,
Әүвәлге тик дәхи гомер сөрербез.

Дәхи хәсрәтле калмыш кыз туганнар,
Бәне даим карендәш дип уйлаңлар!

Бәнемчөн кайгырып йөрмә бигаять,
Хода бирсен сезә тәүфыйк-һидаять.

Ходаның әмерене куймаң һәмишә,
Теләң Хакдин бәне иртә вә кичә.

Энеләрем, колак салың сүземә,
Исән кайтсам, күренерсез күземә.

Горурланып, бигаять азмагайсыз,
Шәригатьтән тыш юлга басмагайсыз!

Телеңез саклаңыз ялган яладин,
Хода саклар сезне җөмлә бәладин!

Дәхи мәхәллә халкыма сәламем,
Сәлам бәгъдендә ошбудыр кәлямем:

Ходаның боерыгын куймаясыз,
Шайтан әмеренә буйсынмаясыз!

Хосусан кем, укыгайсыз намазы,
Кичә-көндез кылың Хакка ниязы!

Сезә әйтәм хосусан, аксакаллар,
Бәңа ихлас илә даим бакыңлар!

Әгәрчә кем ерак йирдә үземез,
Егетләргә будыр безнең сүземез:

Телеңез һәр урында саклагайсыз,
Олугларга җаман сүз катмагайсыз!

Әманәттер, әманәттер, әманәт,
Хода җөмләмезе кылсын сәламәт!

Хатын-кызга будыр әйткән сүземез:
Намәхрәм күрмәсен сезнең күзегез!

Олуглар алдыга атламагайсыз,
Аларга каршы юл таптамагайсыз!

Беләсез бит Хода сәвәр әдәпне,
Әдәпле бул, әдәпле бул, әдәпле!

Дисәң «Кемдер бәне фетнәгә салган?
Бәне мәхбүс итеп шатлыкка калган?»

Садыйк угылы Йосыф дәйү беләсең,
Ходаның тәкъдире шулдыр, күрәсең.

Ходаның дошманыдыр, юлдан азган,
Дүнеп Хакдин, динне аякка баскан.

Курыкмай Тәңредән һичбер замани,
Нахак башыма салды бу җәфани.

Хата дип, хатымны сүкмәгәйсез,
Бәнемчөн кайгырып, яшь түкмәгәйсез!

Вәләкин ташлама хәер-догадин,
Хәляс итсен Ходаем бу бәладин.

Илаһым, кыл гөнаһлардин сәламәт,
Кыямәт көн бәне кылма мәлямәт?!

Ирерсез барча галәм падишаһи,
Гөнаһларны гафу кылгыл, Илаһи?!

Илаһым сән, Илаһым сән, Илаһи,
Мөяссәр кыл безә дөррел-җинани?!

Әгәр дус күрсәңез бәнем үземни,
Кабул итең бәнем әйткән сүземни?!

Укыр булсаң бәнем язган хатымны,
Дога кылгыл, онытмагыл атымны?!

Укып алсаң бу хатларны, алып куй,
Аяк астыга таптамай, салып куй?!

Әманәттер укучыга, әманәт:
Ходa җөмләләремезе кылсын сәламәт.

«Мин колхозга керергә каршы түгел»

Бу документны язган Шакир хәзрәт Махиянов хәзерге Башкортстанның Дүртөйле районындагы Тәкәрлек авылында 1907–1928 елларда имамлык вазифаларын үтәгән. Гаризаның датасы күрсәтелмәгән. Шулай да анда 1907 елда 42 яшендә, хәзер исә 70 яшендә булуы язылганга һәм элекке дин әһелләре үзләренең яшьләрен һиҗри (мөселманча) ел исәбе белән исәпләгәнлегенә караганда, бу гариза 1933 елга карый. Тарихтан билгеле булганча, совет хакимлегенең сыйнфый дошманнарын кулаклыкта гаепләп эзәрлекләүнең иң көчле вакыты 1930–1931 елларга туры килгән һәм яңадан 1933 елда икенче дулкыны булган.

Гариза авторы үзләренә өстәмә салым бирелүгә бәйле рәвештә гаять авырлык белән көн күреп, җан асрауларын белдергән.

Электрон чыганакларда Ш.Махияновның 1861 елда дөньяга килгәнлеге турында һәм 1930 нчы елларда җавапка тартылган булуын белдерә торган мәгълүматлар да бар.

Кульязма Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «521т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә 1994 елда Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Башкортстанның Дүртөйле районындагы Иске Солтанбәк авылында Вазыйха Хәммәдиевадан алынган иде.

Гариза тексты 15х21 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына кызгылт-көрән төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә, бик вак итеп язылган. Сакланышы уртачадан түбән: бөкләнгән урыннарында сүзләр бик начар танылa, шулай ук түбәнге

өлеше ертылган булуы сәбәпле, сүзләрен танып булмый. Кәгазьнең икенче ягында гади карандаш белән төрле догалар теркәлгән.

***

Тәкәрлек авылы
советында хезмәт иткүче
әгъзаларга үтенечле
Махиянов Шакирдан

гариза.

Шулай ук бән – Тәкәрлек авылы Махиянов Шакир, бик түбәнчелек илә, үтенәм ошбу гаризам илә без фәкыйрьгә 82 сумлы налог аклаты бирделәр.



Шакир Махиянов гаризасы

Мәгълүмеңез, 27 нче декабрьдән бирле раздельный акты белән башкаланып, кеше ишеге төбендә җөримен. Үзем бер зәгыйфь, сукыр, җитмеш яшьлек бер картмын. Һичбер дахутлы эшем юк. Көздән бирле сатып алып ашыймыз. Үткән ел арыш булмаган сәбәпле, унике сажин сөргән җирем сачелмәй калды. Шуның илә күп вакыт алабута икмәге ашарга туры килде. Мәгълүмеңезчә, эш тә юк бит, шул дахут каян килсен?

Үзем тукыз йөз җиденче ел кырык ике яшемдә мулла булып, егерме сигезенче ел муллалыгымны куеп, бу көндә хокук көтеп, колхоз члены булуны теләймен. Бүгендә җитмеш яшьлек бер картмын.

Бу да мәгълүм булсын – революция булганга кадәре җирсез-сусыз тереклек иттем. Кайчан революция чыккач җирле-сулы булып, кеше булдым.

Үземезнең тереклегемездә май һәм күкәй һәм он һәм гайре нәрсәләр сатып, файда күргән кеше түгелмен. Корткам ярдан керәч алып кайтып сатып, киндер сугып кешегә – шулай ризыкланып көн кичерәмез.

Шуның илә үтенәм – миңа бу налог тиеш түгел, чөнки мин колхозга керергә каршы түгел, һичбер вакыт һәрбер эшкә карышканым юк. Шуның илә үтенәм сез хөрмәтлеләргә минем налогны киметүеңезне.

Үтенәмен гаризамны кабул итмәй, илтифатсыз калдырмассызлыкларыңызны.

«Кечкенә генә урын бирүегезне сорыйбыз»

Мулланәҗип Җәлалетдин улы Җәлалетдинов (1871–1948) хәзерге Әгерҗе районының Тәбәрле авылында мулла гаиләсендә туган һәм шунда гомер иткән. 1899–1929 елларда авылның беренче мәхәллә мәчетендә имамлык вазифаларын үтәгән. Дини белемне Әгерҗе мәдрәсәсендә алган. Ул төбәкнең зур абруйлы хәзрәтләреннән берсе һәм Коръән-хафиз буларак танылган. Рус грамотасын да яхшы үзләштергән.

1920 нче еллар уртасында совет оешмалары, төрле сәбәпләр табып, аңа дини белем бирергә рөхсәт итмәгән. Хәзрәтнең кызы Сафия апа дин сабагын укыттырмас өчен бик мәкерле хәйләләр уйлап чыгарылганын сөйләгән иде. Үтенеч белән Әгерҗе кантон идарәсенә барган муллага: «Рөхсәт итәбез, тик мәчет эченә бәдрәф ясатырга кирәк булыр, балаларга кыш көннәрендә хаҗәтләрен үтәргә урамга чыгып йөрү кыен бит», – дигәннәр. Мулла кеше гомере буе үзе имамлык иткән мәчет эченә ничек итеп хаҗәтханә ясатырга җөрьәт итсен инде?! Шулай итеп, совет хакимлеге мулла белән бергә мәхәллә халкын да мыскыллаган.

1928 елда Тәбәрледәге ике мәчет тә ябылган һәм дин әһелләре вазифаларыннан читләштерелгән. Шуның белән берлектә, мулла һәм мәзиннәргә зур салымнар йөкләү дәвам иткән. Мулланәҗип (Нәҗип) дин әһеле булуы сәбәпле, 1928 елда бөтен йорт-җирләреннән, мал-мөлкәтеннән һәм хокукларыннан мәхрүм ителгән. Өйләре тартып алынгач, башка кешеләрнең мунчаларында яки ташландык каралтыларда яшәргә мәҗбүр булганнар.

Нәҗип мулла республиканың рәсми матбугат органнарыннан берсе «Крәстиян гәзите»нең 1929 елгы 18 май санында игълан бастырырга мәҗбүр булган. Анда «Муллалыкларын таш-

лыйлар» исеме астында «Әгерҗе районының Тәбәрле авылы мулласы Нәҗип Җәлалетдинов шул елның 12 нче апреленнән башлап үзенең муллалыгын ташлавын белдерә» дигән язма чыккан. Югыйсә, Нәҗип мулла 1928 елда раскулачивать ителеп, бөтен малы-мөлкәте тартып алынган хәлдә дә, имамлыгын дәвам иткән булган.

Дәүләт салымнарын түләргә теләми дип гаепләнеп, М.Җәлалетдинов 1929 елда хөкем ителгән һәм җиде елга Архангельскига сөргенгә җибәрелгән.

Бөтенләй чарасыз калган гаиләсенең башлыгы – хатыны Зифа абыстай 1931 елның 6 мартында, кулак хатыны буларак, СССРның ерак өлкәсенә 5 елга җибәрергә хөкем ителгән. Абыстай, балаларын ияртеп, Нәҗип хәзрәтнең сөрген урынына киткән. Кызлары Сафия һәм уллары Мәсхүт сөйләве буенча, алар Архангельскиның үзендә бер йортның чормасында яшәгәннәр. Әтиләре ат белән ризык ташыган, Архангельск портында һәм агач-урман чыгаруда эшләгән. Нәҗип хәзрәт андагы тоткыннарны бер ара грамотага (русча уку-язуга) да өйрәткән.

Мулланың гаиләсе берничә елдан соң Тәбәрлегә кайткач та Зифа абыстай күрешергә баргалап йөргән. Шактый таушалган Мулланәҗип хәзрәтне Габделхәй исемле улы 1936 елда авылга алып кайткан. Яшәргә йорт-җирләре булмаганлыктан, авыл советына мөрәҗәгать иткәннәр.

Гаилә башлыгы гарәп хәрефләре белән 1936 елның 18 маенда язган гаризаның караламасы хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «4891т» шифры белән саклана. Аны хәзрәтнең оныгы Өлфәт Бәшәров гаиләсеннән 2009 елның 8 ноябрендә бу юлларның авторы алган иде. Гариза тексты 14,5х21 см. зурлыгындагы бер кәгазьгә (дәфтәр битенә) гарәп хәрефләрендә, кара төстәге кара белән язылган. Саклнышы уртача.

Бу гаиләгә үзләре сораган җиргә урнашырга рөхсәт бирелгән. Алар авылдагы берәүнең иске кара мунча бурасын


1936 نچی یل 18 نچی مای

Зифа

Зифа

Зифа

Җәлалетдиновлар гаризасы

урам читенә алып килеп, астына куыш-чокыр (землянка) казып, шунда яшәгәннәр. Элекке мулла гаиләсенә ярдәм итү, ипи сыныгы булса да бирү, гомумән, аралашу авылдашларга тыелган. Хәзрәт вафатына хәтле авылдагы дини йолаларны үзе башкарган.

Нахакка җәберләнгән Җәлалетдиновларның репрессия корбаннары буларак акланулары турындагы мәгълүмат юк, Хәтер китапларында да чыкмады, мулла гаиләсе әгъзаларының үзләренә ул хакта шулай ук бер кәгазь дә бирелмәгән.

Ул заманда төрмә яки сөргеннән авылларына кайтканнан соң ярымземлянкаларда яшәгән татар муллалары аз булмаган. Мәсәлән, Балтач районындагы Арбор авылы имамнарының берсе – Мотыйгулла хәзрәт Зыятдинов (1888–1967) кулаклыкта гаепләнеп, өч ел сөрген җәзасын тутырып кайткач җиргә яртылаш казып эшләнгән кечкенә генә өйдә торган[1].

***

Әгерҗе районы Тәбәрле авыл советы идарәсенә
шул авылның Нәҗип Җәлалетдинов,
Зифа Госманова һәм дә
Ләбибә Нәҗипова, Кави Нәҗиповтан

гариза.

Үзебезнең бүгенгәчә яшәгән урыныбыз башка кешегә бирелү сәбәпле, бу көндә без сездән сорайбыз безгә кечкенә генә бер урын билгеләп бирүегезне. Әгәр мөмкин булса, бәрәңге бакчасы белән бер җирдә булуын теләйбез. Үзебез теләгәнчә, мөмкин булса: 1 нче – Нәбиулла Һадиев белән рәттән; 2 нче урын – Хатбуллин Тимергали белән Хафиз Закиров арасыннан.

Бу теләгебезне игътибарга алып, мөмкин кадәре тизлек белән хәл кылуыгызны [сорыйбыз]. Бүгеннән, мәгълүмегез, безгә бәрәңге утыртырга кирәк.

---

[1] Мөхәммәтшин Г. Балтач мәчетләре: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2018. – Б. 65–66.

«Бер егъламаган кеше калмады»

Бу хат Кәшфелголүм исемле мулла тарафыннан элекке күршеләренә язылган. Хатның башында адресаты «Хәсән абзый» дип аталган булса, аннан соң берничә мәртәбә «Газетдин абзый» диелгән. Бу затлар, ихтимал, бергә яшәгән аталы-уллы кешеләр булгандыр.

Хатның авторы кайсы төбәк кешесе булганы анык билгеле түгел. Шулай ук хатның кайдан язып җибәрелгәне дә күрсәтелмәгән. Әмма андагы «Урал таулары чаклы сәлам» дигән гыйбарәгә, шулай ук «зар» сүзенең һәм Закирә исеменең «дар, Дакирә» дип язылуларына караганда, Урал тауларына якын төбәктә яшәгән кеше дип яисә Урал аръягына (Магнитогорск яки Чиләбе тирәсенә) сөрелгән кеше каләменнән чыккан дип тә фаразларга мөмкин.

Һәрхәлдә, хатны язучы «үз илендә торырга мөмкин булмаган муллалар һәм байлар... һәркаюсы гаеткә килделәр, үзләрен үзләре яшермәделәр» дигән сүзләреннән туган җиреннән мәҗбүри читтә яшәгән, административ сөргендәге кешеләрдән булганлыгы аңлашыла. Ләкин хатта үзләренә чакыру сүзләре булуы, ураза тотып, гаетләрне зурлап үткәрүләре һәм Нәзарәт файдасына акча җыюлары турындагы мәгълүматларга караганда, бик үк кырыс чикләнеп һәм ирексез рәвештә гомер сөрмәгәннәр кебек.

Язылган елы үзендә күрсәтелмәгән булса да, «алдагы 37 нче ел» дигән сүзләрдән хатның 1936 елда язып җибәрелгәнлеге аңлашыла.

Әлеге хат Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1192т» шифры белән саклана. 17x21 см. зурлыгындагы бер кәгазьдә (дәфтәр

битендә) гарәп хәрефләрендә, карандаш белән язылган бу хат Казан шәһәренең «Каравай» мәчетеннән бу юлларның авторы һәм китапханә хезмәткәре Ирек Һадиев тарафыннан 1993 елның ноябрендә алынган иде. Сакланышы уртача.


Каравай мечеть
1993 г. Ноябрь

Кәшфелголүм мулла хаты

***

Вә биһи нәстәгыйн.

Хәсән абзый! Сезләр[гә] без ки, мәгълүмеңез – күрше муллагыз Кәшфелголүмнән гаять тә сагынып, бер сөйләшергә дар булып, Урал таулары чаклы сәламнәремне озатып, бәгъдендә сау-сәламәт яшәвеңезне теләп, фатиха үтенеп калам. Шулай ук абыстайга, һәкәза бик сагынып бик күп сәламнәр сөйләп, бәгъдендә сау-сәламәт яшәвен теләп, фатиха үтенеп калам. Шулай ук Сәүбән дуска һәм киленнәрнең һәр икесенә дә, аермаенча, сәламнәр сөйләп, бәгъдендә сау-сәламәт яшәүләрен теләп калам. Шулай ук Госсаметдин дуска һәм киленгә һәм Дакирәгә һәм дә абыстайга һәм Әминәгә гаять тә сагынып, Урал таулары чаклы сәламнәремне озатып, бәгъдендә сау-сәламәт яшәүләрен теләп калам. Шулай ук авыл күршеләрнең һәркаюсына, аермаенча, сәламнәр сөйләп калам.

Аның соңында, Газетдин абзый, минем үтенеч сүзем шул – Дакирә безгә тиешле әманәт акчаны тулысы илән тапшырды, бик сөендем яшь көенә бәхилләтергә тырышуына. Рәхмәтләр яусын, гомергә рәхәт яшәсен!

Газетдин абзый, син Дакирәгә тиешле акчаны тапшырырсың. Сиңа да, Газетдин абзый, рәхмәт «мулла үзе кайткач бирәмен» дип әйтүеңә. Мин алдагы [җәйдә] 37 нче елның агус числасыз кайта алмам. Күп акча түгел, мин кайтуны көтмәгәне дә ярый, мин сиңа ышанам.

Аның соңында, Мөзәянә «Дакирә килә» дип әйткәч, килә дип бик көткән идек. Озак вакытлар килмәй торгач, бик гаҗәпсендек. Чирләсә дә, авылга кайтып китмәскә кирәк иде. Безгә килеп, тәрбияләнеп ятса лутчы булыр иде. Киләсе килсә, һаман да мөмкин. Килсен, әйтерсез. Фатыйма бик сагына, бик сөйли Әминә илән Дакирәне.

Аның соңында, Фатыймадан абыстайга һәм Дакирәгә, Әминәгә – һәркаюсына, аермаенча, сәламнәр сөйләп калам.

Аның соңында, рамазан шәриф рузәләре бик тынычлык белән, тәмле ашлар ашап, рузәне тәмам итеп, гаеткә бардым.

2 мең чамасы мөселман булырга кирәк, Нәзарәт файдасына 1 мең ярым иганә җыелды, мәхәллә идарәсенә, зиярат файдасына тагы шу[л] 1 мең дә дүрт йөз сум иганә җыелды. Монда ике Коръән-хафиз бар, берсе гает укыды, икенчесе Коръән укыды – бер егъламаган кеше калмады, гаҗәеп! Аларның мәкамнәре бигрәк тә хозур булды. Дөнья кайгылары таралды, шулкадәре рәхәт таптым. Быел башка елларга караганда да халык күбрәк булды, иганә күбрәк дип әйттеләр. 70 мулла булды, гел менә шул минем кебек – үз илендә торырга мөмкин булмаган муллалар һәм байлар җыелган. Шулар һәркаюсы гаеткә килделәр. Алай үзләрен үзләре яшермәделәр.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин, бик матур үткәрдек.

Ходаем, гомер биреп, киләсе рамазан айларын күрсәтеп, кайгысыз-хәсрәтсез тотуны насыйп итсен һәрбарчамызга!

Сагынычлык мөнәҗәте

Бу мөнәҗәт тексты ахырында язылган сәлам хаты сүзләреннән авторы Галләм исемле булганлыгы аңлашыла. Ул мөнәҗәт-хатны җәмәгатенә адреслаган. Тексттан күренгәнчә, Галләм Казан төрмәсенә китерелгән һәм шунда вакытында әлеге шигъри хатын язган. «Эчәсе суларым булган Казан дигән калаларда» һәм «Җәмәгатем килер диеп, барам төрмә капкасына» дигән юллар турыдан-туры шуны белдерә.

Мөнәҗәт авторы, мөгаен, руханилардан булгандыр. Һәрхәлдә, XVII гасыр төрки әдибе Аллаһыяр Суфыйның татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек итеп кулланылган, бик популяр «Сөбател-гаҗизин» әсәренең шигъри юллары эпиграф рәвешендә язылганлыгы «Сагынычлык мөнәҗәте»нең авторы шактый укымышлы кеше булганын белдерә. Гомумән, мөнәҗәт эчтәлегеннән дә авторның диндарлыгы күренә.

Язылган елы күрсәтелмәгән булса да, аның 1930 нчы елларга караганлыгын чамаларга мөмкин.

«Сагынычлык мөнәҗәте» дигән исеме астында «Яшел тавыш берлән, Мөхәммәдия көенә» дигән аныклагыч сүзләре бик сагышлы-моңлы итеп көйләп укылырга тиешлеген белдергән. Мондагы «яшел тавыш» гыйбарәсе ирония төсмерендә кулланылган. Тексттагы кинаяле гыйбарәләр тагын да бар. Мәсәлән:

Йөз мең яшәүләрен теләп,
Дога кылам Ысталинга,

– юллары, һичшиксез, яшерен кинаяне белдергән. Чөнки мөнәҗәтнең авторы үзен генә түгел, меңнәрчә башка укымышлы һәм тырыш кешеләрнең җәберләнеп-мыскылланып дошманга әверелүен, газиз гаиләләреннән һәм мал-мөлкәтләреннән мәхрүм ителеп, төрмә һәм лагерьларга ябылуын бик яхшы

аңлаган. «Йөз мең яшәү» гыйбарәсе төрки-татар суфичылык әдәбиятында күп гасырлар дәвам итеп килгән.

«Дога кылам Ысталинга» дигән юллар Сталин заманындагы иронияле башка бер такмакны да искә төшерә:

Каһәр суккан Николай
Ике сыер саудырды.
Рәхмәт яусын Сталинга –
Бер кәҗәгә калдырды.

Монда авыл кешесенең каһәрләнгән Николай патша заманындагы тормыш-көнкүрешен яңа – совет власте чорындагы хәле белән чагыштырып, кинаяле «рәхмәт» әйтелгән.

Шулай ук, «Сагынычлык мөнәҗәте»ндәге:

Кайгырмаек маллар өчен,
Өйрәнәбез санагатькә,

– дигән сүзләре дә, гүяки, хәләл мөлкәтләре талап алынганына аптырамыйча, зур эшләргә өйрәнүне өстен куйган.

Бөтен дәүләт файдасына
Ихлас берлән түгәм көчне,

– дип язылган юлларда да ирония көчле. Ирексез хезмәтнең, гомумән, ихластан башкарылган булуына кем генә ышаныр икән?!

Кулъязмадагы текстның ахырында сәлам хат рәвешендәге мондый юллар бар:

«Әл-хатты бакый вәл-гомрү фани.

Сез ки, сәгадәтле улан, үзем өчен кадерле булган сәвекле җәмәгатем ...[1] без ки, картыгыз Галләмдин гаять сагынып, дөньядагы сачәкләр санынча, үземнең карт җөрәгемдин өзелеп чыккан ялкынлы сәламнәрем күндерү бәгъдендә ватанымда изге тормышларыгыз, без кайтуга сабры җәмиләләрне Җәнабе Хакдин тәзәррыг кыйлып, фатихада калам».

Текст 17х20 см. зурлыгындагы, 1930 нчы елларга нисбәтле ике кәгазьнең (мәктәп дәфтәренең куш битендә) шәмәхә төстәге кара белән, гарәп хәрефләрендә язылган. Сакланышы уртача. Мөнәҗәт тексты кулдан ясалган кысага алынган

[1] Кулъязмада исем урыны буш калдырылган.

(беренче битендә бизәкле) һәм һәр битнең ике як читләренә берәр строфа язылган. 2б кәгазьдә гади карандаш белән рус хәрефләрендә «З.Хакимов» һәм «Муллах...» дигән имзалар язгаланган.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «516т» шифры белән саклана торган кулъязма китапханәгә Ижевск шәһәре мәчетеннән бу юлларның авторы һәм китапханә хезмәткәре Ирек Һадиев тарафыннан 1993 елның 6 декабрендә алынган иде.

Мөнәҗәт-хатның Ижевск мәчетеннән алынган булуы уңаеннан бер нәрсәне искәртергә тиешбез. 1920–1930 нчы елларда – элекке муллаларны рәхимсез җәберләү чорында Татарстан, Удмуртия, Башкортстанның, Пермь һәм Киров өлкәләрендәге кала һәм авылларның имамнары һәм мәзиннәре, гаиләләре белән качып, Иж шәһәренә дә килеп төпләнгәннәр, берникадәр вакытка сыенып-котылып торганнар. Анда чагыштырмача тыныч һәм иркенрәк яшәгәнлектән, укымышлы татарлар Иж шәһәрен «Гареш күләгәсе» дип йөрткәннәр. 1930 нчы елларда Ижевск каласындагы шундый, элекке указлы муллалар егермеләп булган, шулардан 15 кешенең исемнәре мәгълүм[2].

Текстның төп нөсхәсендә аерым хәрефләр һәм иҗекләр төшеп калган, кайбер орфографик хаталар да бар.

***

Халика, каилмән үз ноксаныма,
Күп җәфа кыйлдым үземнең җаныма.
Халика, йа Әүвәлән, йа Ахирән!
Нәфс-ү-шайтан җаныма булды бәла[3].

---

[2] Мәрданов Р. Иж шәһәре татарлары тарихыннан. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2006. – Б. 95–97.

[3] Бу шигъри юллар Аллаһыяр Суфыйның «Сөбател-гаҗизин» исемле дини-әхлакый әсәреннән алынган (Китабе мөстәтаб вә шәрифел-мәаб Сөбател-гаҗизин. – Казан: Чирков хатынының вәрәсәләренең табыгханәсе, 1904. – Б. 61–62).

Әсгадәкә Аллаһу фид-дарайни

Сагынычлык мөнәҗәте

(яшел тавыш берлән, «Мөхәммәдия» көенә)

Карт-карыйлар серләшәбез
Рәсүл тарихларын сөйләп.
Минем җазган мөнәҗәтне
Укый күрең инде көйләп.

Бөтен дәүләт файдасына
Ихлас берлән түгәм көчне.
Мөнәҗәтне шуңар язам –
Яшь буынга гыйбрәт өчен.

Чыгып карыймын айларга
Тәмам унбише җиткәчтен.
Кавышулар кыен икән
Җырак җирләргә киткәчтен.

Җолдызларга карыймын да,
Нур балкыгач зикер итәм.
Саулыгыма шөкер итәм,
Сине күрсәм, һушым китә.

Тутый кошларның баласы
Басып сайрай курайларга.
Сәналәр әйтәм Ходайга
Әйтеп дөрле бәлаләргә.

Казан мәсҗидләре биек,
Аның түбәләре кыек.
Бәнем күңелләрем боек,
Рәхим кыйл, йа, Рәсүлулла?!

Казан мәсҗид азан укый,
Мисыр күгәрчене гөрләй.
Сез газизләр искә төшә,
Җөрәккәем шуңар дөрләй.

Казанга килгән юлларның
Ике яклары канаулы.
Без килмәдек мең яшәргә,
Минем көннәрем санаулы.

Эчәсе суларым булган
Казан дигән калаларда.
Гомерләр бирсен анага,
Сабырлык бирсен балага.

Минем җазган мөнәҗәтем
Балаларыма кушыла.
Ризыклар монда булу
Һич тә килмәде һушыма.

Илаһи тәкъдир иткәндер
Гөнаһыма җәза берлән.
Зарыйг кыйлам бер Алла[га]
Ихлас калебләрем берлән.

Әй, шәфкатьле балаларым,
Үзәккәемне өзәсез!
Ризык беткәч кайтырбыз,
Сабырлык берлән түзәрсез.

Игълан булгач барам ашка,
Таягым тартмайдыр ташта.
Ата-баба да күрмәгән
Инде килде безнең башка.

Көне-төне якты бирә
Корпустагы электрләр.
Кайгылы көннәр авышыр,
Шатлыклы көн килеп җитәр.

«Сагынычлык мөнәҗәте» кулъязмасы

Иртән торсам, азан укып,
Мәсех тартам беләгемә.
Җәнабе Хакдин зарым кылам
Сезнең өчен теләгемә.

Сәхрә вакытлары үтәр,
Сачәкләр сәҗдәгә китәр.
Юлбашчыбыз игълан итәр –
Кайту вакытларым җитәр.

Күркәм киемнәр киярләр
Казан забуты тукыгач.
Өмит ит чын, газиз карчык,
Минем хатымны укыгач.

Әй, сәвекле җәмәгатем,
Төшләремдә күрәм сине!
Бик сагынсам уйлыймын да,
Һич чара юк, түзәм инде...

Иртә торгач кыям басып,
Сачләреңне үрерсеңме?
Җомга көннәр дога кылам,
Дөшләреңдә күрәсеңме?

Кыр казлары очып китә
Урал тауларына карап.
Безнең көннәр шулай үтә
Утырган көннәрне санап.

Дәрья сулары кушыла
Бәхре мохыйт атласына.
Җәмәгатем килер диеп,
Барам төрмә капкасына.

Сәламнәр әйтеп җибәрәм
Һавадин очкан кошларга.
Җазмас идем мөнәҗәтне,
Җазамын эчем пошканга.

Шәфәгатьле җәмәгатем,
Күңел салма хыянәткә!
Милләт өчен искә төшер
Балаларга гыйбадәткә.

Бөтен дөньяны балкыта
Мәгарифләрнең яктысы.
Изге тормышлар балкысын,
Җинаять булсын актыкка.

Айа, йаным, кызыл алмам!
Күз алдында тора шәүләң.
Куанычлы яшәүләрне
Насыйп әйлә, Кадыйр Мәүлям?!

Әй, сәвекле җәмәгатем!
Итагать бул гыйбадәткә?!
Кайгырмаек маллар өчен,
Өйрәнәбез санагатькә.

Иртән торгач корпусларда
Сайрашабыз күрешкәндә.
Хода бирсен сабырлыклар,
Ирешербез уңышларга.

Эшләгән эшләрем саләт
Дус-дошманнар арасында.
Рәхимсез карашлар түгел
Безнең Казан каласында.

Кыйблалардин җилләр исәр
Газиз бәйрәм көннәрендә.
Уйлыймын да үткәрәмен,
Йокым килми төннәремдә.

Минем болай булуларым
Һич тә килмәде һушыма.
Без килмәдек мең яшәр[гә],
Кыр казлары да кушыла.

Минем өчен сәдака бир
Мин укыган остазыма?!
Йөз мең яшәүләрен теләп,
Дога кыйлам Ысталинга.

Безне искә төшерсәгез,
Китапларны ачып кара!
Килеп китсәң дә – ни чара?
Юктыр инде сезгә ара...

Җиде көннәр арасында
Аңар булыр хуҗа җомга.
Куанычлы кайту берлән
Күңел салам изге юлга.

«Бик тук, бер исәбем дә юк»

Шаһимәрдан Мөхәммәтзариф улы Зарипов хәзерге Әгерҗе районындагы Тәбәрле авылында сәүдәгәр гаиләсендә 1884 елда дөньяга килгән, тормышы җитеш булган. 1911–1912 елларда ул төбәкнең иң зур байларыннан сәүдәгәр һәм җирбиләүче Латыйп Вахитовның хуҗалык эшләрен алып барган. 1917 елга кадәр бер ара Иж корал заводында да эшләп алган.

Шаһимәрдан Зарипов.
1910 нчы еллар

Совет хакимлеге урнашкач, Ш.Зарипов 1923–1926 елларда страхование буенча агент һәм 1923–1929 нчы елларда авыл советының җир төзү эшләре вәкиле, 1930 нчы елда чәчүлек орлык җыю буенча ышанычлы вәкил, 1931–1932 елларда Әгерҗе заготконторасының вәкиле булган. Колхоз әгъзаларын тикшерү вакытында, Ш.Зарипов кулак дип табылып, 1933 елда колхоздан чыгарылган һәм хөкем ителеп, 6 айга мәҗбүри урман эшенә җибәрелгән. Ул, Лубян урманхимия производствосында эшләп, үзен тырыш һәм алдынгы, намуслы кеше буларак күрсәткән.

Шаһимәрдан Зарипов 1934 елда яңадан колхозга алынган. Ләкин, дәүләт салымнарын түли алмаганлыктан, мөлкәте конфискацияләнгән. Совет власте алдында электән «гөнаһлыгаепле»ләр: сәүдәгәрләр, таза тормышлыларны рәхимсез

эзәрлекләү вакытында – 1937 елда Зариповлар гаиләсенә тагын бәла килгән. Шул елның 5 декабрендә Ш.Зарипов кулга алынып Әгерҗегә алып кителгән. Аннан Казанның 2 нче санлы төрмәсенә озатылган.

Тикшерү-гаепләү эшләре дәвамында ачыкланганча, Шаһимәрдан Зариповның совет властенә ятышсыз (ләкин туры һәм хаклы) сүзләре булган икән. Өлкәннәр аның кулга алынуына «мәчет манарасын төшерделәр, гаетләрне кайда укырбыз?» дигән сүзләре сәбәпче булган дип искә алалар иде. Динебез өчен иң авыр 1927–1930 нчы елларда аның мәчет мөтәвәллие (идарә эшләрен башкаручы) булып торганын исәпкә алганда, шундый сүзләрне әйтүе бик мөмкин.

Архив документында теркәлгән «гаепләре» шактый. Мәсәлән, Ш.Зарипов 1936 елның 1 сентябрендә Әгерҗегә баргач «Авылларда колхозчыларның хәле авыр, икмәк юк. Шуңа карамастан, заёмга язылырга мәҗбүр итәләр. Идарәгә керсәң, ике коммунист ике яктан «заёмга язылырга кирәк, югыйсә дошман буласың» диләр – теләсәң-теләмәсәң дә язылырга туры килә. Ел буе колхозда эшләп тә, бернәрсә алмагач, тормыш мени бу!» – дигән икән. Шул ук 1936 елның 27 сентябрендә Әгерҗедәге «Союзптицепродукт» конторасына кергәч: «26 сентябрь көнне безнең авыл өстеннән Ерак Көнчыгышка таба 30 аэроплан очып узды, сугыш чыгар, ахрысы», – дип әйткән сүзләре дә гаепкә алынган. Ш.Зарипов 1937 елның 24 июлендә ул заман өчен тагын да хәтәррәк сүзләр ычкындырган: «Сез шәһәрдә яшисез, хезмәт хакы аласыз, ипи борын төбегездә. Менә авылда торып карасагыз иде, анда яшәп булмый. Узган ел әле ашлык бар иде, тик аны Әгерҗегә алып киттеләр дә, колхозчылар иписез калды, ач тордылар инде. Моңа беркем дә борчылмады. Халык тизрәк сугыш булганны көтә. Сугыш булса, авыл халкы совет властенә каршы барачак. Совет власте бу турыда яхшы белә, шуңа күрә, ничек тә сугышмаска тырыша. Сугыш булса, алар бетәчәк. Халык хәзерге ачлыкны беркайчан да онытмаячак. Хәзер күп кешеләр мал-туарсыз, кайберәүләр йортсыз да калды». Менә бу ачы хакыйкать

сүзләре Ш.Зариповның үз башына җиткән. Ул кулга алынганда гаиләсе бик ишле – хатыны, балалары һәм онықлары – барлыгы 9 кеше булганнар.

1937 елның 5 декабрендә Әгерҗедәге сорау алу вакытында Шаһимәрдан Зарипов гаепләүләрнең бөтенесен дә кире кагып, «беркайчан да андый контрреволюцион сүзләр сөйләмәдем һәм коммунистларга каршы коткы таратмадым» дигән. Тик аңа нисбәт ителгән барлык сүзләр, контрреволюцион эшчәнлек һәм совет властена яла ягу буларак, гаепләү документына теркәлгән. Шунда ук 1933 елда Ш.Зариповның тегермән тартканда тоткарлык чыгарып, колхоз атларын фуражсыз калдыруы һәм 1917 елга кадәр Л.Вахитовның ышанычлысы буларак «гөнаһлары» да өстәп язылган. Аңа карата хөкем чыгарган «өчлек»нең карарында системалы рәвештә советка каршы агитация алып баруы (сугыш булачагы, совет властенең бетәчәге, колхозлардагы ачлык турындагы провокацияләре, ВКП(б)га заёмнар турында яла ягып дискредитацияләве) әйтелгән. Сугыш булу очрагында советка каршы күтәрелү турында пропаганда алып барган. Фураж орлыгын тартуны тоткарлап, атларны фуражсыз калдырганлыгы да язылган. Шушы гамәлләре өчен Шаһимәрдан Зарипов 10 елга лагерьга ябарга хөкем ителгән.

Зарипов Шаһимәрдан, сәяси репрессия корбаны буларак, 2001 елның 15 мартында акланган.

Аның 1938 елда гаиләсенә язган ике хаты сакланып калган. Гарәп хәрефләре белән язылган ул хатлар Тәбәрле авылында яшәүче оныгы Рәүфәт Шәймәрдановта саклана.

Икенче хатындагы адресыннан аңлашылуынча, Ш.Зарипов җәза вакытын Медвежьегорск лагеренда үткәргән икән. Хат текстыннан күренүенчә, анда танылган муллалар да булган.

Шаһимәрданның оныгы Нурмөхәммәтнең оныгы Айдар Шәймәрданов әлеге хатлар уңаеннан язган мәкаләдә мондый юллар бар: «...Бераздан бабайның хатлары килүдән туктаган. Аның соңгы әманәтен Кызылъяр авылы мулласы алып кайткан. Шаһимәрдан бабайның каты авырып вафат булуы, Мед-

вежья Гора станциясендә мөселманнарча җирләнүе билгеле була»[1].

Шаһимәрдан Зариповның 1897 елгы бертуган энесе Тимергали дә репрессиягә дучар булганын искәртик. Ул 1931 елның 20 мартында кулга алынып, шул елның 7 сентябрендә ТАССРның Баш сәяси идарәсе тарафыннан 5 елга концлагерьга җибәрүгә хөкем ителгән. Җәза вакытын Беломорканал төзелешендә үткән һәм 1934 елда вакытыннан алда азат ителгән.

1. Шаһимәрдан Зариповның гаиләсенә язган хаты. 1938 ел.

Һу Аллаһу әл-Барый,
Ерак җирнең хәле.

Гаять хөрмәтле иптәшем Мәүлихага бик сагынып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә угылым Шаһимөхәммәт илән киленем Һаҗәргә бик сагынып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә угылым Нурмөхәммәт илә угылым Рифкатькә бик сагынып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә кызым Гүзәл илә угылым Шәүкәткә бик сагынып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә барча авыл күршеләргә, барча агай-энеләргә һәм дә Хуҗамөхәммәт кияү илә Хәдичә кызыма, һәм дә кодача илә Касыйм кодага, һәм дә Имаметдин кияү илә Фатыйма кызыма, һәм дә Мулланур кияү илә Мәдинә кызыма, һәм дә кодагыйга барча балалары илән, бик сагынып, бик күп-күп сәламнәр укып калам.

Үзем хәзергә таза, сау-сәламәт, акрын бер көйгә эшләп йөримен. Агач юл ясап йөрибез. Дүрт мәртәбә комиссия булды, зур врачлар карап, йәнвәлит таптылар. Эшләсәк, тугыз йөз грамм икмәк, рабучай талон алабыз. Бу вакытта ашау җитә. Эшләмәсәң, дүрт йөз грамм икмәк, основной талон аласың. Булган кадәр, эшләргә тырышамыз.

Балалар бик үскәндер инде? Нурмөхәммәт икенчегә күчә

[1] Шәймәрданов А. Ерак бабам хатларын укыдым // Ватаным Татарстан. – 2001. – 20 ноябрь.

алдымы? Рифкать тә керә торгандыр инде? Кайчан укырга башлайлар? Күңелләрен төшермәңез, сораган әйберләрен алып биреңез! Тырышып укысыннар!

13 нче июльдә язган хатыгызны 22 нче июльдә алдым. Ни язганыгыз – мәгълүм булды. 20 нче июльдә салган посылкагызны һаман алмадым әле. Бу хатны кичектереп язарга туры килде, посылка көтеп тордым.

Хәлегез булып, посылка салсаңыз, күп салмагыз. 8 кило чамасы булса, җитәр. Күп салсаңыз, расхут күп чыгар. Тәмлерәк нәрсәләр салыгыз. Акча булса, монда икмәк бар. Кара икмәк килосы 1 сум 5 тиен. Посылкага ниләр салганыгызны әйтеп язмагансыз. Кышка аяк башына кияргә ...[2], бер кием бияләй салсагыз ярар иде. Мәдинә Бубыйда торамы, Тирсәдәме? Кодашта эшләгән икмәген алдыгызмы? Ашлыклар ничек? Бәрәңгеләр яхшымы? Алмалар бармы?

Беломор-Балтыйк каналларыннан парахут белә зур күлләр белә өч йөз километр кадәр җиргә кайттык. Ленинградтан 6 йөз [километр] кадәр җирдә, шул күлләр буенда торамыз. Янымда булган мөселман иптәшләр: Уфа Камалетдинев Зыя казый, Бирский Латыйпов Хәсән хәзрәт, Казан Зарипов Камил мөәзин, Әгерже Әсәдуллин Габдулла мулла, Әхмәтша кода[3].

Маһинур түтәйнең җан агасы Мөбарәкҗан ни эш белә хөкем ителде? Нәсифулла[4] котылдымы? Барын да әйтеп языгыз. Без хат алгач бик сөенәбез. Авылда ни хәлләр бар? Үзегез ни хәлдә торасыз?

Башка язар сүз юк. Хуш, сау булыгыз!

Сезләрнең хәерле гомерләреңезгә бәрәкәт һәм сәламәт кайтып, күрешүне теләп язгучы мәгълүм әткәңез Шаһимәрдан дәйү беләсез. Әдрис шул.

1/VIII–38.

Күзлекне салсагыз ярар иде, язу укып булмай.

---

[2] Хат текстындагы берничә сүз укылмый.

[3] *Әхмәтша кода* – Әгерже районындагы Кодаш авылы кешесе.

[4] *Нәсифулла* – 1937 елда «спекуляция» өчен хөкем ителгән авылдашы Н.Нигъмәтуллин.

Хатта телгә алынган кайбер шәхесләр турында кыскача мәгълүмат

Камалетдинов Зыя казый – Зыяэтдин Җамалетдин улы Камалетдинов (Зыяэтдин әл-Камали, 1873–1942) – танылган дин галиме, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, фәлсәфәче, тәрҗемәче, Уфа шәһәрендәге «Галия» мәдрәсәсен оештыручы һәм 1907–1918 елларда җитәкчесе, 1908 елдан Уфа шәһәренең Икенче җамигъ мәчете имамы, 1923 елдан Уфадагы Диния нәзарәтендә казый булган шәхес. Мисырда «Әл-Әзһар» университетында белем алган, дини-фәлсәфи әсәрләр авторы.

Зыя Камали Диния нәзарәте җитәкчелегенә каршы 1936 елда оештырылган сәяси гаепләүдә башкалар белән бергә кулга алынган. 1938 елның гыйнварында 58 нче маддә буенча 7 елга хөкем ителгән. Медвежья Гора лагеренда тотылган. 1938 елның көзендә Уфага өстәмә тикшерү эше буенча кайтарылгач, 1939 елда яңадан лагерьга җибәрелгән. Әмма юлда авырып, эшелоннан төшерелгән һәм озакламый Куйбышев шәһәре төрмәсендә вафат булган. 1956 елда акланган.

Латыйпов Хәсән хәзрәт – Хәсән Латыйп улы Латыйпов, хәзерге Башкортстанның Борай районында 1881 елда туган. Бөре шәһәрендә имам булып торган. 1931 елның 16 июлендә кулга алынып, 58 нче маддә буенча 10 елга хөкем ителгән. 1989 елда акланган.

Зарипов Камил мөәзин – Камил Зариф улы Зарипов, хәзерге Әлки районындагы Яңа Чаллы авылында 1899 елда туган. Казан шәһәрендәге «Кызыл мәчет»тә мәзин булган. 1932 елның 9 июлендә кулга алынып, 16 декабрьдә 58 нче маддә буенча 3 елга концлагерьга хөкем ителгән. Аннан соң, күрәсең, тагын кулга алынып җәза бирелгәндер.

Әсәдуллин Габдулла – Габдулла Әсәдулла улы Әсәдуллин (1893 елда туган), 1937 елның 12 апрель көнендә Әгерҗедә кулга алынган һәм шул елның декабрендә 10 елга хөкем ителгән. 1989 елда акланган.

2. Шаһимәрдан Зариповның гаиләсенә язган хаты. 1938 ел.

Һу Аллаһу әл-Барый,

Ерак җирнең хәле.

Сез ки, гыйззәтә лаек вә хөрмәтә муафыйк улан иптәшем Мәүлихага, без ки иптәшең Шаһимәрданнан бик сагынып вә бик саргаеп, бер күреп сөйләшергә зар булып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә угылым Шаһимөхәммәт илән киленем Һаҗәргә, без ки әткәгездән бик сагынып вә бик саргаеп, бер күрергә зар булып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә угылым Нурмөхәммәт илә угылым Рифкатькә, һәм дә кызым Гүзәл илә угылым Шәүкәткә бик сагынып вә бик саргаеп, бер күрергә зар булып, бик күп-күп сәламнәр укып калам. Һәм дә барча кияүләр һәм кызларга һәм барча кардәшләргә һәм барча агай-энеләргә һәм барча авыл күршеләргә, һәрбарчасына, аермаенча, бик сагынып вә бик саргаеп, бер күрергә зар булып, бик күп-күп сәламнәр укып калам.

Сәлам бәгъдендә үзем, әлхәмделилләһи, сау-сәламәт йөримен хәзергәчә. Мондин түбән – әмре Аллаһыныңдыр. Сез хөрмәтлеләрне дә сәламәттер диеп беләмен. 13/VIII-да язган мөбарәк хатыңызны 6/IX алдым. Ниләр язган – мәгълүм булды. Квитансәгә акча юнәтеп, товар алуыңызга мин бик шатландым да... «посылка салабыз 10 көннән дигәч» тә бик шатландым.

Мин группа турында язган идем, йәнвәлит «В» диләр, ягъни эшкә яраксыз таптылар. Миңа һичкем авыр эш кушарга хакы юк һәм һичкем авыр эш кушмай да. Эшемез авыр түгел, бик җиңел. Барагымыз бик тыныч, бик тук һәм бер исәбем дә юк. Сез генә юк. Өс-баш та бик бөтен: яңа чалбар, яңа зимнәстүркә, яңа ботинка бирделәр. Хәзергә эшемез бик яхшыланды. Хәзергә акчага да мохтаҗ түгел, Аллага шөкер. Шикәрсез чәй эчмәймен, һәрвакыт шикәр булып тора. Икмәк тә бик яхшы.

1/IX-дә Садретдиннәргә хат язып салдым, 22/VIII-сендә алардан хат алган идем... Мулланур кияү җегет кешеме? Димче кем булды? Болай ару гына кебекме? МТС-та кем булып

эшләй? Кодагый килгәне бармы? Барын да әйтеп языңыз бу хатны алгач та?!

Сез мин сораганга җавап языңыз, төшереп калдырмагыз. «Пәкри әби[5] исәнме? Алмалар бармы?» дигән идем – берсен дә язмагансыз. Минем бик беләсем килә. Үгез исән үстеме? [Ничек] торасыз? Алла хәерен насыйп кылгай иде. Амин. Үзеңезнең хәл-әхвәлләреңезне әйтеп, авылда ни хәлләр бар – әйтеп языңыз.

Башка сүз юк. Хуш, сау булыңыз.

Сез хөрмәтлеләрнең исән һәм тыныч яшәүләрен теләп язгучы мәгълүм әткәңез Шаһимәрдан Мөхәммәтзариф угылы дәйү беләсез.

8/IX. [1938 ел].

Шәйхетдинев[6] ни сәбәпле снимать ителде? Хәзер ни囙 эштә эшләй?

Командировканың исеме алышты. Яңа адрес:

Кировская ж/д

Ст. Медвежья Гора

п/о Повенецкое

22 Волозерское отделение

1 мех. лаг. пункт. Получить Зарипову Шаймардан.

---

[5] *Пәкри әби* – иң карт авылдашларының берсе, ул вакытта 90 яшендәге карчык – Фәхерниса (Фәхри).

[6] *Шәйхетдинев* — 1929–1933 һәм 1937–1938 елларда Тәбәрле авылының ВКП(б) оешмасы җитәкчесе Әхмәтшакир Шәйхетдинев (1900–1940). 1938 елның җәендә, сәламәтлеге какшау сәбәпле, вазифасыннан азат ителгән.

МАНАРА БӘЕТЛӘРЕ

Илдә совет хакимлеге урнашкан 1917 елдан ук руханиларга, дини оешмаларга һәм гыйбадәтханәләргә авыр көннәр килгән. Дин һәм дин әһелләре – большевистик тәгълиматның төп сыйнфый дошманнарыннан берсе булганга күрә, 1920 нче еллар ахырында руханиларны эзәрлекләү аеруча көчәйгән.

1928–1929 елларда Россиянең төрле төбәкләрендәге мәчетләр ябылып, хөкүмәт карамагына алынган, манаралары киселгән, имамнар һәм мәзиннәр репрессияләнгән. Мәчет манараларын кисү фаҗигаләре күбесенчә 1930 нчы еллар башына туры килгән. Ул вакытта исән калганнарын 1940–1950 нче елларда кисү вакыйгалары да булган.

Мәчетләрнең дин тотучылар карамагыннан алынуы һәм манараларын кисү вакыйгалары халыкның күңелен бик рәнҗеткән. Совет хакимлегенең мондый рәхимсезлегенә ачынган татар халкы бәетләр чыгарган һәм мөнәҗәтләр язган, елый-елый көйләп укыганнар, яшертен генә дәфтәрдән-дәфтәргә күчергәннәр. Алар, гадәттә, «Манара бәете» дип аталган. «Манара бәетләре»нең төрле вариантлары иҗат ителгән, алар кайчакта үзара кушылган яисә бүтән бәет юллары белән дәвам иткән. Гомумән, андый бәетләр күптөрле. Шунысы истә тотылырга тиеш, совет хакимлеге беткәнче (ягъни, 1990 нчы еллар башына кадәр) «Манара бәет»ләре матбугатта басылмаган. Димәк, алар халык арасында кульязма рәвешендә генә таралган.

1990 нчы елларда «Манара бәетләре»нең текстлары газеталарда һәм журналларда күренгәли башлады, аерым төбәк һәм авыл тарихларына багышланган китапларда һәм кайбер җыентыкларда төрле күләмдәге текстлары басылды. Татар халык авыз иҗатын өйрәнүче галим Котдүс Хөснуллинның 2001

елда нәшер ителгән китабында «И манара» исеме белән шактый күләмле (27 строфалы) тексты басылып чыкты[1].

Безнең бу китапта «Манара бәете»нең өч төрле тексты тәкъдим ителә. Аларның беренчесе Ижевск шәһәрендә гомер итүче Сәяхәт Бәкеровта сакланган дәфтәрдән 2009 елда күчереп алынган иде. Гарәп хәрефләре белән язылган ул дәфтәрнең иясе – С.Бәкеровның туганы Лотфулла Даутов булган.

Лотфулла Даут улы Даутов (1905–1990) хәзерге Әгерҗе районының Тәбәрле авылында туып-үскән һәм яшәгән. 1933 елның март аенда аның гаиләсе кулак хуҗалыгы буларак билгеләнеп, колхоздан чыгарылган. Л.Даутов Бөек Ватан сугышында катнашканнан соң хөкемгә тартылып, Колыма дәһшәтләрен кичеп, исән кайткан. Бу текстның ике строфасы К.Хөснуллин китабында чыкканга туры килә. Ә текстның ахырындарак «Дине исламның исеме калган...» дип башланган дүртьюллыктан алып дүрт строфа күләмендәге өлеше бүтән мөнәҗәт-бәеттән алынганлыгы шигъри төзелешеннән күренеп тора.

Лотфулла Даутов. 1941 ел

«Манара бәете»нең II тексты Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1170т» шифры белән саклана торган, 17х20,5 см. зурлыгындагы, 1940 нчы елларга нисбәтле бер кәгазьнең ике ягына шәмәхә кара белән, гарәп хәрефләрендә теркәлгән кулъязмадан алынды. Сакланышы уртачадан ту-

[1] Хөснуллин К. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: көйләп укуга ниезләнгән жанрлар. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 534–536.

бән, бит читләре таушалган. Кульъязма Татарстанның Кукмара районындагы Ятмас Дусай авылында 1996 елның 30 май көнендә бу юлларның авторы һәм китапханә хезмәткәре Ирек Һадиев тарафыннан табылган иде.

Әлеге II текст К.Хөснуллин китабында бирелгән вариантка бик якын. Гомумән, бәет-мөнәҗәтләрдәге аерым юлларның охшашлыгы яки кабатлану күренеше татар халык авыз иҗатына хас.

Бу бәет теркәлгән кульъязмада дәфтәрнең бите сакланмаганга күрә, текстның ахырындагы 6 дүртьюллыгы шәхси кулларда саклана торган дәфтәрдән күчереп алып өстәлде.

Бәетнең III тексты Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2169т» шифры белән саклана торган, 17х20,5 см. зурлыгындагы, 1940 нчы елларга нисбәтле, гомуми күләме 22 кәгазьдән торган мәктәп дәфтәреннән алынды. Аны Равил хәзрәт Бикбаев Татарстанның Балтач бистәсе мәчетеннән алып килеп 2013 елның 1 сентябрендә китапханәгә тапшырган. Бәет дәфтәрнең 17а–18а кәгазьләрендә шәмәхә төстәге кара белән, гарәп хәрефләрендә язылган. Бу дәфтәрдә шулай ук дини язмалар (хәдисләр, догалар һ.б.), мөнәҗәтләр, салават касыйдәләре теркәлгән. Сакланышы уртача.

Дәфтәрдә бу текст «Мөнәҗәт» дип кенә исемләнгән булса да, ул эчтәлеге буенча «Манара бәет»ләренең бер варианты. Төп чыганакта шактый хаталы итеп һәм аерым хәрефләрне төшереп калдырып язылган. Текст:

Әй, Мөхәммәт өммәтләре,
Тырышаек үзебез!

– дип, халыкны, ничек кенә авыр булса да, күңелләрдә иман нурын сакларга өндәгән сүзләр белән тәмамланган.

Милли китапханәдә саклана торган кульъязмаларда «Манара бәете»нең башка күчермәләре дә бар. Алар, нигездә, берберсенә охшаш һәм бик якын, әмма һәрберсе аермаларга һәм үзенчәлекләргә ия.

I текст

Манара бәете

Әй, манара, манара,
Мескенкәем, бичара.
Тәкъдир шулай язган микән,
Түзмәенчә ни чара?!

Әй, манара, манара,
Аең карый кыйблага.
Ничә еллар укып тәсбих
Әйткән идең Аллага.

Әй, манара, сине кискәч,
Башың җиргә кадалды.
Башыңдагы күгәрченнәр
Бар да читкә таралды.

Әй, манара, син утырдың
Ничә еллар зур булып.
Сине кисеп төшергәннәр
Йөрсеннәр инде хур булып.

Әй, манара, исемеңне
Бигрәк матур куйганнар.
Әгәр телгә килгән булсаң,
Куркыр иде дошманнар.

Әй, манара, син үзеңне
Кискәннәрен белмәдең.
Бер Ходайдин әмер булып,
Нигә телгә килмәдең?

Әй, манара, син утырдың
Мөэминнәргә билгегә.

Сине кисеп төшергәннәр
Хур булсыннар мәңгегә.

Әй, манара, син булмагач
Яумый ягмур шылтырап.
Сине кисеп төшергәннәр
Йөрсен мәңге калтырап.

Әй, манара, сине кискән
Җаннар кая киттеләр?
Бер эчәрлек хәмер өчен
Юкка харап иттеләр.

Бик югары менгән икән,
Ник армадылар кискәндә?
Җирләр түгел, күк тетрәде
Син егылып төшкәндә.

Әй, манара, таң туганда
Азан тавышын көтәбез.
Азан тавышы ишетелмәгәч,
Мәхрүм булып китәбез.

Әй, манара, мескенкәем,
Ямьле иде айларың,
Ераклардин күренә иде
Ялтыраган нурларың.

Әй, манара, әй, мәсҗидләр,
Сагына сине мөэминнәр.
Азан да юк, намаз да юк –
Зәгыйфьләнде бит диннәр.

Мәсҗид буйларына барсаң,
Хәсрәткә чумасың.
Эчләренә барып керсәң,
Кычкырып елап чыгасың.

Үзебезнең балалар бит
Җырлап-биеп яталар.
Үз тәннәрен кызганмыйлар,
Җәһәннәмгә аталар.

Әй, манара, манара,
Мескенкәем, бичара!
Әллә Ходай кушты микән,
Түзмәенчә ни чара?!

Әй, манара, манара,
Син бер түгел, йөзләп бит.
Син егылдың, түзалмадың,
Бәхиллегең куеп кит.

Бигрәк надан балалар,
Бер нәрсә дә белмиләр.
Авылларга кино килсә,
Артларындин калмыйлар.

Әй, манара, манара,
Өмидеңне өзмә әле.
Егылдым диеп кайгырып,
Өмидеңне өзмә әле.

Әй, манара, манара,
Авырттымы кискәндә?
Җирләр түгел, күк тетрәде
Син егылып төшкәндә.

Дине исламның исеме калган,
Мәсҗид михраблары уалган.
[Манараларын кисәләр] –
Шушымы әллә ахыр заман?

Ай-Кояшны күрмиләр,
Ислам динен белмиләр,
Алланы да берләмиләр –
Шушымы әллә ахыр заман?

Дөнья ашын куймыйлар,
Шәригатьне белмиләр,
Җыр-шигырьдән туймыйлар –
Шушымы әллә ахыр заман?

Әүвәлгеләр язганнар,
Килер диеп бер заман,
Биш намазга юк бер азан –
Шушымы әллә ахыр заман?

Әй, манара, манара,
Айларыңны кем кискән?
Нигә сине бик кызганам,
Һич тә чыкмыйсың истән?!

Әй, манара, манара,
Менеп азан әйттеләр.
Намазы юк, рузасы юк
Кешеләр харап иттеләр.

Әй, манара, манара,
Сиңа авыр булды ла.
Сине кисеп төшергәч,
Күңелләрем тулды ла.

Әй, күгәрчен, күгәрчен,
Кайда күкәй салырсың?
Мәсҗид очына карасаң,
Хәсрәтләргә калырсың.

Әй, манара, манара,
Түздең җилгә-давылга.
Сине кисеп төшергәч,
Ямьнәр бетте авылда.

Әй, манара, кайгырма,
Күгәрченнәр киттеләр.
Сине егып төшергәннәр
Кибеп-корып беттеләр.

II текст

Манара бәете

И, манара, синең аең,
Бик җыракдин ялтырый.
И, манара, син ауганда
Бөтен адәм калтырый.

Манара әйтә: «Әл-видагы,
Менә бүген кисәләр!»
«Әл-видагы, бәхил бул!» – дип,
Кыйбладин җилләр исәләр.

Манараны кисәр өчен
Балта тотып килделәр.
Җир җөзенә фәрештәләр
Саф-саф булып иңделәр.

Манара әйтә: «Кисәләр бит,
Авам, авам, тотыңыз!
Өммәтләрем, һәр барчагыз
«Вәл-гасрый» укыгыз!

Манарада ай һәм урак
Авабыз дип дулкынлый.
Һавада Ай һәм Кояш та,
Йолдызлар – бар да җылый.



«Манара бәете» (II текст) кульъязмасы

Манараның тәрәзләре
Бар да җиргә коелды.
Фәрештәләр канат җәеп
Саф-саф булып җыелды.

Борма-борма баскычларны
Алып-алып куйдылар.
Борма саен фәрештәләр
Саф-саф булып кундылар.

И, манара, син киселгәч
Кунган кошлар таралды.
И, манара син булмагач,
Ислам дине таралды.

«Манараны кисәләр!» – дип
Бала-чага тавышы.
И, манара, син булмагач,
Бетте азан тавышы.

И, манара күп заманнар
Әйтелгән иде азан.
Ходадан вакыт җиткәндер –
Якындыр ахыр заман.

Әл-видагълар әйтелгәндә
Җилләр дә исмәс иде.
Ходадин вәгъдә җитмәсә,
Алар да кисмәс иде.

Манараны кисү берлә
Кояшның нуры бетте.
«Инна иләйһи раҗигун» дип,
Манара авып китте.

Әй, манара, син куелгач
Бөтен дөнья булды нур.
Инде безгә рәнҗеп китмә,
Шәһри рәхмәт, шәһри нур.

Әл-видагы, и, манара!
Бүген актыгы көнең.
Чөнки сине кисәргә дип
Бар да киләләр бүген.

Мәчет әйтә: «Манарам ауды,
Хәзер мине ишәләр».
Җилләр дәген төньягыннан
Ямьсез булып исәләр.

Мәчет әйтә: «Җук гөнаһым,
Сүтәбез дип киләсез.
Кыяматтә минем өчен
Ничек җавап бирерсез?»

Мәчет әйтә: «Әй, манара,
Әй, минем михрабларым!
Әл-видагы, исәнләшим,
Актыкка минутларым».

Мәчет әйтә: «Әй, михрабым,
Әй, минем мөнбәрләрем!»
Күгәрчен әйтә: «Әй, мәсҗид!
Инде кайда гөрләрем?»

«Ничә еллар бу урында
Ялгыз утырды башым.
Биш вакыт намаз, тәравих,
Салават иде ашым».

Бар халыклар җыелганнар,
Бар да мәчет сүтәләр.
Күркәм яктан фәрештәләр
Тәкбир әйтеп үтәләр.

Фәрештәләр җыелганнар,
Бар да тәкбир әйтә, дип.
Манара әйтә: «Ашыкмагыз,
Бераз бәхилләшик!» – дип.

Мәчет әйтә: «Актык минут,
Бик ашыгып сүтмәгез!
Минем турыдан узганда
Дога кылмый үтмәгез?!»

III текст

Мөнәҗәт

Артларына михраб ярып
Бик зур мәсҗид салдык без.
Бәхетсез өммәт икәнбез –
Бик мәхрүм калдык без.

Кырык җиде ел гомер иткән
Газиз мәсҗид-манара.
Хак Тәгалә шулай кушкач
Авыр килде замана.

Әй, манара, барые синең
Башларыңда айларың.
Исраф булып узар инде
[Изге] рамазан айларың.

Әй, манара, бу замана
Әйтелгән синдә азан.
Синдә азан әйтелмәгәч,
Халыклар калды надан.

Әй, манара, күп күрдек
Авылда җәмнәреңне.
Аң-белем ала алмадык,
Белмәдек тәмнәреңне.

Чит илләрдән ямьле иде
Синең ызан буйларың.
Дошман кулларыннан үтте
Синең актык туйларың.

Әй, мәсҗидем, әй, манарам!
Сезгә килде авырлар.
Манара авып төшкәнгә
Тилмереште авыллар.

Әй, дусларым, сабыр итик,
Кушкан сабыр итәргә.
Хак Тәгалә шулай кушкач,
Мәҗбүр булдык кисәргә.

Әй, мәсҗидем, кайда синең
Гөрләп торган чакларың?
Шыгырдатып, азан әйтеп,
Тәравихлы кичләрең?!

Эчләреңдә балкый иде
Синең якты шәмнәрең.
Бал-шикәрдин татлы иде
Синдә укыган фәннәрем.

Идәнеңдә барые синең
Аллы-гөлле паласың.
Бик зиннәтле йортлар идең,
Кадерсезгә каласың.



«Манара бәете» (III текст) кульязмасы

Әй, мәсҗидем, барые синдә
Пыяла ишек бүлмәләр.
Мөнбәреңдә барые синең
Гөрләп торган муллалар.

Күгәрченнәр килер инде,
Азая җырлар инде.
Гөрләр-җырлар беткәнгә
Үзәкләре өзелер инде.

Гүрнәчәбез исән булса,
Гөрләгән булыр идең.
Мәсҗид сүтелгәнен белсәң,
Килмәгән булыр идең.

Менәргә биек иде
Синең сырлы баскычың.
Муллаларың беткәч инде
Бетте диннең ачкычы.

Шыгырдатып суыралар
Гүрнич кадакларын да.
Сиңа тәкъдир җиткән икән
Мартның азакларында.

Әй, Мөхәммәт өммәтләре!
Тырышаек үзебез!
Хак Тәгалә кабул итсә,
Якты булыр йөзебез.

СҮЗЛЕК

азмагайсыз – азмагыз

аклат – салым күләме; рус телендәге «оклад» сүзе

арест наложить итеп – арест салып

Ахир – ахыры булмаган зат (Аллаһы Тәгалә)

әбрәкәй – бәдрәф

әзаләһү Аллаһу Тәгалә би-фазлиһи вә кәрәмиһи җәлли җәлаләһү – Аллаһы Тәгалә аны үзенең шәфкате һәм юмартлыгы белән юк итте

әл-видагъ, әл-видагы – хуш, сау бул

әлгаязе билләһи – Аллага сыенам, Алла сакласын

әлфазыйлел-мөхтәрәм – хөрмәтле олуг зат

әлхаль – инде, хәзер

әл-хатты бакый вәл-гомрү фани – язу мәңгелек, гомер фани (үтә торган)

әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин – ике дөньяның хуҗасы Аллага мактаулар булсын

әмре Аллаһы – Алла әмере

әсгадәкә Аллаһу фид-дарайни – Аллаһы Тәгалә сине ике дөньяда да бәхетле итсен

әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү – сезгә Алланың сәламнәре, рәхмәтләре һәм бәрәкәтләре ирешсен

Әүвәл – әүвәле булмаган зат (Аллаһы Тәгалә)

әүкате хәмсә – биш вакыт намаз

әүлад вә әүладел-әүлад – балалар һәм оныклар

әхбаб – дуслар

әһали – халык

әһлия – хатын

бакыңлар – карагыз

балнисә – хастаханә; рус телендәге «больница» сүзе

бәгъдендә – соңында, шуннан соң

бәгъзән – кайчак, кайвакыт

бәгъзебер – кайбер
бәнемчөн хәсрәтә – минем өчен хәсрәткә
бәрабәр – бергә
Бәхре мохыйт атласы – Атлантик океан
бигаять – чиксез, чиктән тыш
би-исмиһи Сөбханәһә – бөек Алланың исеме белән
бинаән галәйһи – шуңа күрә
биргәй – бирсен
бөек – зур
бөйлә – мондый
бөрадәр, бөрадәре газиз – туган, газиз туган
брач – табиб; рус телендәге «врач» сүзе
булыс, вулыс – волость

ва вәйла – аһ-зар
васита – арадашлык
вә биһи нәстәгыйн – аннан гына (Алладан) ярдәм сорыйбыз
«Вәл-гасрый» – Коръәннең «Әл-гасыр» сүрәсендәге беренче аять
вәрта вә мөһликә – бәла һәм һәлакәт
вольный высылка – административ сөрген
вредитель – корткыч

галибән – күбесенчә, бигрәк тә
гарәбиел-гыйбарә – гарәп телендә
гарыз итү – әйтү, сөйләү, җиткерү
горбәт – туганнардан аерылып, читтә булу
горсовет – шәһәр советы; рус телендәге «городской совет» гыйбарәсенең кыскартылмасы
гөрифтар улмышам – дучар булдым
гөрьян – үксеп-үксеп елау
гүрнәчә – чиста һәм якты, кунаклар кабул итә торган ак өй; рус телендәге «горница» сүзе
гыйззәтә вә хөрмәтә муафыйк улан – кадерле һәм хөрмәтле
гыйззәтә лаек – кадерле
гыйльме гаруз – шигъри үлчәм (метрика) гыйлеме

даим әйләп – дәвам итеп
дахут – керем; рус телендәге «доход» сүзе

дәйү, дия – дип
дәкыйкә – минут
дәреҗ – теркәү
дәфен – җирләү
дәхи – тагын
добровольный – ирекле, үз ихтыяры белән
догаи хәйр риҗа итү – хәер-догалар үтенү

егълагай, егълайур – елар, елый

җәнабе сәгадәт – бәхетле җәнапләрегез
җөда улмыш – аерылган
җөмлә – барлык

забут – завод
задания – йөкләмә, салым
задания мясы – ит йөкләмәсе
зарыйг – зар
зәйәблиния – гариза; рус телендәге «заявление» сүзе
зикер итү – искә алу
зимнәстүркә – хәрби өс киеме; рус телендәге «гимнастёрка» сүзе
зиядә – күбрәк, артык
зиярәтән – күрешергә

иганә, иганәт – ярдәм
иҗбар – ихтыяҗ, мәҗбүрилек
илән – белән
иля машаллаһ – Алла теләгәнчә
имсаленә муаффәкъ улгайсыз – охшашына ирешегез
имсаль – охшаш
индивидуәлнәй задания – аерым хуҗалык салымы
инкыйлаб – революция
инна Лилләһи вә инна иләйһи раҗигун (Коръәннең «Бәкарә» сүрәсендәге 155 нче аять) – Алла тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз
ин талә гомри фә-Аллаһу йәҗмәгуна вә ин җаәә мәүтуна сәламүн галәйкүм – гомерем озын булса, Аллаһы Тәгалә безне күрештерер, әгәр үлсәм, сез имин булыгыз

ирәрмән – булам
ирсаль – язган
истигъфа – хезмәттән туктау
истифадә – файдалану

йәнвәлит – инвалид

кабилият – сәләт
Кадыйр – кодрәтле (Аллаһы Тәгалә)
каилмән – сөйлим, әйтәм
кайд – теркәү
калеб – йөрәк, күңел
карый – карт
касвәт – тупаслык, караңгылык
кахытлык – ачлык, мохтаҗлык, кытлык
кәлям – сүз
кәмисия – комиссия
кәнүшни – ат абзары; рус телендәге «конюшня» сүзе
квитансә – квитанция
кемсә – кеше, берәү
керәч – известь, акбур
кипяток – кайнаган су
кладовой – келәт
контр – «контрреволюционер» сүзенең кыскартылган варианты
крушение – һәлакәт
куфайка – дөресе: фуфайка, сырма
кыям – аягүрә басып тору

лагпункт – лагерь пункты
Лилләһил-хәмд – Аллага шөкер
лутчы – яхшырак; рус телендәге «лучше» сүзе

мастерской – остаханә
мәдәд – ярдәм
мәзкүр – әйтелгән, күрсәтелгән
мәктүб – язылган, хат
мәктүбемлә – хатым белән

мәкъбүл – кабул

мәлямәт – шелтәләү, орышу

мәмнүн – шат, риза

мәнбәгъ – чыганак

мәншүр – указ, аерым хезмәтне үтәү өчен бирелгән хокук кәгазе

мәркәз – үзәк

мәрсүл – җибәрелгән

мәрсүм – язылган

мәсех – сыйпау, сөртү

мәсҗиде шәриф – изге мәчет

мәсрурияте там насыйп улгай – тулы шатлык насыйп булсын

мәтен – китапның (әсәрнең) төп тексты

Мәүля – хуҗа, яхшылык итүче (Аллаһы Тәгалә)

мәхбүс – тоткын, әсир

мәхкәмә – хөкем итү

мәшьүм – шомлану

минисия – милиция

мисле – охшаш, кебек

могавин – ярдәмче

мөәссәсә – оешма

мөбтәля – дучар

мөддәт – вакыт, срок

мөҗәб – нәтиҗә

мөҗәлләд – том

мөсагадә – мөмкинлек

мөсадәрә – конфискация

мөсаһәлә – илтифатсызлык, әһәмият бирмәү

мөхтәсиб – муллалардан өстен дин галиме

мөяссәр кыл безә дөррел-җинани – безгә кадерле җәннәтләрне насыйп ит

муаффәкъ – ирешү

Мусхәф Шәриф – Коръән

нам – исемле

намәхрәм – чит ир-атка күренүе шәригать буенча тыелган хатын-кыз

натәмам – тәмамланмаган

нахия – район, төбәк

нәфс-ү-шайтан – нәфес һәм шайтан
нияз – ялвару
ноксан – кимчелек, гаеп

основной талон – төп талон

пасилкә – посылка
пиравaт кылдым – почта аша җибәрдем; рус телендәге «перевод» сүзеннән
подвал – баз
полный – тулаем, җитәрлек

Раббәна, лилләһи раҗигун – Раббыбыз, сиңа кайтабыз
рабучай талон – эшче талоны
раздельный акты – хуҗалыкларның бүленүе турындагы документ
ракыйм – язучы
расхут – чыгым; рус телендәге «расход» сүзе
рәзаләт – хурлык, түбәнлек
рәсүл – пәйгамбәр
рәфика – тормыш иптәше, хатын
рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васыйгатән – Алланың киң рәхмәтләре ирешсен
рисалә – китапчык

сабры җәмил – күркәм сабырлык
саг уласыз – сау булыгыз
саләт – намаз
сахиб – ия
сәвәр – сөяр, яратыр
сәвекле, сәвелеп – сөекле, яратып
сәгадәт – бәхет
сәгыеңез иншадыңызлә мәшкүр вә мәәҗүр улгайсыз – шигъриятегез белән мактаулы һәм саваплы булыгыз
сәна – мактау
сельски сәвит, сельсовет – авыл советы; рус телендәге «сельский совет» гыйбарәсе

сельхозналог – авыл хуҗалыгы налогы
симия – гаилә; рус телендәге «семья» сүзе
сипләү – шомарту, төзәтү
снимать – төшерү
спецпереселенец – административ сөрелүче
станса (ыстанса) – станция
сутык – җир мәйданын үлчәү берәмлегенең (дисәтинә, гектар) йөздән бер өлеше; рус телендәге «сотка» сүзе
суырткыч – ашлык җилгәрү машинасы
сүммә – тагын, янә

тәәххер – соңару
тәгаҗҗеб – гаҗәпләнү
тәзәррыг – түбәнчелек белән ялвару
тәнбиһ итү – искәртү, кисәтү
тәравих – ураза вакытында кич белән укыла торган намаз
тәслимате халисанә – эчкерсез сәламнәр
тәхәйер – хәйран калу
тәшәббес – керешү, тотыну
тәшйигъ – озату
тәэсис – нигезләү
төйләгән – тилгән
трактор задаткасы – трактор өчен түләнергә тиешле акчаның алдан бирелгән өлеше

удар – һөҗүм, хәвеф
улан, улсын, улу, улып – булган, булсын, булу, булып
ухрави сәгадәт – ахирәт бәхете (ягъни, җәннәт)

үзрә – эчендә
фә-җәзааһу Аллаһу ганьна хәйрәл-җәзаи – Аллаһы Тәгалә аңа хәерле җәза бирсен (аны иң яхшы бүләк белән бүләкләсен)
фәрагать – эштән бушап тору
фәүкыльгадә – гадәттән тыш
фибрал – февраль
фирак булдым – аерылдым

хазир улу – катнашу

Халикъ – юктан бар итүче, барча галәмне яратучы (Аллаһы Тәгалә)

халис – саф, ихлас

хафизы Кәлямулла – Коръән-хафиз, Коръәнне яттан белүче

хәбес – кулга алу, арест

хәбесханә – төрмә

хәляс – котылу

хәтем – Коръән уку

хәтме кәлям – сүзне тәмамлау

хәят – тормыш, яшәеш

химая – яклау

хосусан (хосусилә) – аеруча, бигрәк тә

хосуста – турыда, хакта

хөрмәтә муафыйк – хөрмәткә лаек

хөсне кабул илә тәләкъкый – яхшы кабул итү

хушнуд – шат, канәгать

Һадиел-имами – имамнарга тугры юл күрсәтүче, юлбашчы

һакәза – шулай ук

һәмишә – һаман

һәркаю – һәркайсы

һәүл намазы – мәет җирләнгән көнне кичен укыла торган намаз

һидаять – туры юлга керү

һилял – яңа туган ай

Һу Аллаһу әл-Барый – ул, Аллаһы Тәгалә, юктан бар итүче

частный – хосусый; текстта хосусый сәүдәгәр күздә тотылган

чигәрмесән – чигәсеңме

шәйхелислам – мөселманнар башлыгы

шәраит – шартлар

шәрафәтле – кадерле, хөрмәтле

шәрех – аңлатма, китапның авыр урыннарын ачыклап аңлату

шәһри нур – нурлы ай

шәһри рәхмәт – рәхмәт ае

шөйлә – шундый

шөмулән – берлектә

шура – совет

ызба – йорт, өй
ысправка, ысправкы – белешмә; рус телендәге «справка» сүзе
ысталавай – ашханә; рус телендәге «столовая» сүзе
ыстароста – староста
ышкул – мәктәп; рус телендәге «школа» сүзе

явитсә итү – килеп күренү, теркәлү
ягмур – яңгыр
ятап – этап
яхуд – яки

РЕЗЮМЕ

В 29-ом выпуске серии «Татарская археография» представлены воспоминания, письма, документы, баиты и мунаджаты, посвящённые репрессиям 1930-х гг., а также несколько документов из личных архивов. Издание представляет собой обзор рукописных материалов, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Представленные рукописи – результат многочисленных археографических изысканий, проведённых в Казани, Ижевске, Бугуруслане, а также в селениях Агрызского, Балтасинского, Кукморского районов Республики Татарстан, Татышлинского и Янаульского районов Республики Башкортостан.

Авторами текстов, написанными на арабской графике, являются бывшие представители духовенства, купечества и др., пережившие суровые испытания тех лет. Всего в книге упоминаются имена более 70 невинно репрессированных человек.

В сборник также вошли несколько вариантов «Баита о минарете», рассказывающего о разрушении мечетей – своего рода символа победы советской власти над религией. Всего в книге – 18 текстов.

Во вступительной статье к изданию дан обзор общественно-политического состояния страны и республики 1930-х годов: классовой борьбы, коллективизации сельского хозяйства, раскулачивания, административных высылок, антирелигиозных мер и т.п. Некоторые материалы частично уже были опубликованы, в том числе и в предыдущих выпусках серии «Татарская археография».

В конце вступительной статьи приводятся краткие сведения о географии наиболее крупных мест заключения и массовых административных ссылок, упоминаемых в опубликованных текстах, таких как Беломорканал, Московский канал, Северный край, Вишлаг, Магнитогорск, Анджеро-Судженск и др.

Опубликованные материалы снабжены предисловиями, краткими сведениями об авторах и их биографиях, примечаниями.

Издание иллюстрировано фотографиями отдельных авторов и образцами факсимиле рукописей.

«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «Милли китап» нәшриятында «Татар археографиясе» дип аталган махсус сериядә фәнни-популяр басмалар 2008 елда дөнья күрә башлады. Сериянең төп максаты – китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган тарихи, әдәби һәм башка төр язма истәлекләрнең текстларын басмага әзерләп нәшер итү аша татар кулъязма мирасын таныту.

Басма җыентыкларда кулъязма истәлекләрнең текстлары, фәнни мәкаләләр, кулъязмаларның тасвирламалары, искәрмәләр һәм русча резюме урын ала. Сакланыш дәрәҗәсе мөмкинлек биргәндә һәм ихтыяҗга күрә төп чыганакның күчермәсе – факсимилесе да бастырыла.

Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). **Шул ук.** Икенче басма. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 88 б.

Түләк китабы: дастан / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

Сәяхәтнамәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

Кыз хикәяте / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

Сөрген хатлары / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

Гали авылы тарихы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2015. – 108 б. (16 нчы китап).

[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

Сугыш һәм солдат бәетләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

Дастане җайә (Мәликә китабы) / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

Халык җырлары: XVII–XX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2021. – 196 б. – (28 нче китап).

ЭЧТӘЛЕК

Мәрданов Р. «Дога кылам Сталинга...»..............................3

«Гомернең бушка узуы – җәза»..35
«Төрмәдән юк булды»..63
«Таланган малда бәрәкәт юк»..69
Лагерьда моңаеп-сагынып җырлаган җыруларым...........81
«Сөргеннәргә сөргән җирдә әрәм булырбыз микән?».....91
«Гаиләмне ач калдырды»...107
1931 елда чыккан мөнәҗәт..110
«Мин мулла да түгел, кулак та түгел»............................113
Төрмәдә яткан мулланың мөнәҗәте................................116
«Мин колхозга керергә каршы түгел»............................123
«Кечкенә генә урын бирүегезне сорыйбыз».................126
«Бер егъламаган кеше калмады»....................................130
Сагынычлык мөнәҗәте..134
«Бик тук, бер исәбем дә юк»..143

Манара бәетләре...151
I текст..154
II текст...158
III текст..162

Сүзлек...166
Резюме..175

«Татар археографиясе»
сериясендә чыккан китаплар..176

СТРАНИЦЫ ТРАГИЧЕСКИХ СОБЫТИЙ 1930-ых ГОДОВ

(на татарском языке)

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Алсу Хафизова

Басарга кул куелды 05. 05. 2022. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 463.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 05. 05. 2022. Формат 60x84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 463.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.